ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ИСЛАМНЫ ӨЙРӘНҮ ҮЗӘГЕ

*Камил Вәлиуллин*

# التَّرْبِيَّةُ الدِّينِيَّةُ الإِسْلاَمِيَّةُ

# ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ

ДӘРЕСЛЕК

КАЗАН 2012

УДК 297

ББК 86.38

В15

Төзүчесе: Камил Хәмзә улы Вәлиуллин

Уку әсбабындагы шартлы билгеләр:

- шигырь, мөнәҗәт, хикәя яисә мәкаләне укы һәм истә калдыр

- дәфтәреңә язып куй

- салләл-лааһү гәләйһи вә сәлләм (аңа Аллаһының сәламе булсын): Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺнең исеменнән соң кылә.

В 15 Вәлиуллин К.Х.

Ислам тәрбиясе. Дәреслек. - Яр Чаллы: «Ислам нуры» эшмәкәрлек үзәге. - 2012. - 257 б.

***«Ислам тәрбиясе» дәреслеге түбәндәге бүлекләрдән тора: Ислам дине, иман нигезләре, Коръән Кәрим, пәйгамбәрләр кыйссалары, Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺнең тормышы, мөселманнарның күркәм холыклары, Ислам әдәпләре һәм догалары. Китап мәктәпнең башлангыч сыйныф укучылары өчен һәм мәчет-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак тәкъдим ителә. Шулай ук, гаиләдә балаларга укыту өчен дә кулланырга мөмкин.***

© Вәлиуллин К.Х., 2012

© Исламны өйрәнү үзәге, 2012

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш ........................................................................................ 10

## ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ
## 1-НЧЕ СЫЙНЫФ

**1-нче бүлек. Ислам дине ....................................14**

1. Гамәл кылу................................................................14

2. Ислам диненең нигезләре..............................................16

А. Ике шәһадәт китерү...................................................16

Ә. Тәһарәт һәм намаз.....................................................21

Б. Зәкят..........................................................................30

В. Ураза.......................................................................... 34

Г. Хаҗ............................................................................. 37

**2-нче бүлек. Пәйгамбәрләр кыйссалары................ 40**

1. Адәм гәләйһис-сәләм пәйгамбәр..................................40

2. Нух гәләйһис-сәләм пәйгамбәр .................................... 44

**3-нче бүлек. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең тормышыннан ....................................................... 47**

1. Мөхәммәд ﷺ нең гаиләсе........................................... 47

2. Фил вакыйгасы ............................................................ 47

3. Мөхәммәд ﷺ нең бала чагы ....................................... 48

4. Мөхәммәд ﷺ Әбү Талибның тәрбиясендә.................. 48

**4-нче бүлек. Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли ....................................51**

1. «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен әйтү ........51

2. Сәламләшү.....53
3. Әтием һәм әнием.....54
4. Туганнарым һәм якыннарым.....57
5. Кардәшләрем (дусларым) һәм күршеләрем.....58
**5-нче бүлек. Ислам әдәпләре һәм догалары.....60**
1. Ашау әдәпләре һәм догалары.....60
2. Бәдрәфкә керү әдәпләре һәм догалары.....62
3. Дәрес алу әдәпләре һәм укыла торган догалары.....64
**6-нчы бүлек. Аллаһы Тәгаләнең Китабы - Коръән Кәрим.....67**
Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр.....67

## ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ
## 2-НЧЕ СЫЙНЫФ

**1-нче бүлек. Иман нигезләре.....70**
1. Аллаһы Тәгаләгә иман китерү.....70
2. Фәрештәләргә иман китерү.....73
3. Пәйгамбәрләргә иман китерү.....75
4. Китапларга иман китерү.....77
5. Ахыр заманга һәм Кыямәт көненә иман китерү.....80
6. Тәкъдиргә иман китерү.....83
**2-нче бүлек. Пәйгамбәрләр кыйссалары.....86**
1. Һүд гәләйһис-сәләм пәйгамбәр.....86
2. Ибраһим гәләйһис-сәләм һәм Исмәгыйль гәләйһис-сәләм пәйгамбәрләр.....89

3. Йосыф гәләйһис-сәләм пәйгамбәр................................ 94

**3-нче бүлек. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең тормышыннан.......................................................102**

1. Кәгъбәне төзү.............................................................. 102
2. Хәдичәгә өйләнү.......................................................... 103
3. Вәхинең иңдерелә башлавы........................................ 103
4. Исламга өнди башлау.................................................. 105
5. Беренче мөселманнар.................................................. 107
6. Хабәшстанга күчеп китү............................................ 109
7. Олы кайгы елы............................................................110
8. Таифка бару ................................................................ 111
9. Мөхәммәд ﷺ нең Мәккәдән Коддуска төнге сәяхәте һәм күккә ашуы ...........................................................112
10. Пәйгамбәр ﷺ нең Мәдинәгә һиҗрәт кылуы (күчеп китүе)..........................................................................113

**4-нче бүлек. Мөселманның күркәм холыклары ..... 119**

1. Тугрылык ..................................................................119
2. Мәрхәмәтлек һәм йомшак күңеллелек.....................120
3. Ярдәмләшү һәм юмартлык.........................................121
4. Әдәп һәм хая .............................................................. 124
5. Шөкер, шөкер итү ...................................................... 125

**5-нче бүлек. Ислам әдәпләре һәм догалары ..........129**

1. Мәҗлес әдәпләре һәм догалары ................................ 129
2. Авыруның хәлен белү әдәпләре һәм догалары ....... 130
3. Һәрвакыт зур файдалар китерә торган догалар ...... 131

**6-нчы бүлек. Аллаһы Тәгаләнең Китабы – Коръән Кәрим ........ 133**

Коръән Кәримне уку һәм аның гыйлемен үзендә йөртүченең өстенлекләре........ 133

## ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ
## 3-НЧЕ СЫЙНЫФ

**1-нче бүлек. Аллаһы Тәгаләнең күркәм исемнәре һәм сыйфатлары ........ 138**

1. Иман кәлимәләре ........ 138
2. Аллаһы Тәгаләнең исемнәре ........ 142
3. Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары ........ 145
4. Аллаһы Тәгалә - Гафу итүче, Шәфкатьле ........ 156

**2-нче бүлек. Пәйгамбәрләр кыйссалары ........ 160**

1. Әйюб гәләйһис-сәләм пәйгамбәр ........ 160
2. Муса гәләйһис-сәләм пәйгамбәр ........ 162
3. Дауд гәләйһис-сәләм пәйгамбәр ........ 170

**3-нче бүлек. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең тормышыннан ........ 173**

1. Бәдер сугышы ........ 173
2. Өхед тавы янындагы сугыш ........ 174
3. Худайбия вәкыйгасы ........ 176
4. Патшаларга һәм хакимнәргә илчеләр җибәрү ........ 178
5. Хайбәр ныгытмасын алу ........ 180

6. Аллаһы Тәгалә бүләк иткән гыйбадәт ...................... 180
7. Мәккәи Мөкәррәмне фәтех итү.................................... 181
**4-нче бүлек. Тугры хәлифәләр............................183**
1. Әбү Бәкер әс-Сиддыйк.....................................................183
2. Гомәр ибн Хаттаб әл-Фәрук..............................................185
3. Госман бин Гаффан Зин-Нүрайн ..................................189
4. Гали ибн Әбү Талиб Хәйдар............................................191
**5-нче бүлек. Ислам әдәпләре һәм догалары ..........194**
1. Берәр зарар һәм зыян килсә укыла торган тога ......194
2. Кием әдәпләре һәм догалары ........................................194
3. Төчкерү әдәпләре һәм әйтелә торган догалары ....... 196
**6-нчы бүлек. Аллаһы Тәгаләнең Китабы – Коръән Кәрим ...................................................................197**
Коръән Кәрим турында сорау-җавап............................. 197

## ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ
## 4-НЧЕ СЫЙНЫФ

**1-нче бүлек. Мөселман календаре һәм мөселман бәйрәмнәре .........................................................201**
1. Мөселман календаре ...................................................... 201
2. Мөселман бәйрәмнәре....................................................202
**2-нче бүлек. Пәйгамбәрләр кыйссалары...............206**
1. Сөләйман гәләйһис-сәләм пәйгамбәр .......................206
2. Юнус гәләйһис-сәләм пәйгамбәр................................ 210
3. Гайсә гәләйһис-сәләм пәйгамбәр.................................212

**3-нче бүлек. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең тормышыннан ........................................................ 217**

1. Тәбүк вакыйгасы ........................................................ 217
2. Хушлашу хаҗы ........................................................ 217
3. Рәсүлүллаһ ﷺ нең вафаты ........................................................ 218
4. Рәсүлүллаһ ﷺ ның сыйфатлары ........................................................ 219
5. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең хатыннары ......... 220

**4-нче бүлек. Мөселманның күркәм холыклары ..... 227**

1. Тырышлык ........................................................ 227
2. Сабырлык ........................................................ 231
3. Әманәт ........................................................ 235
4. Локман Хәкимнең улына әйткән нәсыйхәтләре ... 237
5. Яхшы һәм начар сүз ........................................................ 239
6. Әти-әнигә хөрмәт ........................................................ 243

**5-нче бүлек. Ислам әдәпләре һәм догалары .........248**

1. Йокы әдәпләре һәм укыла торган догалары ............ 248
2. Юл әдәпләре һәм догалары ........................................................ 250
3. Мәчет әдәпләре һәм догалары ........................................................ 252

**6-нчы бүлек. Аллаһы Тәгаләнең Китабы – Коръән Кәрим ........................................................ 254**

Коръәннең иңдерелүе һәм бер мусхафка тупланы .. 254

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا

وَ مِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا وَ مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلْ فَلاَ هَادِيَ لَهُ

أَشْهَدُ أَنْ لآ إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ

## ***Мөхтәрәм газиз балалар!***

Кешеләрнең иң күркәме, иң сөеклесе ул - күркәм әхлакле, әдәпле, тәрбияле булганы. Без мөселманнар күркәм әхлакле, әдәпле булуыбыз өчен Аллаһның Китабы Коръән Кәримне һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең күрсәтмәләрен өйрәнергә һәм шуларны гамәлдә үтәргә тиешбез.

Әхлаклылык – милләт көченең нигезе, әхлаксызлык һәм бозыклык исә милләтнең таркалуының һәм түбән тәгәрәвенең нигезе. Бүгенге көндә фән һәм техника алга китте, гаҗәеп ачышларга тап булды. Әмма икенче яктан, адәм баласы көннән көн үзенең кешелек сыйфатларын югалта, фәкать үзен генә сөючегә, тетрәндергеч җинаятьләрне эшли алучыга әйләнеп бара. Табигатькә, тормышның табигый агымына кире барганга күрә кешелек газап чигә. Шуңа күрә кешегә үзенең асылына кайтырга, аны бар иткән бердәнбер Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә иман китереп, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә кирәк.

**Кадерле балалар!** Күңелләребездә мөкатдәс Ислам динебезгә карата мәхәббәт артсын, иманнарыбыз нык булсын. Раббыбыз Аллаһы Тәгаләне, изге Китабы Коръән Кәримне, Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ не ихлас күңелдән сөючеләрдән булыйк. Үзебезгә, әти-әниләребезгә, дәү әти һәм дәү әниләребезгә, абый-энеләребезгә, апа-сеңелләребезгә карата, туганнарыбыз, күршеләребез, дусларыбыз (кардәшләребез) арасында һәм башка мөнәсәбәтләрдә дә мөселманча булырга тырышыйк. Рәсүлебез Мөхәммәд ﷺ , аның сәхабәләре, элек яшәгән яхшы, инсафлы кешеләр безгә үрнәк булсыннар. Барчабыз иман-Ислам юлында нык торып, үзебезгә, халкыбызга, Ватаныбызга файдалы кешеләр булырга насыйп әйләсен.

Хак Сөбханәһү вә Тәгалә ошбу хезмәтне изге гамәлләрдән кылса иде. Вафат булуыбыздан соң да бу китапны укучылар үзләренең хәер догалары белән безне шатландырсыннар иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә ниятләребезне күзәтеп торучы һәм туры юлны күрсәтүче!

وَآخِرُ دَعْوَانَا أَنِ الْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

Габдулла Тукай

## *Таян Аллага*

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның, һәрдәм таян син Аллага!



Йа Ходай, күрсәт, диген, ошбу җиһанда якты юл;
Ул – Рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле Ул!


Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә Кыйбла каршына;
Бел Аны: керсез күңелдән тугры юл бар Гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның, һәрдәм таян син Аллага!


# ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ

## 1-НЧЕ СЫЙНЫФ



# 1-НЧЕ БҮЛЕК

## ИСЛАМ ДИНЕ

Дин – кешеләрне дөньяда һәм Ахирәттә бәхетле итәр өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан пәйгамбәрләр аркылы



кешеләргә ирештерелгән юл.

Ислам – буйсыну дигән мәгънәне аңлата. Ислам дине – Аллаһы Тәгалә тарафыннан Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә җибәрелгән хак дин. Кешеләр Ислам динебез кушканча яшәргә тиеш була. Ислам дине кушканча яшәүче кеше, Аллаһы Тәгаләгә буйсынучы булып санала.

Ислам диненең хаклыгына ышанган кеше мөэмин һәм мөселман дип атала. Безнең динебез – Ислам дине. Без, Әлхәмдүлилләһ, һәркайсыбыз мөэмин һәм мөселманнар.

### *1. Гамәл кылу*

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә Ислам динен кешеләрне яхшылыкка өйрәтү өчен җибәргән. Ислам дине – туры юлны күрсәтүче дин. Аның хөкемнәре буенча гамәл кылган кеше дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле була.

Ислам диненең мәгънәсе: Аллаһы Тәгаләдән килгән хак дин буенча гамәл кылу дигәнне аңлата. Мөселман кешесе эшләргә яисә тыелырга тиешле кайбер гамәлләрне карап үтик:

**Фарыз** – шундый гамәл, аны эшләгән кеше саваплы, эшләмәгән кеше гөнаһлы була, фарызлыгына ышанмаган кеше кяфер була. Фарыз гамәлләр:

- һәркөн биш вакыт намаз уку, Рамазан аенда ураза тоту;
- әти-әнине хөрмәт итү, аларга итагать итү, аларга карата яхшы мөгамәләдә булу һ.б.

**Важиб** – шундый гамәл, аны эшләгән кеше саваплы, эшләмәгән - гөнаһлы, важиблыгына ышанмаган кеше зур гөнаһлы була. Важиб гамәлләр:

- витр намазын уку, гает намазларын уку;
- берәр гамәлне эшләргә теләсә «Аллаһ бирсә» яисә «иншаАллаһ» дип әйтү;
- укытучыны хөрмәт һәм аңа итагать итү һ.б.

**Сөннәт** – шундый гамәл, аны эшләгән кеше саваплы була, эшләмәгән гөнаһлы булмый, ләкин Кыямәт көнендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең шәфәгатенә (яклавына) лаек булмый. Сөннәт гамәлләр:

- һәрбер яхшы гамәлне башлар алдыннан «Бисмилләһ» (ягъни «Аллаһ исеме белән башладым») дип әйтү;
- мөселманнарга сәлам бирү;
- кигән киемнең чиста һәм тәртиптә булуы;
- сәлам биргәндә кул бирешү һ.б.

**Хәрам** – шундый гамәл, аны эшләгән кеше зур гөнаһлы, аны хәләл диюче - кяфер була. Хәрам гамәлләр:

- кеше тәненә зарар китерү;

- кеше әйберен урлау;
- рөхсәтсез кеше өенә керү;
- исерткеч эчү, отышлы уеннар уйнау һ.б.

**?Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Фарыз һәм важиб булган тагын нинди гамәлләр беләсең? Син бу гамәлләрне үтәргә тырышасыңмы?
2. Сөннәт гамәлләргә нинди мисаллар китерә аласың? Иң яраткан сөннәт гамәлеңне әйт һәм ни өчен икәнлеген аңлатып бир.
3. Хәрам гамәлләргә тагын нинди гамәлләр керә? Шушы гаммәлләрдән саклану өчен, синең уйлавыңча, нәрсә эшләргә кирәк?

## *2. Ислам диненең нигезләре*

Ислам диненең нигезләре бишәү: Беренчесе – ике шәһадәт китерү; икенчесе – көнгә биш тапкыр намаз уку; өченчесе - Рамазан аенда ураза тоту; дүртенчесе - зәкят бирү; бишенчесе - хаҗ кылу.

Рәсүлебез Мөхәммәд ﷺ нең хәдисе:

“Ислам дине 5 нәрсәгә нигезләнгән: Аллаһтан башка һичбер илаһ юк һәм Мөхәммәд ﷺ Аллаһның Рәсүле дип шәһадәт бирү, көненә биш тапкыр намаз уку, зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту һәм хаҗ кылу”.

## *А. Ике шәһадәт китерү*

Ислам дине нигезләренең беренчесе – ике шәһадәт китерү:

أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ الاَّ اللهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللهِ

*(Әшһәду әл-лә иләһә иллә-Лаһу вә әшһәду әннә Мухәммәдәр-Расулу-Лаh)*

Мәгънәсе: "Аллаһтан башка һичбер иләһ юк һәм Мөхәммәд ﷺ Аллаһның Рәсүле дип шәһадәт китердем".

Без Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанып, кушкан эшләрен эшләп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә тиешбез. Аллаһның биргән санаусыз нигъмәтләренә рәхмәтле булып, Аны һәрнәрсәдән өстен күрергә, Аны сөяргә, Аннан курыкырга, Аңа чын күңелдән шөкер итәргә, Аның исемен һәрвакыт хөрмәт белән телгә алырга кирәк. Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү түбәндәгечә була:

- 5 вакыт намазны калдырмау белән;
- әти-әнигә итагать итү, сүзләрен тыңлау белән;
- дәресләрне әзерләү һәм тиешлесен эшләү белән;
- укытучыларны хөрмәт итү, кардәшләрне, дусларны, туганнарны ярату белән;
- фәкыйрьләргә һәм мохтаҗларга ярдәм итү белән.

Без Мөхәммәд ﷺ не Аллаһның илчесе булуына, Аллаһы Тәгалә тарафыннан аның безгә Ислам динен алып килүче булуына ышанырга тиешбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ динне өйрәтү өчен барча халыкларга җибәрелгән. Шул сәбәпле, аның тормышын үзебезгә үрнәк итеп алырга, кылган гамәлләрен безгә дә эшләргә тырышырга кирәк. Аның исемен әйткән вакытта яки ишеткәндә ﷺ «Салләл-Лаһү галәйһи вә сәлләм» ("Аңа Аллаһның сәламе булсын") дип хөрмәт белән искә алу кирәк.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Кем иртә һәм кич:

رَضِيتُ بِاللهِ رَبًّا وَبِالاِسْلاَمِ دِينًا وَبِمُحَمَّدٍ رَسُولاً

(Радытүби-Лләһи Раббән вә бил-Исләми динән вә би-Мүхәммәдин Расүлән, ягъни, Аллаһның Патша булуыннан, Исламның дин булуыннан, Мөхәммәд ﷺ нең Пәйгамбәр булуыннан разый булдым) дип әйтсә, аңа Җәннәт тиеш булыр».

## Аллаһы Тәгалә – Ризыкландыручы (الرَّزَّاقُ)

Аллаһы Тәгалә барча җан ияләрен Ризыкландыручы һәм Ул ялгыз бер Үзе аларга ризыкны Бирүче. Аллаһы Тәгалә әйтә:


إِنَّ اللَّهَ هُوَ الرَّزَّاقُ

«Хакыйкатьтә Аллаһ – ризык бирүче». *(Әз-Зәрият сүрәсе, 51/58).*

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Бала ана карынында 4 айлык булгач, Аллаһы Тәгалә аңа бер фәрештә җибәрә, ул аңа җан өрә һәм Аллаһы Тәгалә фәрештәгә аның әҗәлен һәм ризыгын язарга куша». (Сахих Бохари һәм Мөслим).



Аллаһы Тәгалә кешеләргә ризыкны бирүче булса да, кеше, эшләмичә ялкауланып, ризыкның килүен генә көтеп ятмаска тиеш, ә Аллаһы Тәгаләдән ризык өмет итеп, кәсеп итәргә тиеш. Кеше Аллаһы Тәгалә биргән ризыкны хәләл юл белән дә, хәрам



юл белән дә алырга мөмкин. Хәләл юлдан эзләсә, Аллаһы Тәгалә хәләл юлдан бирер, хәрам юлдан эзләсә, хәрам юлдан бирер. Ризыкны хәләл яки хәрам юл белән табуы кешенең үзеннән тора. Шуңа күрә кеше Кыямәт көнендә ризыкны хәләл яисә хәрам юл белән табуы һәм Аллаһы Тәгалә биргән ризыкны кая тотуы хакында соралачак.

Өмет баглау һәм инану ризыкка түгел, ә һәр җан иясен Ризыкландыручы Аллаһы Тәгаләгә генә булырга тиешле. Чөнки Аның хәзинәсе мул, Аңа чын күңелдән ышанганнар кыенлык күрмәсләр. Тик бер генә туендыручы булган Аллаһыны онытып, ризыкка өмет баглаганнар кыенлык күрерләр, хәсрәттән котыла алмаслар.

Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә тормыш сынау өчен бирелгән һәм Ул аларны төрле юллар белән сыный. Шуның өчен кайбер кешеләрне фәкыйрьлек белән, кайбер кешеләрне байлык белән сыный, кайберләрен хасталык белән, кайберләрен курку, кайгы, шатлык һ.б. белән сыный.

Шуңа күрә ризык Бирүче бер Аллаһы Тәгалә генә дип иман китергән кеше фәкыйрь булган чагында сабыр итә һәм хәрам юллар белән ризык табарга тырышмый, бай булган чагында Аллаһы Тәгалә биргән ризыкка шөкер итеп, үз өстендәге

зәкят һәм сәдакаларын үтәп, хәләл юлларга акчасын тота. Хак мөселман боларның бөтенесе Аллаһы Тәгаләнең сынавы икәнлеген белә һәм аны исән-сау үтеп, Аллаһның ризалыгын алырга өмет итә.

Кораблар йөзә диңгездә
Зур йөкләр төяп.
Уйлап карагыз, балалар,
Бу түгелме соң нигъмәт?

*Җәүһәрия Якупова*

Инандым мин Аллаһка,
Аллаһның барлыгына,
Аллаһның берлегенә,
Бердер Аллаһым минем.

Барлыгы Үзеннәндер,
Һич кемсәдән түгелдер,
Үзлегеннән булгандыр,
Бердер Аллаһым минем.

Бер Аллаһым, Үзең Син
Һәр нәрсәне бар иткән,
Һәркемгә ризык биргән
Бердер Аллаһым минем.

Аллаһым, Син ялгызсың,
Юктыр уртагың Синең,
Юктыр тиңдәшең Синең,
Бердер Аллаһым минем.

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Аллаһы Тәгалә галәмдә бар иткән кояшны, айны, йолдызларны күзәт. Син алар хакында нәрсәләр беләсең? Шуларны сөйлә.
2. Аллаһы Тәгалә үстергән агачларны, чәчәкләрне, үсемлекләрне һәм башкаларны альбом битенә ясап кара.
3. Безнең илебездә нинди хайваннар бар? Алар нәрсә ашыйлар? Син нинди хайванны яратасың һәм ни өчен? Шул хайван турында сөйләп бир.

## *Ә. Тәһарәт һәм намаз*

Ислам дине нигезләренең икенчесе – намаз.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә:

إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَوْقُوتًا

“Тәхкыйк, мөэминнәргә вакытында намаз уку фарыз ителде”.

*(Ән-Ниса сүрәсе, 4/103)*

Намаз укыячак кешенең тәне, киеме һәм урыны чиста була. Ул Ислам дине кушканча су белән тиешле әгъзаларын юып, тәһарәт алырга тиеш, чөнки намаз кабул булсын өчен аны тәһарәтле килеш укырга кирәк. Мөселман кешесе һәрвакыт та тәһарәтле йөрергә тырыша.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйткән:

«Ислам дине - чиста дин. Чиста булырга тырышыгыз. Чиста булмаган кеше Җәннәткә кермәс».



«Бисмилләһ» дип әйтәм дә,
Юыла нәни куллар.
Чиста булсын, пөхтә булыйм
Үрчемәсен микроблар.

*Җәүһәрия Якупова*



1. Тәһарәт алачак кеше иң әүвәл, бәдрәфкә кереп, су белән гаурәтләрен нәҗестән пакълар;



2. Күңелдән тәһарәт алам дип ниятләр: «Иләһи ният кылдым тәһарәт алырга»;



3. Аннан беләзекләренә кадәр ике кулын юар;



4. Уң кулына су алып, өч мәртәбә авызын чайкар;



5. Уң кулы белән су алып, борынын юар, сул кулы белән сеңгерер (моны 3 тапкыр эшләр);



6. Аннан өч мәртәбә битен юар;



7. Өч мәртәбә уң кулының беләген юар (терсәген кертеп);



8. Өч мәртәбә сул кулының беләген юар (терсәген кертеп);



9. Аннан соң, учларын һәм бармакларын суга чылатып, ике кулы белән башын сыйпар;



10. Ике колагын сыйпар;



11. Ике кулы белән муенын сыйпар;



12. Аннан соң тубыкларына кадәр, иң кечкенә бармагыннан башлап, өч мәртәбә уң аягын юар;



13. Соңыннан өч мәртәбә сул аягын юар (аякны юу баш бармак ягыннан башлана).

## ? Сораулар һәм күнегүләр:

1. Тәһарәт алуны өйрәнгәннән соң аны үзеңнең якын туганыңа яисә дустыңа да өйрәтеп кара.

2. Чисталык турында Пәйгамбәребез ﷺ нең тагын нинди хәдисләрен беләсең? Бер – ике хәдисне киләсе дәрескә сөйлә.

3. Чисталык-пөхтәлек турында бер – ике мәкаль яисә шигырь язып кил (өйрәнеп кил).



## НАМАЗ УКУ РӘВЕШЛӘРЕ

Намаз ул – Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм рәвештә күңел һәм тән белән гыйбадәт итү. Һәрбер мөселман кешегә көненә биш вакыт намаз уку тиеш: иртәнге намаз, өйлә, икенде, ахшам, ястү.

Хәдис: Бервакыт Пәйгамбәребез ﷺ үз өеннән чыкты. Көз иде, һәм агачлардан яфраклар коела иде. Ул бер агачның ботагын тотып, аның яфраклары коелгач әйтте: «Әй, Әбу Зарр, Аллаһ ризалыгы өчен намаз укыган мөселманның гөнаһлары шушы агачның яфраклары коелган шикелле коелып төшәр».

Мөселман кеше Кыйбла ягына басып, намаз уку ниятен әйтә.

**Тәкбир**



Күзләр сәҗдә кылу урынына карый. Учлар Кыйблага юнәлгән, баш бармак колак йомшагына тиеп тора. Ике аяк арасында 4 бармак сыярлык ара калдырыла. «Аллаһү әкбәр» дип әйтелә.

**Кыям**



Күзләр сәҗдә кылу урынына карый. Куллар кендек асты турысында бәйләнгән. Уң кулның чәнчә бармагы белән баш бармагы сул кул беләзеген тоткан.

## Рөкугъ



Күзләр аяк очларына карый. Баш һәм җилкә бер тигезлектә, арка төз хәлдә җиргә параллель торышта. Аяклар һәм куллар туры. Кул бармаклары ачык хәлдә тезгә ныклап таянган.

## Сәҗдә



Баш ике кул арасында. Маңгай белән борын җиргә терәлгән. Бармаклар Кыйблага туры куелган. Терсәкләр ян-якка җибәрелгән һәм җиргә тимиләр. Корсак ботларга тияргә тиеш түгел. Аяк бармаклары алга, Кыйблага юнәлтелгән хәлдә, үкчәләр бер-берсенә тиеп тора.

## Кәгъдә



Күзләр тезләргә карый. Куллар тез өстендә. Сул аяк яткырылып, шуның өстенә утырыла, уң аякның бармаклары Кыйблага таба юнәлгән хәлдә, табаны белән җиргә вертикаль тора.

**Уң тарафка сәлам**



**Сул тарафка сәлам**



Куллар тездән әз генә югарырак, ботлар өстендә. Уң аяк табаны җиргә вертикаль, баш бармак Кыйблага карый. Баш уңга борылган һәм күзләр уң җилкәгә карый. (Сул тарафка сәлам бирү дә шуңа охшаш).

## Дога



Ике кул догага күтәрелгән, бармак очлары җилкә тирәсендә. Ачык учлар йөзгә каратылган. Баш бармаклар аерылыбрак тора.

Намаз – диннең терәге,
Намаз – Ахирәт бүләге;
Гамәл кылган кешенең
Утта янмас сөяге.

И Раббыбыз, газиз Аллаһ,
Рәхмәтеңдә булсак иде,
Биш вакыт намазыбызны
Вакытында кыйлсак иде!

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Намаз турында Пәйгамбәребез ﷺ нең бер хәдисен тап һәм аны дәфтәреңә язып алып кил.

2. Син намаз укыр өчен мәчеткә барганың бармы?

3. Мәчеттә намазны ничек укыйлар? Өйдә укыганыңнан аермалары бармы?

4. Намаз турында берәр хикәя төзе.

## *Б. Зәкят*

Ислам дине нигезләренең өченчесе – һәр елда бер мәртәбә малдан зәкят бирү.

Зәкят байлар тарафыннан фәкыйрьләргә, мескеннәргә, бурычы булып, аны түләргә акчасы булмаганнарга, Аллаһы Тәгалә юлында булучыларга һәм мохтаҗларга бирелә. Зәкятне бирмәгән кеше бик зур гөнаһлы була. Зәкят малы акчадан, алтыннан, көмештән, хайваннардан, уңыштан (җиләк-җимешләрдән) бирелергә мөмкин.

Сәдака - кешенең үз теләге белән бирелә торган хәер. Аны бирү бик саваплы. Сәдаканы күп бирү гөнаһларның гафу ителүенә, бәла һәм афәтләрдән имин булырга сәбәпче була.

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән:


«Аллаһы Тәгалә мөселманнарга малларыннан зәкят бирүне әмер итте. Ул зәкят мөселманнарның байларыннан алынып, фәкыйрьләргә бирелер».

📖 Элек вакытларда яшәгән ди абый белән апа. Аларның ике уллары һәм дүрт кызлары булган. Әтиләре һәм уллары һәрвакыт бакчада эшләгәннәр, чөнки бакчалары бик зур булып, аларда алма, слива, балан, груша агачлары, бәрәңге, помидор, кыяр һ.б. җиләк-җимешләр үскән. Бакчаларында

уңыш һәр елны күп булу сәбәпле, әтиләре фәкыйрьләргә, мескеннәргә, ятимнәргә һәрвакыт гошерен чыгарган.

Бу елны да бакчаларында уңыш мул булган. Уллары әтисенә шатланып әйткән:

- Әй, әтиебез! Бакчабызда җиләк-җимешләребез быел да күп булды!



- Әлхәмдү-лилләһи улларым. Безгә биргән нигъмәтләре өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәргә тиешбез. Моның өчен Аллаһка бурычлыбыз.

Уңышны җыеп алганнан соң, йортларына гошер алучылар килгән:

- Әссәламү-галәйкүм, әй Әхмәд!

- Вәгаләйкүм-әссәлам вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү. Хуш киләсез! Әйдә түргә узыгыз. Мин сезне көтә идем инде. Гошер бит ул мескеннәрнең, ятимнәрнең, фәкыйрьләрнең хакы.

Әхмәд абый гошергә дип әзерләгән яшелчәләрне һәм җиләк-җимешләрен гошер алучыларга бирә. Гошер алучылар аңа Аллаһтан бәракәт теләп, рәхмәтләрен әйтеп чыгып китәләр. Боларны күреп торган уллары әтиләренә әйткәннәр:

- Әй, әтиебез, боларның бөтенесен аларга ни өчен бирдең?

Әтиләре:

- Динебез буенча, җыеп алган уңыштан (җиләк-җимештән) гошер чыгару тиеш ул, улларым. Аллаһы Тәгалә безне шушы гошер белән бәракәтләндерә, саранлык исә бәракәт китермәячәк, - дип әйткән.



Киләсе елда да уңыш мул үскән, ләкин әтиләре вафат булган. Инде уңышны җыеп алырга да вакыт җиткән. Уллары уйлый башлаган: иртәгә гошер алучылар килсә, без әтиебез кебек гошер чыгарырга тиешме? Юк... Алай эшләсәк безгә аз калыр, җыеп алган уңышка безнең хакыбыз күбрәк. Аларның берсе әйткән:

- Әйдә, алар килгәнче бакчабызга төнлә барыйк  һәм җиләк-җимешләрне җыеп алыйк.

- Әйдә, шулай эшлик, һәм моны алар килгәнгә кадәр тизрәк эшләргә кирәк! Җиләк-җимешләрне таң атканчы җыеп алыйк, алар безне күрмәсләр.

Абыйсы белән энесе төнлә бакчаларына килгәч ни күргәннәр соң?

-Әй, Аллам! Бу нәрсә?... Бакчабызга ни булган? Җиләк-җимешләребез кая киткән? Агачларыбызга нәрсә булган? - дигән Габдулла.

- Бу Аллаһның җәзасы... Без фәкыйрьләргә, мескеннәргә гошер сәдакасын бирергә теләмәгән идек. Без алдандык... Әтиебез шикелле аларның хакларын бирергә теләмәдек... Һичшиксез, бу саранлыгыбыз өчен Аллаһ безгә җәза бирде.

- Әйе... Без инде хәзер бернәрсәсез калдык. Без фәкыйрь булдык...

- Әй, Раббыбыз, безне гафу ит һәм фәкыйрьлеккә төшүдән коткар.

Менә шулай, гошер ул - малга бәракәт китерә торган һәм аны арттыра торган гамәл.

📖

И мөселман, кыйл гыйбадәт бу мөбарәк җомга көн,
Зикер илә калбең саф кыйл бу мөбарәк җомга көн.

Мәетләр дә җомгаларны бәйрәм диеп белерләр,
Балаларының ишегенә ул кичәдә килерләр.

Сәдака бирсә бер кеше һәр нәрсәдән бер микъдар,
Ничә мең савап язылыр бу мөбарәк җомга көн.

Сәдака бирмәсә бер кеше һәр нәрсәдән бер микъдар,
Рухлар китәр мәхрүм булып бу мөбарәк җомга көн.

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Синең якын туганнарыңнан кемдер булса зәкят биргәне булдымы? Алар зәкятне нәрсәдән, күпме һәм кемгә (кая) биргәннәрен сораштыр.
2. Зәкят яисә сәдака яки гошер бирү хакында Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисен язып кил.

## *В. Ураза*



Ислам дине нигезләренең дүртенчесе – Рамазан аенда ураза тоту. Ураза тоту ул - таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчы ашамый-эчми тору. Уразалы кеше таң җәелгәнче торып сәхәр ашый, ә кояш баткач, ахшам намазына азан әйтелгәч, хөрмә яисә йөзем белән ифтар кыла, ягъни авыз ача. Рамазан аенда Коръән уку, тәравих намазларын уку, сәдакалар өләшү һәм башка изгелекләр эшләү бик саваплы.

Аллаһы Тәгаләнең Китабы Коръән Кәримнән:

يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ

«Әй, иман китерүчеләр! Элек вакытларда иман китерүчеләргә әмер ителгәне кебек, тәкъвалыгыгыз артсын өчен, Рамазан аенда ураза тоту сезгә дә тиеш ителде».

*(Әл-Бәкара сүрәсе, 2/183)*

Мөхәммәд-Әмин мәктәптән кайтты. Кичке аштан соң балалары Мөхәммәд-Әмин, Мостафа һәм Зәйнәп бергә әтисе янына җыелдылар.

Мөхәммәд-Әмин әйтте:

- Әтием, кичә син ураза турында сөйләшербез дип вәгъдә биргән идең, онытмадыңмы?

- Ураза - кояш чыга башлаган вакыттан алып, кояш батканга хәтле ашаудан һәм эчүдән тыелу ул. Ураза тоту Исламның нигезләренә керә, аны тотарга көче булган һәр мөселманга ул фарыз була. Әгәр кеше Рамазан аенда авырып китсә, уразаны тотмас, ә калган көннәрен сәламәтләнгәннән соң тотар. Шулай ук, сәфәрдә булган кешегә дә, сәфәр вакытына уразасын калдырып, сәфәрдән кайтканнан соң уразасын тотып бетерергә рөхсәт ителә. Бик карт кешеләргә яисә сәламәтлекләре булмаган кешеләргә ураза тоту фарыз түгел, алар фидия бирерләр, ягъни бер көн өчен бер мескенне бер көн ашату, - дип аңлатты әтиләре.

- Әтием, мин аңладым, Аллаһы Тәгалә безгә нәрсә эшләргә кушса да, анда кешеләр өчен файда бар. Ураза тотуның нинди файдасы бар икән? – дип сорады Мостафа.

Әтисе әйтте:

- Бу бик яхшы сорау, улым. Ураза тоту безне Аллаһы Тәгаләгә сөекле булуыбызга китерә һәм Ул безнең кылган догаларыбызны кабул итә, гөнаһларыбызны кичерә. Ураза тоту сабыр итәргә гадәтләндерә, ихтыярны көчле итә, сәламәтлегебезне саклый.

- Коръән Кәримнең Рамазан аенда иңгәнен укытучымнан белгән идем. Ни өчен шулай икән?, - дип сорау бирде Зәйнәп.

Әтисе әйтте:

- Аллаһы Тәгалә Рамазан аен башка айларга караганда өстенрәк кылган, шул сәбәпле Коръән Кәримне иңдерү өчен Рамазан аен сайлаган.

- Әтием, нәрсәләр уразаны боза икән?, - дип сорады Мостафа.

Әтисе әйтте:

- Әгәр берәү Рамазан аенда көндез ризык ашаса-эчсә, аның уразасы бозыла.

Мөхәммәд-Әмин әйтте:

- Ураза тотуның әдәпләрен өйрәнер идем, әтием.

Әтисе сөенеп әйтте:

- Теләгең изге, улым. Ураза тотуның әдәпләре күп, сиңа кайберләрен санап күрсәтәм: нәфел намазларын арттыру, дога кылу, Коръән Кәримне күбрәк уку, кешеләр белән аралашуда әдәп-әхлаклы булу, кемдер сиңа начар сүз әйтсә, аңа шул ук сүз белән кайтармыйча, аңа: “Мин ураза тотам” дип әйтү.

Ураза әдәпләреннән кайберләре: кояш баткач, хөрмә белән авыз ачу, мохтаҗларга сәдака бирү.

### Изге Рамазан ае

Рамазан ае безгә – Аллаһның зур бүләге,
Укы намаз, тот ураза, ул бит Оҗмах терәге.

Күтәр, мөэмин, башыңны, намаз вакыты җитә,
Биш вакыт намаз укысаң, йөзең нурланып китә.


Көн саен сөенеп йөрим Кадер киче җитә дип,
Тагы кайгырып куям Рамазан ае үтә дип.

Изгелек эшләү фарыздыр һәр мөэмин-мөселманга,
Ураза тотсак, гамәл кылсак, әҗере булыр анда.

### ? Сораулар һәм күнегүләр:

1. Ураза тоту турында Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисен язып кил.
2. Рамазан аенда ураза тотканың бармы? Бу ай башка айлардан аерыламы? Рамазан ае турында хикәя сөйлә.

## *Г. Хаҗ*



Ислам дине нигезләренең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккә шәһәренә барып, Хаҗ кылу. Шушы Хаҗ үзе сәламәт булып, Мәккәи Мөкәррәмәгә барып кайтырлык юл чыгымнарына һәм үзе кайтканчы

өендә калганнарына яшәргә җитәрлек малы булган бай кешегә генә фарыз була. Авыру кешеләргә, сукыр кешеләргә һәм фәкыйрь кешеләргә Хаҗ фарыз түгел.

Хаҗ сәфәренә чыгу өчен юлларның тыныч булуы да шарт. Әгәр юллар тынычсыз булса, Хаҗ кылу фарыз булмас. Юллар тынычланганчы, бай кешеләргә дә, Хаҗ сәфәрен кичектерү дөрес булыр. Фарыз булганнан соң сәбәпсез Хаҗны кичектерү дөрес түгел.

Хаҗ гамәлләре, Мәккәи Мөкәррәмәдә һәм аның тирәсендә, һиҗри ел буенча Зөлхиҗҗә аеның 8-12 көннәрендә башкарыла.

## ? Сораулар һәм күнегүләр:

1. Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре кайсы илдә урнашканнар? Аларны картадан тап.

2. Киләсе дәрескә Кәгъбә рәсемен алып кил яисә аны альбом битенә ясап кил.

3. Бер-берсенә туры килгәннәрен тоташтыр:

| | |
|---|---|
| Исламның баганалары | Ике шәһадәт |
| Беренче багана | Мәккә шәһәре |
| Мохтаҗларга бирү | Биш |
| Ураза тоталар | Зякәт |
| Хаҗ кылалар | Рамазан |

## *Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- Ислам дине нәрсә икәнлеген;
- Мөэмин һәм мөселман дип кемгә әйтелгәнен;
- фарыз, важиб, сөннәт, хәрам аңлатмаларын һәм аларга керүче гамәлләрне.

**Исламның баганалары биш икәнен белдем:**

- Ике шәһадәт китерү;
- көненә биш тапкыр намаз уку;
- зәкят бирү;
- Рамазан аенда ураза тоту;
- хаҗ кылу.

**Бу бүлектән өйрәндем:**

- тәһарәт алырга;
- намаз укырга.



# 2-НЧЕ БҮЛЕК
## ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАЛАРЫ

### *1. Адәм галәйһис-сәләм пәйгамбәр*

Элек галәмдә Аллаһы Тәгаләдән башка, һичнәрсә юк иде. Соңыннан Аллаһы Тәгалә Үзенең Көч-Кодрәте белән, җир-күкләрне һәм алар арасында булган һәрнәрсәне алты көндә бар итә.

Шул мәхлукатлар арасында фәрештәләр һәм җеннәр бар иде. Фәрештәләрне Аллаһы Тәгалә нурдан ярата һәм алар Аның кушканнарын гына үтиләр, һичбер гөнаһ кылмыйлар, һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт итәләр. Җеннәрне уттан ярата һәм аларның кайберләре мөэминнәр, ә кайберләре кяферләр булалар.

Адәм галәйһис-сәләмне Аллаһы Тәгалә балчыктан ярата һәм аны бар иткәннән соң Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә, аңа ихтирам йөзеннән, сәҗдә кылырга әмер итә. Бөтен фәрештәләр дә аңа сәҗдә кылалар, ләкин алар арасында булган Иблис исемле җен генә сәҗдә кылмый.

Аллаһы Тәгалә әйтте: “Әй Иблис! Мин сиңа Адәмгә сәҗдә кылырга әмер иткәч, син ни өчен сәҗдә кылмадың?” Иблис әйтте: “Мин аңардан артыграк, чөнки мине уттан яраттың, Адәмне балчыктан яраттың”.

Иблис тәкәбберлеге аркасында кылган шушы гамәле өчен Җәннәттән чыгарылды, имансызлар дәрәҗәсенә төшерелде, Кыямәт көненә хәтле ләгънәтле, Ахирәттә мәңге Җәһәннәмле булды.

Иблис эшләгән гөнаһы өчен тәүбә итәргә дә теләмәде. Ул Адәм гәләйһис-сәләмгә һәм аның балаларына Кыямәт көненә кадәр дошман булып, туры юлдан яздырырга теләде. Бу хакта Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, ялварды. Аллаһы Тәгалә аңа кешеләрне туры юлдан авыштырырга ирек бирде, ләкин “Миңа иман китергәннәрне генә туры юлдан яздыра алмассың” дип әйтте.

Аллаһы Тәгалә, Адәм гәләйһис-сәләмгә иптәш булсын өчен, аның кабыргасыннан аңа хатын итеп Хәваны ярата.

Аллаһы Тәгалә Адәм гәләйһис-сәләм белән Хәваны Җәннәткә кертеп, андагы нигъмәтләр белән ләззәтләнергә рөхсәт бирә. Бары тик бер агачның җимешләрен генә ашауларын тыя. Иблис исә, аларны хәйлә белән алдалап, тыелган агачтан ашата. Алар ялгышып хата эшләгәннәрен аңлагач, Раббыларыннан гафу сорап тәүбә итәләр. Аллаһы Тәгалә аларның бу тәүбәләрен кабул итә.

Соңыннан алар Җәннәттән чыгарылып җиргә төшерелә. Адәм гәләйһис-сәләм Һиндстан җиренә, ә Хәва хәзерге Согуд Гарәбстанның Җиддә шәһәре тирәсенә төшә. Адәм гәләйһис-сәләм Хәваны эзләп Мәккә җирләренә килә һәм алар Мөздәлифә тирәсендә кавышалар. Бу хәлгә алар бик сөенәләр һәм Аллаһы Тәгаләгә шөкрана кылалар.

Җәннәттән сөрелгән Иблис исә, җирдә кешеләрне туры юлдан яздырып йөри башлый. Иблис һәм аның гаскәре булучы шайтаннар кешеләрне туры юлдан яздыруда зур тәҗрибә туплаганнар.

Аларга каршы тору өчен кешеләргә аларның мәкерлекләрен белү кирәк. Аллаһы Тәгалә, аларга каршы корал булarak, кешеләргә Үзенең дин хөкемнәрен иңдереп торган. Шуның өчен иман һәм дин юлында булучылар гына Иблиснең мәкерлекләреннән саклана ала.

Көннәр, айлар, еллар уза. Адәм гәләйһис-сәләм белән Хәваның балалары туа. Алар үзләренең матур итеп яшәүләренә бик сөенәләр. Иблис исә, үзенең мәкерлекләрен тормышка ашырырга тели.

Адәм гәләйһис-сәләмнең Кабил исемле олы улы үзенең игезәк кыз туганына өйләнергә сорый. Ләкин Аллаһы Тәгалә Адәм гәләйһис-сәләмгә Кабилне Һәбилнең игезәк кыз туганына, ә Һәбилне Кабилнең игезәгенә өйләндерергә дип белгерткән иде.

Һәбил Аллаһы Тәгаләнең шушы әмеренә буйсына һәм риза була. Иблис моннан файдаланып, туганнар арасына дошманлык салмакчы була. Кабил энесенә каршы мәкерлек уйлый башлый. Адәм гәләйһис-сәләм, уллары арасындагы шушы хәлне белеп, аларга Аллаһы Тәгаләгә корбанлык китерергә куша. Ул: “Кемнең корбаны кабул булса – кыз шуныкы булыр”, - дип әйтә.

Кабил бик начар, бозылган җимешләрне алып килә, Һәбил иң яхшы сарыктан корбан бирә. Аллаһы Тәгалә Һәбилнең корбанын кабул итә, ә Кабилнекен кабул итми.

Кабилнең корбаны кабул булмагач, Һәбилгә карата тагы да ачулы булып, ул энесен үтерергә уйлый. Һәбил моны белеп алып, абыйсын бу эшеннән тыелырга үгетләп карый. Кабил аның сүзләренә игътибар бирмичә, шайтанның вәсвәсәсенә бирелеп, энесен үтерә. Иблис, мәкерлеге белән Кабилне

шушы эшкә этәрә алганы өчен, аңардан явыз рәвештә көлә. Кабил эшләгән гөнаһына бик үкенә һәм мәетне кая куярга белмичә, берничә көн күтәреп йөри. Шунда Аллаһы Тәгалә аңа карга җибәрә. Ул Кабилгә җирне казып күрсәтә. Карганың, җирне казып күмүен күргәч, Кабил дә җирне казып Һәбилне күмә.

Шулай итеп, җир йөзендә иң беренче кан түгелә. Бу җинаятьне шәйтан вәсвәсәсенә бирелеп Кабил ясый.

### Бу кыйссадан алган файдалар

- Һәрбер нәрсә Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән барлыкка килә.
- Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне нурдан, җеннәрне уттан, кешене балчыктан ярата.
- Фәрештәләр Адәм галәйһис-сәләмгә хөрмәт итү сәҗдәсен кылалар.
- Аллаһы Тәгаләгә буйсынмау – Аның рәхмәтеннән ерагаюга сәбәп була.
- Әгәр берәр гөнаһ эшләнсә, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итеп, Аннан гафу итүен сорау.
- Мөселманнарга Иблиснең һәм аның гаскәре булучы шайтаннарның мәкерлекләреннән уяу булу кирәк.

## *2. Нух гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Нух гәләйһис-сәләмнең халкы ташлардан ясалган сыннарга табына иде. Аллаһы Тәгалә Нух гәләйһис-сәләмгә аларны ялгыз бер Аллаһка гына гыйбәдәт итүгә чакырырга куша. Ләкин алар аны кире кагалар, аңа каршы чыгалар, аны һәм аның белән булучы мөэминнәрне мәсхәрә итәләр, алардан көләләр.

Нух гәләйһис-сәләмнең үзенең халкын иманга чакыруы 700 елдан артык көне-төне дәвам итә. Шуңа карамастан, иман китерүчеләрнең саны бик аз була.

Халкының хак юлны кабул итмәвенә Нух гәләйһис-сәләм бик нык кайгыра. Алар аңа итагать итмиләр, аңа иярүгә каршы чыгалар, нәтиҗәдә имансызлардан булалар. Нух гәләйһис-сәләмнең кайгысы тагы да арта.

Халкының аны шулай мыскыл итүе, аннан көлүе Нух гәләйһис-сәләмгә бик авыр була һәм ул Раббысыннан шул хакта сорый. Аллаһ аңа зур көймә төзергә әмер итә. Нух гәләйһис-сәләм аны төзи башлый, аңа бу эштә мөэминнәр дә ярдәм итәләр. Көймәне эшләү озакка сузыла.

Кяферләр Нух гәләйһис-сәләмнең яныннан узган саен аны һәм аның белән булучы мөэминнәрне мыскыл итеп көләләр иде, чөнки ул тирәдә су юк иде.

Кяферләрнең көлүенә Нух гәләйһис-сәләм сабыр итте һәм аларны: “Аллаһы Тәгаләнең газабыннан көймәгә кергән мөэминнәр генә котылачаклар”, - дигән сүзләр белән кисәтә иде. Моны ишеткән кяферләрнең көлүләре һәм мыскыл итүләре арта гына иде.

Көймә төзелеп беткәч, Аллаһы Тәгалә Нух гәләйһис-сәләмгә мөэминнәр белән бергә көймәгә утырырга һәм хайваннарның, кошларның, үсемлекләрнең һәр җенесен (бер пар малай-кыз) алырга куша. Боларның бөтенесе, туфан тәмамлаганнан соң яңа тормыш башлап җибәрер өчен кирәк иде.

Нух гәләйһис-сәләм Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәп көймәгә утыра. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә күкләргә яңгыр яудыруны һәм җиргә суларны күп итеп чыгаруны куша. Су ташкын булып ага, күтәрелә башлый. Көймә хәтта су уртасында кала.


Кяферләр бу күренештән бик куркып, ярдәмгә чакыра башлыйлар һәм Нух гәләйһис-сәләмнең сүзләре дөрес булганын аңлыйлар. Шиксез, Аллаһы Тәгаләнең вәгъдәсе хак.

Нух гәләйһис-сәләм үзенең улын Аллаһы Тәгаләгә иман китерергә һәм көймәгә утырырга чакыра. Улы әтисенең сүзләрен кире кагып: “Мин тауның иң биек урынына менәрмен һәм анда хәтле су җитмәс”, - дип әйтә. Туфан күтәрелеп аны йота. Ул батып вафат була (калган кяферләр суда батканы шикелле). Бөтен җирне су баса.

Аллаһы Тәгалә күкләргә яңгырны яудыруны һәм җирләргә суны чыгаруны туктатырга куша. Көймә бәрәкәтле җирнең ярында туктый. Нух гәләйһис-сәләм, мөэминнәр һәм хайваннарның, кошларның, үсемлекләрнең һәр җенесе дә җиргә төшәләр. Нух гәләйһис-сәләм һәм мөэминнәр Аллаһы Тәгаләгә, аларны коткарганнары өчен, шөкер кылалар һәм Аллаһы Тәгаләнең ялгыз бер Үзенә генә гыйбәдәт кылып яши башлыйлар.

## *Бу кыйссадан алган файдалар*

- Нух гәләйһис-сәләм иманга чакыруда бик күп авырлыклар һәм кыерсытуларга дучар булса да, сабыр була һәм өметсезлеккә бирелми.
- Нух гәләйһис-сәләм үзенең халкын 700 елдан артык иманга чакыра.
- Аллаһы Тәгалә Нух гәләйһис-сәләмнең халкын, иман китермәгәннәре өчен, туфан белән һәлак итә.
- Нух пәйгамбәр көймәгә хайваннарның, кошларның, үсемлекләрнең һәр җенесен (малай-кыз) алуы, туфан тәмамлаганнан соң яңа тормышны башлап җибәрү өчен иде.
- Аллаһы Тәгалә мөэминнәрне, Аллаһ юлында булучыларны коткаруын һәм аларга дошманнары өстеннән җиңү бирүен.
- Аллаһы Тәгаләгә һәрвакыт шөкер итәргә кирәклеген.



# 3-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘД ﷺ НЕҢ ТОРМЫШЫННАН

### *1. Мөхәммәд ﷺ нең гаиләсе*

| | |
|---|---|
| Әтисе: | Габдулла |
| Әнисе: | Әминә Вәһаб кызы |
| Бабасы: | Габдул-Мотталиб |
| Сөт анасы: | Хәлимә |
| Әтисенең абыйсы: | Әбү Талиб |

Мөхәммәд ﷺ Мәккә шәһәрендә, миляди белән 571 нче елда туган һәм бу ел “Фил елы” дип аталган.

Әйдәгез, белик әле, Фил елынданиләр булганын.

### *2. Фил вакыйгасы*

Кәгъбәтулла Мәккә шәһәрендә урнашкан. Кәгъбәтуллага кешеләр хаҗ кыла торган булганнар. Кешеләр Кәгъбәтуллага түгел, ә монда килеп хаҗ кылсыннар дип, Йәмән патшасы Әбраһа үз җирендә бер гыйбадәтханә салдырта. Ләкин кешеләр Әбраһа салдырган бинага хаҗ кылырга килмиләр. Моңа Әбраһаның бик каты ачуы килә. Ул гаскәр җыя һәм Мәккәгә барып Кәгъбәтулланы җимерергә тели. Гаскәрдә филләр дә була. Ул вакыт өчен филләр булу гаскәрнең бик көчле икәнлеген күрсәткән. Гаскәр Мәккәгә юл тота. Аллаһы Тәгалә шушы Әбраһаның үзен һәм аның гаскәрен һәлак итү өчен, алар өстенә бик күп кошлар җибәрә. Кошларның һәрберсендә өчәр

кечкенә таш була: берсе – томшыгында, икесе – аякларында. Кошларның күплегеннән күк кап-кара була, хәтта күк үзе күренми. Әбраһа гаскәре турысына җиткәч, кошлар ташларын ычкындыралар. Бу ташлар эләккән кешеләрнең барчасы да һәлак була. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә Кәгъбәтулланы җимерелүдән саклый.

## *3. Мөхәммәд ﷺ нең бала чагы*

Пәйгамбәребез ﷺ дөньяга килгәнче үк аның әтисе Габдулла вафат була. Ул туганда әтисенең вафат булганына ике ай үткән була. Әнисе Әминә аны Хәлимә исемле сөт анасына имезергә тапшыра. Хәлимә Мөхәммәд ﷺ не ике ел буена хәләл сөтен имезеп тәрбияли.

Алты яшенә кадәр әнисенең янында була. Бер көнне әнисе белән Мәдинә шәһәренә әнисенең туганнарына кунакка баралар. Шунда әтисенең каберен дә карап китәләр. Кунактан кайткан вакытта, Әбва исемле авылга килеп җиткәч, әнисе авырып китә һәм вафат була. Әнисе бу дөньядан киткәндә Пәйгамбәребез ﷺ гә нибары 6 яшь кенә була. Бу хәлдән соң ул дәү әтисе Габдул-Мотталибта яши башлый. Ләкин ике елдан соң дәү әтисе дә вафат була. Бу вакытта Пәйгамбәребез ﷺ гә 8 яшь кенә иде.

## *4. Мөхәммәд ﷺ Әбү Талибның тәрбиясендә*

Дәү әтисенең вафатыннан соң Мөхәммәд ﷺ не абыйсы Әбү Талиб алды. Ул әтисенең абыйсы иде. Әбү Талиб аны ﷺ үз балаларыннан да күбрәк ярата, яныннан һич җибәрмәс иде. Берара ул ﷺ көтүче булып, абыйсының сарыкларын көтте. 13 яшьләр тирәсен-

дә абыйсы белән бергә Мәккә шәһәреннән сәүдә өчен Шамга барырга юлга чыкты. Алар Бусра исемле шәһәргә юнәләләр. Анда Бәһира исемле бер галим булып ул күп китаплар укый иде. Укыган китапларыннан яңа пәйгамбәр киләчәген, аның исеменең Әхмәд икәнлеген белә, һәм хәтта кайбер галәмәтләрен дә чамалый иде.

Бер көнне Бәһира ут кебек көйдерүче кайнар чүл эсселегендә күк йөзендә бер болыт күрә. Урынында басып тора алмас хәлгә килә. Ни күзе белән күрсен: шул болыт бер төркем юлчылар белән килә, юлчылар барса-бара, туктаса-туктый. Бу хәлне күргәч, Бәһираның гаҗәпләнүе тагы да арта. Ул юлчыларны өенә чакыра. Мөхәммәд исә дөяләр янында калганлыктан, Бәһира янына керми.

Бәһира бер карады, ике карады – болыт килми. Шуннан Мөхәммәд ﷺ не дә чакырта. Болытның да ﷺ белән бергә килгәнен күргәч, телсез кала. Пәйгамбәребез ﷺ килгәч, аның аркасын ачып карый. Ике калак сөяге арасында пәйгамберлек мөһерен күреп, аны үбә. Шуннан соң Әбү Талибка сәяхәтне дәвам итмәскә киңәш бирә. Алар кире Мәккәгә кайтып китәләр.

Мөхәммәд ﷺ шулай ук сәүдә белән дә шөгыльләнә. Аның ﷺ һәр хәрәкәте дөрес, һәр сүзе тугры була. Һәркемнең хисапсыз сөюен яулый. Мәккә халкы, шул тугрылыгы өчен, аңа ﷺ гә "Әмин" (ягъни "Ышанычлы") дигән исем бирә.

Мәккә шәһәрендә тудың,
Атаң иде Габдулла,
Анаң иде Әминә,
Йә Мөхәммәд Мостафа!

Атаң-анаң вафаты
Сине ятим калдырды,
Сине Аллаһ үстерде,
Йә Мөхәммәд Мостафа!

## *Бу бүлектән белгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- Мөхәммәд ﷺ нең гаиләсен.
- Пәйгамбәр ﷺ нең туган елын һәм үскән җирен.
- Пәйгамбәр ﷺ туачак елда булган “Фил вакыйгасын”.
- Мөхәммәд ﷺ нең бала вакытын.
- Мөхәммәд ﷺ нең абыйсы Әбү Талибта тәрбияләнгәнен.
- Мөхәммәд ﷺ нең “Әмин” (ягъни “Ышанычлы”) дигән исеме булуын.



# 4 -НЧЕ БҮЛЕК

## МӨСЕЛМАН БАЛА ТӘРБИЯЛЕ БУЛЫП, АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ СӨЙГӘННӘРНЕ ЭШЛИ

بسم الله الرحمن الرحيم

### *1. «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен әйтү*

Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли һәм һәр эш алдыннан «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен әйтә: ашар алдыннан, өйдән чыгар алдыннан, урамда йөргәндә, дәрес алдыннан, йоклар алдыннан һ.б.

Телне ачтык иртән "Бисмиллә" дип,
Йөзне борып Кыйбла ягына.
Аллаһы Тәгаләнең биргән көнен зурлап,
Иман нуры җанда кабына.

*Госман Садә*

Аллаһның исемен әйтүнең бәракәте:

- Аллаһның исемен әйтеп йөрмәүче гамьсез бала белән шайтан бергә йоклый да, аның ризыгын да ашый.
- Аллаһның исемен әйтеп йөрүче яхшы бала белән шайтан кунмый да, ризыгын да ашамый.

**Мөселман һәр эш алдында «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен әйтә.**






## 2. Сәламләшү

Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли һәм башка мөселман кардәше белән очрашканда «Әс-сәламү галәйкүм», ә сәлам алучы «Вә галәйкүмүс-сәлам» дип сәламләшә. Шулай ук сәлам бирүче «Әс-сәламү галәйкүм вә рахмә-тул-лаһи вә бәракә-түһү», ә сәлам алучы «Вә галәй-күмүс-сәлам вә рахмәтул-лаһи вә бәракәтүһү» дип тә сәламләшергә мөмкин. Сәлам биргәндә бер-берләренең кулларын кысарлар.

Сәлам – сәламәтлек, тынычлык, исәнлек яисә бер нәрсәнең яхшы һәм хәерле булуын теләү дигәнне аңлата.

Сәламләшү - иң яхшы гадәтләребезнең берсе. Өйдә, урамда, мәктәптә, юлда – кайда гына булмасын, бер мөселман икенче мөселман кардәше белән очрашканда, аларның сәламләшүе күркәм гамәлләрдән санала.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: “Арагыздагы җылылыкны арттырачак нәрсәне сезгә белдеримме? Арагызда сәлам таратыгыз”.

Сәлам бирү тәртибе:

- басып торган яисә барган кеше утырган кешегә беренче сәлам бирер;
- аз кеше күп кешегә беренче сәлам бирер;
- яшьрәкләр олыракларга беренче сәлам бирерләр, шулай ук олыраклар, яшьрәкләрне сәламгә күндерер өчен, аларга беренче булып сәлам бирерләр.

Динебез буенча түбәндәге хәлдә кешеләргә сәлам бирелмәс:

- намаз укып утырган кешегә;

- Коръән укыган кешегә;
- вәгазь сөйләгән имамга;
- аракы эчеп утыручыларга;
- бәдрәфтә булган кешегә.

Бер кеше аркылы безгә җибәрелгән сәламгә дә "Вә галәйкүмүс-сәлам" дип җавап бирү кирәк. Кем дә булса берәр кешегә сәлам җибәрсә, ул сәламне иясенә тапшырырга кирәк, чөнки бу сәлам – бер әманәттер.

**Мөселманнар һәрвакыт сәламләшәләр һәм шуның белән бер-берсенә тынычлык, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен һәм бәрәкәтен телиләр.**

## *3. Әтием һәм әнием*

Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли һәм үзенең әти-әнисенә итагать итә, аларның икесен дә ярата, аларны хөрмәтли һәм аларга чын күңелдән хезмәт итә.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Әти-әниләрен риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр".

Синең әниең ул:

- сине үзенең карынында 9 ай буе күтәреп йөргән;
- сине тудырганда зур авырлыклар кичергән;
- үзенең күкрәк сөтен озак вакыт имезгән;
- сине бик ярата һәм сиңа карата бик тә шәфкатьле иде;
- син аннан ризыклана идең;
- синең тәнеңне, киемнәреңне, йоклый торган урыннарыңны чистарта, синең уңышларыңа шатлана,

- авырып киткән вакытыңда бик борчыла һәм төн йокыларын калдыра иде.

📖

**Ана**

И бала! Әнкәң сине
Ярата, сөя, бәбкәм бу, ди;
И ике күзем нуры,
Җаным бу, ди, чәчкәм бу, ди.

Тәрбия кыйлды сине ул–
Син үзең белми идең;
Күп вакыт елый идең,
Йоклый идең, көлми идең.

Йокыларны калдырып
Синең өчен караңгы төн,
Әллә ничә уянып
Биргән сиңа күкрәк сөтен.

Ниндәен шатланды әнкәң,
Син тәпили башлагач;
Шатлыгы бергә-бер артты,
Син "әни" ди башлагач.

Син укырга башлагач,
Бу елда мәктәпкә барып,

Әнкәң артыңнан карап
Калды сиңа шатланып.

Син дә инде бу газиз
Әнкәңне шатландыр, балам;
Ул көтәдер бит сине:
“Укып-белеп кайтыр, балам”.

*Мәҗит Гафури*

Синең әтиең ул:

- сиңа һәм абый-энеләреңә, апа-сеңелләреңә ризык һәм кием алыр өчен тырышып эшләүче;
- гаилә башлыгы;
- сине укытуда һәм киләчәгең өчен тырышучы;
- сине яратучы һәм сиңа шәфкатьле булучы.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ каршына бер ир кеше килеп, аңа сорау бирде: Әй, Аллаһның Рәсүле, кемнең үзенә карата яхшы мөгамәлә таләп итәргә хакы зуррак? Рәсүлүлла әйтте: - Әниең. Ул әйтте: - Аннан соң кем? Рәсүлүлла әйтте: - Әниең. Ул әйтте: - Аннан соң кем? Рәсүлүлла әйтте: - Әниең. Ул әйтте: - Аннан соң кем? Рәсүлүлла әйтте: - Әтиең.

Әти-әнием алдындагы бурычларым:

- әти-әниемә итагать итү;
- әти-әниемә ярдәм итү;
- өйдән чыгар алдыннан алардан рөхсәт сорау;
- алар алдында тавышымны югары күтәрмәү;

- киемемне һәм әйберләремне саклау;
- торган урынымны һәм җиһазларны тәртиптә вә чисталыкта тоту;
- бөтен нәрсәләрне үз урыннарына кую.

**Шиксез, әти-әнисен яраткан баланы һәм аларга итагать иткәнне Аллаһы Тәгалә дә ярата.**

## *4. Туганнарым һәм якыннарым*

Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли һәм туганнарын, якыннарын ярата. Туганнар ата-аналардан соң иң якын кешеләр. Шуның өчен:

- алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле була;
- туганнарының һәм якыннарының ярамаган берәр эшен күрсә, яхшы сүз белән: «Болай эшләргә ярамый», - дип, ул эшнең ярамаганлыгын әйтә;
- алар өстеннән әти-әниләренә әләкләми;
- аларга һәрвакыт ярдәмче була;
- аларның серләрен саклый, башкаларга аларны яманлап йөрми, аларга карата ачык йөзле һәм киң күңелле була.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: «Кем ризыгының арттыруын һәм гомеренең озынайтуын теләсә, шул якыннары белән туганлык җепләрен өзмәсен».

**Мөселман үзенең туганнарын һәм якыннарын яратып, алар белән һәрвакыт очрашып тора.**

## 5. Кардәшләрем (дусларым) һәм күршеләрем

Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли һәм ул кардәшләрен (дусларын) һәм күршеләрен хөрмәт итә. Кардәшләр (дуслар) алар ата-аналардан һәм туганнардан соң иң якын кешеләр. Шуның өчен мөселман баласы:

- кардәшләре (дуслары) белән күркәм мөгамәләдә була;
- кардәшләренә (дусларына) сәлам бирә;
- дусты мәктәпкә килмәсә, аның турында сораша;
- кардәшләре (дуслары) авырсалар, хәлләрен белешә;
- кардәшләренә (дусларына) ярдәм итә;
- шатлык һәм кайгыларын уртаклаша.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтте: “Сезләрдән берегез дә мөэмин булмас, үзе яраткан нәрсәне кардәше өчен дә яратмаса”.

Күршеләр алар кардәшләрдән (дуслардан) соң иң якын кешеләр. Шуның өчен мөселман баласы:

- күршеләре белән һәрвакыт яхшы мөгамәләдә була;
- күршеләрен сөя;
- күршеләре белән дус һәм тату тора;
- күршеләренә ярдәм итә;
- күршеләренең тәрәзәләреннән өй эченә һәм койма ярыкларыннан карамый;
- һәрбер эштә аларның хәтерләрен калдырмый;
- авырып киткән күршесенең хәлен белешә;
- күршеләренә авырлык китерми.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтте: “Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән кеше күршесен рәнҗетмәсен”.

**Әгәр синнән дустың берәр нәрсә сораса, аңа сораган әйберне бир.**

## *Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем*

**Бу бүлектән мин белдем:**

- “Бисмилләһир-рахмәнир-рахим” сүзләрен һәрвакыт әйтеп йөрергә кирәк икәнлеген.
- Сәлам бирүче «Әс-сәламү галәйкүм» дип әйтергә, ә сәлам алучы «Вә галәй-күмүс-сәлам» дип кайтарырга тиешлеген.
- Сәлам биргәндә бер-берләренең кулларын кысуларын.

**Шулай ук:**

- Әти һәм әниемне яратырга, аларга итагать итәргә икәнлеген.
- Туганнарымны һәм якыннарымны яратырга, алар белән яхшы мөнәсәбәттә булырга икәнлеген.
- Кардәшләремне (дусларымны) һәм күршеләремне сөяргә, алар белән әйбәт булырга һәм аларга ярдәм итәргә кирәк икәнлеген.

**Бу бүлектән мин өйрәндем:**

- “Бисмилләһир-рахмәнир-рахим” сүзләрен.
- «Әс-сәламү галәйкүм» һәм «Вә галәй-күмүс-сәлам» сүзләрен.

# 5-НЧЕ БҮЛЕК
# ИСЛАМ ӘДӘПЛӘРЕ ҺӘМ ДОГАЛАРЫ

## *1. Ашау әдәпләре һәм догалары*

Мөселман бала Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт истә тотып, әдәпле була һәм ашаганда түбәндәге кагыйдәләрне үти:

- ашарга утырыр алдыннан кулларын юа;
- ризыкны ашыйсы килгәндә генә ашый, ашап туйгач та ашказанын артыгы белән тутырмый;
- ашар алдыннан дога укый:

اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِي مَا رَزَقْتَنَا وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيمِ

*(Әл-Лааһүммә бәәрик ләнәә фии мәә разәктәнәә вә кынәә гәзәәбәннәәр. Бисмил-Ләәһир-рахмәәнир-рахиим)*

Мәгънәсе: “Әй Аллаһ, ризыкландырган нәрсәләребездә бәрәкәт бир һәм Җәһәннәм газабыннан сакла. Шәфкатьле һәм Рәхимле Аллаһ исеме белән башлыйм”.

- ашар алдындагы доганы әйтергә онытса, исенә төшергәч тә шушы доганы укый:

بِسْمِ اللهِ فِي الأَوَّلِ والآخِرِ

*(Бисмил-Ләһи фил-әввәли вәл-әхыри)*



Мәгънәсе: “Аллаһ исеме белән ашау алдыннан да, ашап бетергәндә дә”.

- ашаган вакытта уң кулы белән ашый һәм эчә;
- әгәр ризыкны таба белән бирсәләр, үз каршысыннан гына ала;

- авызны ризык белән артык тутырмый, чәйнәп ашый, чәйнәмичә йотмый;
- ризыкны чәйнәгән арада сөйләшми, сөйләшкән вакытта ризыгы авызыннан чәчрәмәсен өчен, чәйнәп бетергәч кенә теләгән сүзен әйтә;
- ризыкны ашаганда яисә су эчкәндә, утырып ашый һәм эчә, ә баскан һәм йөргән килеш түгел;
- ашаганнан соң дога кыла:

الحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي أَطْعَمَنَا وَسَقَانَا وَجَعَلَنَا مِنَ الْمُسْلِمِينَ

*(Әлхәмду лил-Ләәһил-ләзии әтгәмәнәә вә сәканәә вә җәгәләнәә минәл-мүслимиин)*

Мәгънәсе: "Безне ризыкландырган һәм мөселманнардан кылган Аллаһка барча мактаулар".



- әти-әнисенә (яки пешерүчегә): "Аллаһның рәхмәте яусын", - дип әйтә;
- ашаганнан соң кулларны юа, авызны чайкый.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Сәхабәләрнең берсе, кечкенә вакытында, Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ белән бергә бер табында булган. Ул бала табактагы ризыкны кулы белән төрле җирдән ала торган булган. Ашавы тәртипсез икән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ аңа әйткән: "Әй, бала! Аллаһның исемен әйт, уң кулың белән һәм алдында булганны аша".

### Ябык шайтан белән симез шайтан

Бервакыт ябык шайтан белән симез шайтан бергә очрашалар. Симез шайтан ябык шайтанга әйтә:

- Әй, дустым! Ни өчен бу кадәр ябык йөрисең?

Ябык шайтан әйтә:

- Әй, кардәшем! Мин бер мөселман кешегә билгеләнгән идем, ул һәр эшендә: ашаганда да, эчкәндә дә, йокларга ятканда да һәм башка бөтен эшләрендә дә «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип әйтә. Шул сәбәпле, ашамый-эчми калам һәм күрәсең, бөтенләй ябыгып беттем.

Симез шайтан әйтә:

- Әй, дустым! Синең хәлең бигрәк кызганыч. Ә мин шундый бер гамьсез бәндәгә билгеләнгән идем: «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» сүзләрен һичбер вакытта әйтми, өенә кергәндә муенына атланып керәм, аның белән бергә ашыйм, эчәм, йоклыйм һәм башка бөтен эшләрендә катнашам. Шул сәбәпле симереп беттем.

## *2. Бәдрәфкә керү әдәпләре һәм догалары*

Мөселман бала Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт истә тотып, әдәпле була һәм бәдрәфкә кергәндә түбәндәге әдәпләрне үти:

- Бәдрәфкә кергәндә Аллаһы Тәгалә исеме язылган значок, балдак, муенса һ.б. нәрсәләрне салып керә, югалу куркынычы булган очраклардан башка.
- Бәдрәфкә керер алдыннан түбәндәге сүзләрне әйтә:

بسم اللهِ اللهُمَّ إنِّي أعُذُ بِكَ مِنَ الْخُبْثِ وَالخَبَائِث

*(Бисмил-Ләәhи. Әл-Лааhүммә инниі әгүзү бикә минәл-хубси вәл-хабәәис)*

Мәгънәсе: “Аллаh исеме белән башлыймын. Әй Аллаh, шиксез мин Сиңа фәхешлек нәрсәләрдән һәм бозык эшләрдән (яисә явыз һәм пычрак көчләрдән) сыгынам”.

- Бәдрәфтән чыкканда түбәндәге сүзне әйтә:

غُفْرَانَكَ *(Гуфраанәкә)*

Мәгънәсе: “Синең кичерүеңне үтенеп сорыйм”.

- Бәдрәфтә хаҗәтне үтәгәндә, Кыйблага ал яисә арт белән утырмый.
- Бәдрәфтә Аллаhы Тәгаләнең исемен әйтми, сәламләүгә җавап бирми һәм сөйләшми, ягъни тынлык саклый.
- Хаҗәтне үтәгәндә кешеләр күзеннән саклана.
- Хаҗәтләрне баскан көенчә түгел, ә утырган килеш үти.
- Хаҗәтне үтәгәннән соң әгъзаларны су белән әйбәтләп юып ала һәм әгъзаларны юганда сул кул белән юа.
- Бәдрәфкә кергәндә сул аяк, ә чыкканда уң аяк белән беренче адымны ясый.
- Хаҗәтләрне кешеләр йөри торган юлларда, су коенган урыннарда (күлләрдә, елгаларда) башкармый.
- Бәдрәфтән соң кулларны сабынлап юа.

## *3. Дәрес алу әдәпләре һәм укыла торган догалары*

Мөселман бала Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт истә тотып, әдәпле була һәм дәрес алган вакытында тиешле тәртипләрне саклый:

- Дәрес алу урынына (мәктәпкә) иртәрәк бара, дәресләргә соңга калып йөрми һәм әдәп белән үз урынына утыра.
- Дәрес укудан әүвәл шушы доганы укый:

اللهمَّ ارْزُقْنَا عِلْمًا نَافِعًا وحِفْظًا كَامِلاً وَذِهْنًا شَامِلاً وَفَهْمًا ذَكِيًّا وَتَوْفِيقًا لِتَحْصِيلِ الْعُلُومِ. اللهمَّ أخْرِجْنَا مِنْ ظُلُمَاتِ الْجَهْلِ وَالْوَهْمِ وَأكْرِمْنَا بِنُورِ الْعِلْمِ وَالْفَهْمِ. اللهُمَّ افْتَحْ لَنَا أبْوَابَ عِلْمِكَ وَانْشُرْ عَلَيْنَا خَزَائِنَ رَحْمَتِكَ. بِرَحْمَتِكَ يَا أرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

*(Әл-Лааһүммә-рзүкнәә гилмән нәәфигән вә хифзән кәәмилән вә зиһнән шәәмилән вә фәһмән зәкиййән вә тәүфиикан литәхсыйлил-гүлүүм. Әл-Лаһүммә әхриҗнәә мин зулүмәәтил-җәһли вәл-вәһми вә әкримнәә бинүүрил-гилми вәл-фәһми. Әл-Лаһүммә-фтәх ләнәә әбвәәбә гилмикә вән-шүр гәләйнәә хазәәинә рахмәтик. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин)*

Мәгънәсе: “Я Рабби, безгә файдалы гыйлемлекне һәм күңелгә тәмам алуны һәм киң зиһенне һәм зирәк аңлауны насыйб ит. Я Рабби, безне наданлык һәм күңел караңгылыгыннан чыгарып, гыйлем һәм аңлау нуры белән хөрмәтлә. Я Рабби, безгә гыйлемлек ишекләрен ач һәм рәхмәт хәзинәләреңне чәч. Әй камил рәхмәт кылучы Аллаһ, һәрбер нәрсә Синең рәхмәтең белән генә булыр”.

- Дәрес уку тәмам булганнан соң шушы доганы укый:

الحَمْدُ للهِ الَّذِى أخْرَجْنَا مِنْ ظُلُمَات الجَهْلِ وَالوَهْمِ. وَنَوَّرَ قُلُوبَنَا بِنُورِ الْعِلْمِ وَالفَهْمِ. اللهُمَّ اغْفِرْ لَنَا وَلِوَالِدَيْنَا وَلِأُسْتَاذِنَا وَسَلِّم دِينَنَا وَاجْعَلْ مَلِكَنَا سَالِمًا وَرَؤُفًا لَنَا بِحَقِّ نَبِيِّنَا محمدِ الْمُصْطَفَى صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ.

*(Әлхәмду лил-Ләәhи-ллэзии әхраҗнәә мин зулүмәәтил-җәhли вәл-вәhми. Вә нәввәра кулүүбәнәә бинүүрил-гилми вәл-фәhми. Әл-Лаhүммәгфир ләнәә вә ли-вәәлидәйнәә вә ли-үстәәзинәә вә сәллим диинәнәә вә-җгәл мәликәнәә сәәлимән вә раүфән ләнәә бихәккы нәбиййинәә Мүхәммәдинил-Мүстафәә салләл-Лааhү гәләйhи вә сәлләм)*

Мәгънәсе: “Һәрбер мактау Аллаһы Тәгаләгә хас. Ул Аллаһы Тәгалә безне наданлык һәм аңламаулык караңгылыгыннан чыгарды һәм шулай ук безнең күңелләребезне гыйлем һәм аңлау нуры белән нурландырды. Я Рабби, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа ﷺ хакына безнең гөнаһларыбызны һәм шулай ук ата-ана һәм остазларыбызның гөнаһларын кичер, динебезне дә, дөньябызны да төзек һәм сәламәт кыйл һәм шулай ук патшабызны сәламәт һәм безгә шәфкатьле вә мәрхәмәтле кыйл”.

- Китап, дәфтәр һәм башка язу әсбапларын чиста тота.
- Дәрес алу урынына (мәктәпкә) кергәч аяк киемнәрен алыштыра, өс киемнәрен (курткаларын) билгеле урынга куя, укытучыга һәм укытучы иптәшләренә ачык йөз белән сәлам бирә.
- Укытучы бирә тора торган дәрескә күңелен сала, һәрбер сүзен зиһененә урнаштыра, дәрес вакытында сөйләшми.
- Укытучы сораганда аяк үрә торып ачык тавыш белән җавап бирә.

- Укытучы берәр нәрсәне укырга, язарга яки ятларга кушса, җиренә җиткереп үти.

## *Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- Ашау әдәпләрен.
- Бәдрәфкә керү әдәпләрен.
- Дәрес алу әдәпләрен.

**Бу бүлектән өйрәндем:**

- Ашар алдыннан укыла торган доганы.
- Ашаганнан соң укыла торган доганы.
- Бәдрәфкә керер алдыннан укыла торган доганы.
- Бәдрәфтән чыкканда укыла торган доганы.
- Дәрес укудан әүвәл укыла торган доганы.
- Дәрес уку тәмам булганнан соң укыла торган доганы.



# 6-НЧЫ БҮЛЕК

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ КИТАБЫ - КОРЪӘН КӘРИМ



Коръән Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җәбраил фәрештә (Аңа Аллаһының сәламе булсын) аркылы Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә 23 ел дәвамында гарәп телендә иңдерелә. Коръән Кәримдә булган һәр сүз Аллаһы Тәгаләнең мөбәрак сүзләре. Шул сәбәпле, аны хөрмәт итү тиешле. Мөселманнар каршында аннан да кадерле һәм газиз Китап юк.

**Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр**

1. Коръән Кәримне укучының тәне госел-тәһарәтле, киеме һәм урыны чиста булу.

2. Коръәнне укыганда мөмкин булганча Кыйбла тарафына каршы утыру.

3. Коръән Кәримне Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен уку, Аллаһы Тәгалә бу укуны кабул итүен һәм әҗер-савап бирүен сорау, кешегә күрсәтер өчен генә укудан саклану.

4. Коръән Кәримне укыр алдыннан “Әгүзү бил-Ләһи минәш-шәйтанир-раҗим” сүзләрен әйтү.

5. Коръән Кәримне тәҗвид кагыйдәләренә нигезләнеп, дөрес итеп уку.

6. Коръән Кәримне матур тавыш белән уку.

7. Коръәнне укыганда буш сүзләрдән, шаяртулардан, көлке - уеннан саклану.

8. Коръән укыганны ишеткәндә сөйләшмәү, игътибар белән тыңлау.

9. Коръәннең ятлаган өлешләрен онытмау өчен, һәрвакыт кабатлау (чөнки оныткан өчен гөнаһ языла).

## Укы ихлас белән Коръән!

Ачып куй алдыңа Коръән, укы ихлас белән һәрдам,
Табарсың авыруыңа шифа, кичен, көндез укы Коръән!

Җаныңны пакьлыйм дисәң, үзеңне саклыйм дисәң,
Сүзеңне аклыйм дисәң, кичен, көндез укы Коръән!

Бәхет табыйм дисәң, белем алыйм дисәң,
Аллаһыма ярыйм дисәң, кичен, көндез укы Коръән!

Бәрәкәт табыйм дисәң, әҗер-савап алыйм дисәң,
Коръән әһле булыйм дисәң, укы ихлас белән Коръән!

Күңелне пакьлыйм дисәң, кабергә нур алыйм дисәң,
Җәннәт әһле булыйм дисәң, укы ихлас белән Коръән!

# ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ

2-НЧЕ СЫЙНЫФ



# 1-НЧЕ БҮЛЕК
## ИМАН НИГЕЗЛӘРЕ

Иман – ул күңелең (калебең) белән хак икәненә ышанып, ышанганыңны телең белән әйтү дигәнне аңлата. Ислам дине буенча иманның җиде нигезе бар. Үзен мөэмин-мөселман дип санаган кеше иманның шушы җиде нигезенә иман китерергә тиеш. Иманның нигезләре: 1) Аллаһы Тәгаләгә иман китерү, 2) Аның фәрештәләренә, 3) китапларына, 4) пәйгамбәрләренә, 5) Ахирәт көненә, 6) тәкъдирнең яхшысы-яманы да Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә, 7) үлгәннән соң янә терелүгә иман китерү.

Ә хәзер шушы иман нигезләре хакында тулырак сөйләшербез.

### *1. Аллаһы Тәгаләгә иман китерү*

Аллаһы Тәгаләнең барлыгын тану – һәрбер кешегә тиеш. Ләкин Аның нинди икәнлеген күз алдыбызга китерә алмыйбыз – бу мөмкин түгел, чөнки моңа акылыбызның куәте җитми.

Әгәр кеше көзге каршына басып үзенә караса, ул үзенең матур сурәтле булганын күрер: анда әйберләрне күрүче ике күзе, тавышларны ишетүче ике колагы, сурәтен матурлап торучы чәчләре. Ә тәненә караса: анда тибеп торучы йөрәген тояр, ризык белән суның тәмен тоючы телен, сулыш алучы борынын, җирдән атлап йөрүче ике аягын, эшләр башкаручы ике кулын бар икәнен күрер. Боларның бөтенесе безне бар иткән Олуг Кодрәт иясе Аллаһ Сөбханә вә Тәгаләнең барлыгына дәлил була. Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَفِي أَنفُسِكُمْ أَفَلَا تُبْصِرُونَ

“Дәхи үзегезнең тән вә рух төзелешегездә дә дәлилләр бардыр, әллә шуларны күрмисезме?” *(Әз-Зәрият сүрәсе, 51/21).*

Аллаһы Тәгалә шулай ук тирә-яктагы нәрсәләргә дә карарга чакыра:

أَفَلَا يَنْظُرُونَ إِلَى الْإِبِلِ كَيْفَ خُلِقَتْ وَإِلَى السَّمَاءِ كَيْفَ رُفِعَتْ وَإِلَى الْجِبَالِ كَيْفَ نُصِبَتْ وَإِلَى الْأَرْضِ كَيْفَ سُطِحَتْ

“Әллә, кешеләр дөяләргә карамыйлармы, ничек бар ителгәннәр? Вә күккә карамыйлармы – ничек күтәрелгән? Вә тауларга карамыйлармы – ничек беркетелгәннәр? Вә җиргә карамыйлармы – ничек палас кебек түшәлгән?” *(Әл-Гашияһ сүрәсе, 88/17-20).*

Һәм Аллаһы Тәгалә кешеләрне иман китерергә чакыра:

فَآمِنُوا بِاللَّهِ وَرَسُولِهِ وَالنُّورِ الَّذِي أَنزَلْنَا وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

“Кубарылу хак булгач, Аллаһка вә Аның рәсүленә һәм Без иңдергән нур булган Коръәнгә иман китерегез! Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдардыр”. *(Әт-Тәгаабүн сүрәсе, 64/8).*

Димәк, Аллаһы Тәгаләгә иман китерү ул иман нигезләренең беренчесе һәм иң мөһиме була.



## Иман нурын яктыртыр

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” иман нурын яктыртыр,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” хәләл ризык таптырыр.

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” – Гарше Көрси баскычы,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” – сигез Оҗмах ачкычы.

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһ”ны әйтми торма бер заман,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһ”ны әйтмәгәннәр бик яман.

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” – бик кадерле кәлимә,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһ”ны урнаштырчы кальбемә.

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” газап эчрә калдырмас,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” Җәһәннәмдә яндырмас.

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһ”ны насыйп итсен үлгәндә,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” юлдаш булсын күмгәндә.

“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” – изге сүзләр изгесе,
“Ләә иләәһә илләә-Ллааһү” – ике җиһан көзгесе.

**Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Өстәлне, урындыкны кем ясаган? Укый торган китабыңны кем язган? Ә син яши торган өйне кем салган? Шул хакта уйла һәм җавабыңны тап.

2. Өстәлне, урындыкны ясар өчен кулны кем биргән? Китапны язарга акылны, зиһенне кем биргән? Өйне салыр өчен материалларны, көчне кем биргән? Шул хакта уйлап кара әле.

3. Җирне картадан яисә глобустан кара. Ул нинди? Кояш һәм ай нинди шәкелдә? Җирне, кояшны, айны, йолдызларны кем барлыкка китергән? Шул хакта фикерлә.

## *2. Фәрештәләргә иман китерү*

Аллаһы Тәгаләнең фәрештәләре бар. Фәрештәләр алар Аллаһы Тәгаләнең бик итагатьле коллары. Аллаһы Тәгалә аларны нурдан яраткан. Алар Аллаһы Тәгаләгә һәрвакыт гыйбадәт итәләр, Аңа мактау һәм тәсбих әйтеп торалар. Аллаһы Тәгалә аларга нәрсә кушса, шуңа һич каршы килмичә, аны җиренә җиткереп башкаралар. Алар һич гөнаһлы эшләрне эшләмиләр.

Фәрештәләр ашамыйлар, эчмиләр, йокламыйлар, өйләнмиләр. Алар мөэминнәрне бик яраталар һәм Аллаһы Тәгаләдән аларга (мөэминнәргә) Үзенең рәхмәтен бирүне һәм гөнаһларын кичерүне сорыйлар. Кеше күзенә күренмиләр, ләкин безне күрәләр. Алар бик күп булып, санын беркем дә белми, Аллаһы Тәгалә ялгыз бер Үзе генә Белүче.

Аллаһы Тәгалә рөхсәте белән фәрештәләрнең кеше сурәтенә керергә көчләре җитә. Коръән Кәримдә Җәбраил (гәләйһиссәләм) фәрештәнең Гайсә гәләйһис-сәләм пәйгамбәрнең әнисе Мәрьям р.а.г. алдына кеше сурәтендә, ике фәрештәнең Ибраһим гәләйһис-сәләм һәм Лут гәләйһис-сәләм пәйгамбәрләр каршына кеше сурәтендә килгәнлекләре турында хәбәр ителә.

Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне канатлы итеп яраткан. Габдуллаһ ибн Мәсгуд р.а.г. дән риваять ителә: «Рәсүлүллаһ ﷺ Җәбраил гәләйһис-сәләмнең 600 канаты бар икәнлеген күрде һәм аларның һәрберсе офыкны каплый иде». (Сахих Бохари һәм Мөслим).

Олуг фәрештәләр дүртәү:

1. Барча пәйгамбәрләргә дә Аллаһы Тәгаләдән вәхи ирештерүче Җәбраил (гәләйһис-сәләм).

2. Җирдәге барлык эшләрне үтәүне (үсемлекләр, хайваннар, җир һ.б.) йөкләтелгән Микаил фәрештә.

3. Җан алучы Газраил фәрештә.

4. Кешеләр үлгәннән соң, аларга яңадан җан кертү өчен сурга өрүче Исрафил фәрештә.

Шулай ук бар:

- Гарешне күтәреп торучы һәм аның тирәләрендә булучы фәрештәләр.

- Җәннәт әһелләренә хезмәт итүче фәрештәләр.

- Җәһәннәмдә хезмәт итүче фәрештәләр.

- Кешеләр өчен җаваплы булучы фәрештәләр бар. Алар төрләргә бүленгәннәр: а) ана карынында булучы балага җан өрүче

фәрештә; б) кешеләрнең барча гамәлләрен язып баручы ике фәрештә: уңдагысы – яхшыларын, сулдагысы – яманнарын; в) кешеләрне саклап торучы фәрештәләр.

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

Дөрес җавап астына сызык сыз:

А: Фәрештәләрнең санын белә:

(Аллаһы Тәгалә - Пәйгамбәр – Галимнәр).

Ә: Фәрештәләр:

- алар безне күрми һәм без дә аларны күрмибез;
- алар безне күрә, ә без аларны күрмибез;
- алар безне күрә һәм без аларны күрәбез.

Б: Вәхине ирештерүче фәрештә ул:

(Җәбраил – Микаил – Исрафил - Газраил).

## *3. Пәйгамбәрләргә иман китерү*

Кешеләргә дин хөкемнәрен өйрәтү өчен Аллаһы Тәгалә бик күп пәйгамбәрләр җибәргән. Ул пәйгамбәрләрнең һәркайсысы кешеләрдән булган. Алар яшь вакытларында да бик акыллы, зирәк, гадел һәм изге табигатьле булганнар. Олы булганнан соң Аллаһы Тәгалә аларны пәйгамбәр итеп сайлаган, ягъни Җәбраил гәләйһис-сәләм исемле фәрештә аркылы аларга үзенең хөкемнәрен җибәргән һәм шул хөкемнәр буенча кешеләрне хак дингә һәм изге гамәлләр кылырга өндәргә кушкан. Шуннан соң ул пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча кешеләрне хак дингә һәм изге гамәлләргә өндәгәннәр.

Пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын-законнарын кешеләргә ирештерүчеләр һәм аңлатып бирүчеләр, туры юлны күрсәтеп, Җәннәт белән шатландыручылар, Җәһәннәм белән куркытучылар. Алар Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен үтәүчеләр һәм аларны үтәүдә башкаларга үрнәк булучылар, үзләренә иярүчеләрне тәрбия кылучылар, яхшылыкка өндәүчеләр һәм яманлыктан тыючылар. Пәйгамбәрләр Кыямәт көнендә үз өммәтләренә шәфәгатьче (яклаучы) булучылар.

Без аларның барчасын да Аллаһы Тәгаләнең илчеләре икәнлекләренә, Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен тулысынча кешеләргә җиткергәннәр, кешеләргә динне җитәрлек дәрәҗәдә аңлатканнар, гыйлем һәм гамәлдә камиллеккә ирешкәннәр, холыкта иң күркәм һәм сүздә иң дөрес сөйләүче кешеләр булуларына иман китерергә тиешбез. Аллаһы Тәгалә аларны ялган сөйләүдән, хыянәт итүдән, ялгышудан, хата кылудан, зур һәм кече гөнаһлардан саклаган.

Аллаһы Тәгалә, аларның пәйгамбәр икәнлекләрен күрсәтү (исбатлау) өчен, аларга төрле могҗизалар биргән.

Иң әүвәлге пәйгамбәр Адәм гәләйһис-сәләм, иң соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд ﷺ. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ Ахыр заман пәйгамбәре, аннан соң дөньяга һич пәйгамбәр киләчәк түгел. Ул безгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан Ислам динен ирештергән.

Адәм гәләйһис-сәләм заманыннан бирле дөньяга бик күп пәйгамбәрләр килеп киткән, күпме икәнлеге безгә мәгълүм түгел. Коръән Кәримдә шушы 25 пәйгамбәрнең исемнәре искә алына:

Адәм, Нух, Идрис, Салих, Ибраһим, Һуд, Лут, Юнус, Исмә-

гыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Әйюб, Шогаеб, Муса, Һарун, Әл-Ясәгъ, Зүл-Кифел, Дауд, Зәкәрия, Сөләйман, Ильяс, Яхья, Гайсә, Мөхәммәд ﷺ. Аларның барысына да Аллаһның сәламе һәм салаваты булса иде.

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Кайсы пәйгамбәрләрнең тормышлары хакында укыганың яисә ишеткәнең бар? Шулар хакында бер ничә җөмлә төзеп кил.
2. Коръән Кәримдә искә алынган пәйгамбәрләрнең исемнәрен истә калдыр.

## *4. Китапларга иман китерү*

Аллаһы Тәгалә дин хөкемнәрен аңлатып, пәйгамбәрләренә Китаплар иңдергән. Аларда Аллаһның кешеләргә әмер иткән һәм тыйган нәрсәләре язылган. Пәйгамбәрләр шул Китаплардагы хөкемнәр белән халыкларын иманга һәм изге гамәлләр кылырга өндәгәннәр.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә иңдерелгән биш Китапның исемнәрен китерә, алар түбәндәгеләр:

1. Сәхифәләр (Ибраһим гәләйһис-сәләмгә иңдерелде);
2. Зәбур (Дауд гәләйһис-сәләмгә иңдерелде);
3. Тәүрат (Муса гәләйһис-сәләмгә иңдерелде);
4. Инҗил (Гайсә гәләйһис-сәләмгә иңдерелде);
5. Коръән Кәрим (Мөхәммәд ﷺ гә иңдерелде).


Коръән Кәримне Аллаһы Тәгалә Рәсүлебез Мөхәммәд ﷺ гә 23 ел дәвамында Җәбраил (гәләйһис-сәләм) фәрештә аркылы

индергән. Ул Пәйгамбәребез ﷺ нең могҗизасы була.

Аллаһы Тәгалә аны гарәп телендә индергән. Коръән Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан индерелгән ахыргы Китап булып санала.

Коръән Кәрим Иләһи күрсәтмәләрнең бөтенесен үз эченә алган: үзеннән әүвәлге Китапларның бөтенесендә булган Аллаһны берләү, Аңа гына гыйбадәт һәм итагать итүне дөресләп килгән; башка Китапларда килгән яхшы гамәлләрне һәм өстенлекләрнең барысын үзенә җыйган.

Аллаһы Тәгалә аны кешеләрнең үзгәртүеннән Кыямәт көненә хәтле Үзе сакларга вәгъдә биргән:




إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

“Дөреслектә, Без Коръәнне Үзебез индердек һәм үзгәрүдән аны Үзебез сакларбыз”.

*(Әл-Хиҗр сүрәсе, 15/9).*

Коръән Кәрим барлык кешеләргә, ике дөньяда да бәхетле булырга сәбәп булучы шәригать итеп индерелде. Коръән Кәримдә һәр заманга һәм һәр урынга яраклы булган мәңге һәм ахыргы хөкемнәр килде.

## 📖 Укы ихлас берлән Коръән!

Ачып куй алдыңа Коръән, укы ихлас белән һәрдәм,

Табарсың дәрдеңә (авыруыңа) дәрман (шифа), кичен, көндез укы Коръән!

Жаныңны пакьлыем дисәң, үзеңне саклыем дисәң,
Сүзеңне аклыем дисәң, кичен, көндез укы Коръән!

Сәгадәт (бәхет) табаем дисәң, мәгърифәт (белем) алаем дисәң,
Ходаема ярыйм дисәң, кичен, көндез укы Коръән!

Бәрәкәт табаем дисәң, әҗер-савап алыйм дисәң,
Коръән әһле булыйм дисәң, укы ихлас берлән Коръән!

Күңелне пакьлием дисәң, кабергә нур алыйм дисәң,
Җәннәт әһле булыйм дисәң, укы ихлас берлән Коръән!

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Дөрес җавап астына сызык сыз:

Күктән иңгән Китаплар:

(Аларны Пәйгамбәрләр язды – аларны Аллаһы Тәгалә иңдерде – аларны галимнәр язды).

Күктән иңгән Китапларның иң ахыргысы:

(Таурат – Коръән Кәрим – Зәбур – Инҗил).

2. Пәйгамбәрләрнең исемнәрен, аларга иңдерелгән, Китап исемнәре белән тоташтыр:

| | |
|---|---|
| Муса (г.с.) | Коръән Кәрим |
| Ибраһим (г.с.) | Зәбур |
| Мөхәммәд ﷺ | Таурат |
| Гайсә (г.с.) | Сәхифәләр |
| Дауд (г.с.) | Инҗил |

## 5. Ахыр заманга һәм Кыямәт көненә иман китерү

Һәрбер җан иясе кайчан да булса бу дөньядан китәчәк, башкача әйткәндә үләчәк. Үлем әлбәттә киләчәк һәм аннан котылып булмый. Үлем – ул бер халәттән икенче халәткә күчү була. Аннан соң икенче тормыш – Ахирәт тормышы башлана. Кешенең үлемнән соң нинди халәттә булуы дөньяда кылган эшләре белән бәйле. Шул сәбәпле, кеше дөньяда яшәгәндә үк, үлемгә әзерләнергә тиеш. Ул исән-сау чагында Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, Кыямәт көненең булачагына ышанган хәлендә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылып, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә тиеш; үлемне һәм Ахирәт көнен истә тотарга, хисап көнендә Аллаһы Тәгалә хозурына килеп басканнан соң, бу дөньяда кылган гамәлләре өчен җавап бирерлек булырга тиеш.

Үлгән кеше кабергә күмелгәннән соң аның янына Мүнкәр һәм Нәкир исемле ике фәрештә килер. Алар аны утыртырлар һәм Раббысы, Пәйгамбәре, Дине һәм Аллаһы Тәгалә фарыз иткән гамәлләренең үтәлүе турында сорарлар. Әгәр мәет мөэмин кешеләрдән һәм изге гамәлләр кылганнардан булса, Аллаһ ярдәме белән күркәм җавап бирер (алардан курыкмыйча һәм каушамыйча), ул бөек нигъмәтләр белән нигъмәтләнер. Әгәр үлгән кеше имансыз булса – аптырар, нәрсә әйтергә дә белмәс, аны фәрештәләр бик каты газапларлар.

Габдулла ибн Гамирдан риваять ителә: «Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Дөреслектә, сезләрдән берегез үлсә, иртә һәм кич аңа бара торган урыны күрсәтеп торылыр. Әгәр Җәннәт әһленнән булса, Җән-

нәт әһленнән икәнлеге, әгәр Җәһәннәм әһленнән булса, Җәһәннәм әһленнән икәнлеге күрсәтелер. Һәм аңа әйтелер: «Бу синең Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә яңадан торгызган вакыттагы урының». (Сахих Бохари һәм Мөслим).

Бер заман шушы дөньяда булган кешеләр һәм хайваннар үлеп һәм дөнья нәрсәләренең һәрберсе һәлак булып бетәчәкләр. Бу заманга Ахыр заман диелер. Ахыр заманның кайвакыт булачагы Аллаһы Тәгаләдән башка һич кемгә мәгълүм түгел.

Һәрбер мөэмин-мөселман Кыямәт көне, әлбәттә, киләчәк дип, шиксез иман китерә. Аның кайчан булуын Аллаһы Тәгалә гади кешеләрдән генә түгел, хәтта пәйгамбәрләрдән дә яшерде. Шуның өчен, бер кеше дә дөнья тормышында Кыямәт көненең кайчан булачагын белми.

يَسْأَلُونَكَ عَنْ السَّاعَةِ أَيَّانَ مُرْسَاهَا قُلْ إِنَّمَا عِلْمُهَا عِنْدَ رَبِّي لَا يُجَلِّيهَا لِوَقْتِهَا إِلَّا هُوَ ثَقُلَتْ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ لَا تَأْتِيكُمْ إِلَّا بَغْتَةً يَسْأَلُونَكَ كَأَنَّكَ حَفِيٌّ عَنْهَاقُلْ إِنَّمَا عِلْمُهَا عِنْدَ اللَّهِ وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ

«Синнән (Әй, Мөхәммәд ﷺ) сорыйлар Сәгать (Кыямәт) хакында: «Кайчан була ул?» – дип. Әйт аларга: «Аның хакында белем – фәкать Раббымда, Аннан башка аның вакытын беркем дә ачыкламас. Җир һәм Күктәге мәхлукларга аны белү авыр. Килер ул сезгә кинәт кенә». Сорыйлар алар синнән, син аның хакында белгән шикелле. Әйт аларга: «Аның хакында белем – фәкать Аллаһыда». Ләкин кешеләрнең күбесе белми».

*(Әл-Әгъраф сурәсе, 7/187)*

Дөньяда булган барча нәрсәләр һәлак булып беткәннән соң, Аллаһы Тәгалә кешеләрне яңадан торгызачак. Черегән һәм таралган тәннәрнең һәркайсысы җыелып, оешып, терек вакыттагы хәлләренә киләчәкләр. Каберләрнең өсләре ярылып, ачылганнан соң, һәр кешенең җаны үз гәүдәсен табып керәчәк. Шуннан соң кешеләр, йокыдан уянган шикелле терелеп, каберләреннән чыгып, Мәхшәр мәйданына җыелачаклар. Мәхшәр мәйданында кешеләрнең дөньяда кылган гамәлләре хисап ителеп, кылган гамәлләренә карап әҗер һәм савап билгеләнер. Имансыз кешеләрнең һәркайсысы Җәһәннәмгә төшәчәкләр. Иманлы кешеләрнең гөнаһсызлары һәм гөнаһлары гафу ителгәннәре Җәннәткә керәчәкләр. Гөнаһлары гафу ителмәгән мөэминнәр Җәһәннәмгә төшеп, гөнаһларының күләменә карап, газап ителәчәкләр һәм газаплары тәмам булганнан соң Җәһәннәмнән чыгып, алар да Җәннәткә керәчәкләр. Җәннәттә калган кешеләр дә, Җәһәннәмдә калган кешеләр дә, һич үлмичә, мәңге терек булачаклар.

Җәннәт – Оҗмах йорты булып, зиннәтле сарайлар һәм җимешле бакчалар белән тулыдыр. Һәр җирендә татлы сулы елгалар һәм ширбәтле чишмәләр агып тора. Анда күрсәтелә торган хөрмәт һәм нигъмәтләрне аңлатып бетерү һич мөмкин түгел. Анда кергән изге кешеләр дөньяда һич кемнең күзе күрмәгән һәм колагы ишетмәгән ләззәтле нигъмәтләр белән хөрмәт ителәчәк.

Җәннәт – мәңгелек йорт. Анда кергән кешеләр һич үләчәк түгел. Һәрберсе кайгы, хәсрәт, авыру, сызлау, уңайсызлык һәм күңелсезлек шикелле хәлләрдән һәрвакыт тынычлыкта

булачаклар. Җәннәткә кергәннәр Аллаһы Тәгаләнең нурын да күрәчәкләр.

Җәһәннәм – Тәмуг йорты. Анда кергән кешеләр ут һәм башка газаплар белән газап ителерләр. Дөньяда вакытта саваплы эшләрне дә күп эшләгән әзрәк гөнаһлы кешеләр Тәмугда җиңел газаплар белән генә газап ителәчәкләр. Кешегә һәм хайваннарга җәбер һәм золым иткән зур гөнаһлы кешеләр Тәмугда бик олуг җәзалар белән газап ителәчәкләр.

? **Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Туры килгәннәрне бер-берсе белән тоташтыр:

| | |
|---|---|
| Савап | Ахирәттәге нигъмәтләр урыны |
| Әл-Бәгс | Аллаһ гамәлләрне хисап итә |
| Әл-Хисап | Аллаһ үлгәннәрне терелтә |
| Җәннәт | Аллаһның газабы |
| Җәза | Аллаһның нигъмәте, бүләге |

2. Кыямәт көне һәм андагы хәлләр хакында сөйләүче Пәйгамбәребез ﷺ нең бер хәдисен язып кил.

## *6. Тәкъдиргә иман китерү*

Без, тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән дип иман китерергә тиеш булабыз. Тәкъдир – булачак нәрсәнең булуын алдан билгеләп кую дигәнне аңлата. Дөньяда булачак нәрсә һәм башкарылачак эшләрнең һәркайсысы Аллаһы Тәгаләгә алдан ук мәгълүм.

Аллаһы Тәгалә һәрбер нәрсәне һәм һәрбер эшне бар иткәнче, Үзенә мәгълүм булган рәвешчә, тәкъдир кылып (ягъни билгеләп) куйган. Дөньяда булган нәрсәләрнең һәркайсысы Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире буенча була. Һәм шулай ук һәрбер булган нәрсә Аллаһы Тәгаләнең Булдыруы белән бар була. Кешеләр һәрбер эшләгән гамәлләрен үз теләкләре белән башкарсалар да, аларга куәт бирүче Аллаһы Тәгаләдер.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: «Иман ул Аллаһка, Аның фәрештәләренә, Китапларына, Рәсүлләренә иман китерү; Җәннәткә, Җәһәннәмгә һәм мизанга (үлчәүгә) иман китерү; үлгәннән соң янә терелүгә һәм тәкъдирнең яхшысына һәм яманына иман китерү».

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: «Кеше иман китермәгән дип санала, дүрт нәрсәгә иман китермичә: Аллаһтан башка илаһ юк һәм мин (Мөхәммәд ﷺ), хак белән җибәрелгән, Аллаһның Рәсүле, дип; үлемгә; үлгәннән соң янә терелүгә һәм тәкъдиргә».

### ? Сораулар һәм күнегүләр:


1. Тәкъдир хакында китерелгән хәдисләрнең берсен ятла.
2. Тәкъдирне үзеңнең әтиеңә яисә әниеңә аңлатып кара.

## *Бу бүлектән белгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- Бөтен нәрсәләрне бар итүче, Кодрәтле Бер Аллаһы Тәгаләгә иман китерергә кирәклеген.

- Нурдан яратылган фәрештәләргә иман китерергә кирәклеген.
- Күктән иңдерелгән Китапларга һәм Пәйгамбәрләрнең бөтенесенә дә иман китерергә кирәклеген.
- Ахирәт көненә һәм Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан икәненә иман китерергә кирәклеген.



# 2-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАЛАРЫ

### *1. Һуд гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Йәмән җирендә “Гәд” исемле бер халык яшәгән. Алар үзләренең көчле һәм зур гәүдәле булулары белән билгеле булганнар. Шуның белән үзләрен иң яхшы кешеләр дип мактанганнар. Алар төрле сыннар ясап шуларга гыйбадәт кылып, җир йөзендә төрле бозыклыклар тарата башлыйлар.



Аллаһы Тәгалә башка халыкларга да пәйгамбәрләр җибәргәне шикелле, Гәд кавеменә Һуд пәйгамбәрне җибәрә. Ул Раббысына гына гыйбадәт кылып, тәкъва булуы белән билгеле була.

Һуд гәләйһис-сәләм халкына Аллаһы Тәгаләнең ялгыз бер Үзенә генә гыйбадәт кылырга кирәк икәнлеген аңлата. Ләкин иман китермәгәннәр аны мыскыл итәләр: “Әй Һуд, без сине надан дип саныйбыз һәм ялганчы дип уйлыйбыз”.

Һуд гәләйһис-сәләм аларга: “Әй кавемем! Мин сезгә нәсыйхәт әйтүче генә һәм аның өчен сездән акча сорамыйм, минем эшемнең әҗере Аллаһы Тәгалә өчен генә. Шуны да аңламыйсызмы әллә?”, - ди.

Кавеме аннан көлүен дәвам итә. Һүд гәләйһис-сәләм, аңа карамастан, аларга Аллаһның биргән нигъмәтләрен исләренә төшерә һәм: “Әгәр дә сез көферлектә булуыгызны дәвам итсәгез, сезгә Аллаһы Тәгаләнең каты газабы булыр.



Нух гәләйһис-сәләмнең кавеме ничек һәлак булганын белмисезме әллә?”, - дип кисәтә. Шуңа карамастан, Һүд гәләйһис-сәләмнең диненә бик азлары гына керә.

Шулай итеп көннәр, айлар, еллар уза. Һүд гәләйһис-сәләм үзенең дәгъватын дәвам итә, әмма күбесенең йөрәкләре таш кебек була – пәйгамбәр сүзенә колак салмый.

Кавеменең тәкәбберлеге һәм каршы торуы дәвам иткәч, Һүд гәләйһис-сәләм Раббысына дога кыла: “Әй Раббым, мине ялганчы дигәннәре өчен, миңа ярдәм бир!” Аллаһы Тәгалә әйтә: “Алар сине ялганчы дигәннәре өчен, тиздән, әлбәттә, үкенечле булып әверелер”.

Аллаһы Тәгалә Һүд гәләйһис-сәләмнең догасын кабул итә һәм аларга яңгырны туктата. Җирләр корый, кояшның эсселегеннән яшеллекләр корып көя, чәчүлекләр яна. Шул газапның, Аллаһтан икәнен белеп, Һүд гәләйһис-сәләм кавемен иманга өнди. Иманга килмәсәләр, Аллаһы Тәгалә тагы да катырак газап белән газаплар дип кисәтә. Ләкин аларның тәкәбберлекләре бик көчле була.



Көннәрдән бер көнне, күк йөзендә болыт күренә. Кешеләр безгә яңгыр килә дип шатланышалар. Һүд гәләйһис-сәләм генә бу болытның Аллаһы Тәгаләнең газабы икәнен белеп, кешеләрне тагы да көчлерәк иман китерүгә чакыра. Ул болытның зур газап билгесе икәнен әйтә, ләкин ышанмаучылар аның сүзләрен кире кагалар. Шуннан соң, Һүд гәләйһис-сәләм иман китерүчеләр белән ул җирдән башка урынга күченеп китә. Шул ук көнне Аллаһы Тәгалә иман китермәүчеләргә бик көчле давыл җибәрә. Ул давыл җиде төн һәм сигез көн дәвамында бөтен нәрсәләрне җимерә һәм барча кешеләрне һәлак итә.

**Бу кыйссадан алган файдалар**

- Үзеңнең көчлелегең белән мактанмаска, тәкәбберләнмәскә, ә киресенчә, тыйнак булырга кирәк.
- Пәйгамбәрләргә иярмичә аларга каршылык күрсәтү, кешене бу дөньяда да, Ахирәттә дә һәлакәткә илтә.
- Диннән ерак булу кешеләрне начар гамәлләрне эшләүгә этәрә.
- Бозыклык, фәхишәлек, Аллаһның диненнән ерак булу кешеләргә Аллаһы Тәгалә тарафыннан газап килүгә китетерергә мөмкин.

## *2. Ибраһим гәләйһис-сәләм һәм Исмәгыйль гәләйһис-сәләм пәйгамбәрләр*

Ибраһим гәләйһис-сәләмнең әтисе агачтан һәм таштан потлар ясый иде, ә халкы шул потларга табына иде. Ибраһим гәләйһис-сәләм боларны күреп: "Ничек инде кешеләр әтием үз куллары белән ясаган потларга табыналар?" - дип гаҗәпләнә иде. Шуны күреп Ибраһим гәләйһис-сәләм әтисенә йомшаклык белән, әдәпле итеп кенә, хак юлны аңлатырга теле:

"Әтием, ни өчен син ишетми дә, күрми дә, сиңа файда да, зарар да бирми торган нәрсәгә гыйбадәт кыласың? Әтием, Аллаһы Тәгаләдән миңа гыйлем һәм дәлилләр килде. Алар синдә юк. Миңа ияр, туры юлга күндерермен! Әтием, шайтанга гыйбадәт кылма, чөнки ул Аллаһка гөнаһкәр булды. Әтием, сине Аллаһы Тәгалә газап итүеннән куркам!"

Әтисе аңа:

"Ибраһим, син без гыйбадәт итә торган иләһләрдән баш тартасынмы? Әгәр бу эштән туктамасаң, мин сиңа таш белән атачакмын. Кит минем янымнан!", - дип җавап кайтара.

Ибраһим гәләйһис-сәләм әйтә: "Ярый, алай булса, сәламәт һәм тыныч бул, мин сине мәҗбүр итмим. Синең өчен Раббымнан гафу итүен сорыйм. Инде үзегезне һәм Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт итә торган нәрсәләрегезне ташлап китәм".

Ибраһим гәләйһис-сәләм халкын Аллаһы Тәгаләнең бер Үзенә генә гыйбадәт кылырга чакыра. Ләкин алар аның сүзләрен кабул итмичә, имансыз булуларында дәвам итәләр, хәтта аның

әтисенә барып зарланалар. Шуңа карамастан, Ибраһим гәләйһис-сәләм иманга чакыруны дәвам итә.

Ул вакытларда Нәмруд исемле бик явыз патша була. Бөтен кешеләр аны "иләһ" урынына күреп, табына торган булалар. Ибраһим гәләйһис-сәләм аның янына килеп, аны ялгыз бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга чакыра. Нәмруд патша аннан сорый: "Синең Раббың кем?", - дип. Ибраһим гәләйһис-сәләм әйтә: "Минем Раббым тергезүче дә һәм үтерүче дә". Нәмруд әйтә: "Мин дә үтерәм һәм тергезәм". Ибраһим гәләйһис-сәләм әйтә: "Аллаһы Тәгалә кояшны көнчыгыштан чыгара, ә син көнбатыштан чыгар, әгәр көчең җитсә". Нәмруд патша бу эшне эшли алмаячаклыгын аңлап, каушап сүзсез кала һәм хурлыкка төшә.

Ибраһим гәләйһис-сәләм халкын күпме генә иманга чакырса да, алар иманга килмиләр. Ата-бабаларыбызга иярәбез дигән дәлилләр белән, алар потларына гыйбадәт кылуда нык торалар.

Ибраһим гәләйһис-сәләмнең үз халкына шушы таштан ясалган потлар аларга бернинди файда китерә алмаганына дәлил китерәсе килә. Ибраһим гәләйһис-сәләм, кешеләрнең потлары торган гыйбадәтханәдән чыгып беткәннәрен көтеп тора да, балта белән потларын вата, мәгәр бер зур потны гына калдырып, аның муенына балта беркетеп куя.

Мөшрикләр моны күргәч әйттеләр: "Безнең иләһләребезгә бу әдәпсезлекне кем кылды? Тәхкыйк, ул кеше залимнәрдән". Әйттеләр: "Бер егетне ишеттек. Ул безнең иләһләребезне гаепләп сөйли иде. Ул егетнең исеме Ибраһим дип әйтәләр".

Нәмруд һәм башкалар әйтте: “Ул Ибраһимны тотып китерегез”.

Сорадылар: “Ибраһим, безнең иләһләребезгә бу эшне син эшләдеңме?”

Ибраһим гәләйһис-сәләм әйтте: “Ник потларыгызның зурысыннан сорамыйсыз соң?”

Алар әйттеләр: “Беләсең бит, безнең потларыбыз сөйләшмиләр, алардан ничек сорыйк ди?”

Ибраһим гәләйһис-сәләм әйтте: “Сез ничек инде файда да, зарар да китерә алмаган нәрсәләргә гыйбадәт кыласыз? Шуны да аңламыйсызмы?”

Аларның моңа бик каты ачулары чыга. Алар җимерелгән потлары өчен Ибраһим гәләйһис-сәләмнән үч алырга уйлыйлар. Зур итеп, тау хәтле, учак ягалар да, аны шунда ыргыталар. Ибраһим гәләйһис-сәләм дөнья утыннан курыкмый, күңеле тыныч була.

Аллаһы Тәгалә шул вакытта утка: “Ий ут, Ибраһимга салкын бул, һәм салкынлык белән дә зарар тидермә”, – дип әйтә. Ут Аллаһы Тәгаләнең әмере белән Ибраһим гәләйһис-сәләмгә бернинди зарар китермичә, салкынга әверелә.

Аллаһы Тәгаләнең кодрәте бик зур шул. Ул Ибраһим гәләйһис-сәләмне коткара. Аллаһы Тәгалә утны бар итеп, аңа яндыру сыйфатын биргәнгә, Аллаһы Тәгалә ялгыз бер Үзе генә шушы утны салкын да итә ала.

Бу вакыйга кешеләргә бик зур тәэсир итеп, кайберләре иман

китерә. Күбесе тәкәбберлек кылып, имансыз халәтләрендә калалар.

Ибраһим гәләйһис-сәләм, кавеме аңа шундый авырлык китергәнгә хатыны Сара белән башка җирләргә китеп, кешеләрне бер Аллаһы Тәгаләгә генә иман китерүгә һәм гыйбадәт итүгә чакыруын дәвам итә. Аларның, Сара белән озак еллар бергә торуларына карамастан, балалары булмый. Бераз вакыттан соң Ибраһим гәләйһис-сәләм Хәҗәр исемле хатынга өйләнә һәм Аллаһы Тәгалә аларга Исмәгыйль исемле ул бүләк итә.

Бер вакытны Аллаһы Тәгаләдән Ибраһим гәләйһис-сәләмгә хатыны Хәҗәрне һәм улы Исмәгыйльне Мәккә җиренә илтеп калдырырга дигән әмер килә. Ул чорларда Мәккәдә кешеләр дә, агачлар да, су да булмый. Шуңа карамастан, Ибраһим гәләйһиссәләм Аллаһның әмеренә буйсынып, хатыны белән улын шунда калдырып кире кайтып китә. “Шушы урын бәрәкәтле урын булсын”, - дип Аллаһы Тәгаләгә дога кыла.

Ибраһим гәләйһис-сәләм киткәннән соң бераз вакыт үткәч, Исмәгыйль сусап елый башлый. Әнисе Хәҗәр, су эзләп, башта Сафа тавына менә, аннары Мәрва тавына китә. Шулай итеп Сафа белән Марва таулары арасында җиде кат йөри һәм соңгы, җиденчесендә, зур могҗиза була. Улы Исмәгыйльнең аягы астыннан чишмә бәреп чыга. Хәҗәр үзе эчеп, малаен да эчергәч, суга “зәмзәм” дип әйтә. Шуннан соң бу җиргә кешеләр дә күченеп яши башлыйлар.

Ибраһим гәләйһис-сәләм хатыны һәм улы янына барып йөри. Төннәрдән бер төнне, ул төшендә улы Исмәгыйльне корбан

кылганын күрә. Бу төш берничә тапкыр кабатлангач, ул үзенең улы Исмәгыйльне корбан итеп чалырга тиешлеген аңлый. Ибраһим гәләйһис-сәләм үзенең төшен улына сөйләгәч, Исмәгыйль Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсынып, үзен корбан итәргә ризалыгын белдерә.

Ибраһим гәләйһис-сәләм улы Исмәгыйльне корбан кылырга алып барганда, шайтан Ибраһим гәләйһис-сәләм янына килеп: “Мин шайтан, төшеңә дә мин килдем”, - дип аны бу эшеннән тыймакчы була. Ибраһим гәләйһис-сәләм исә, җиде таш алып аңа ата. Бераздан шайтан икенче, өченче тапкыр да килә һәм Ибраһим гәләйһис-сәләм аңа шул ук җавап белән кайтара.

Ибраһим гәләйһис-сәләм улы Исмәгыйльне корбан чалам дигәндә, аның пычагы үтмәс була. Аллаһы Тәгалә Исмәгыйльне саклап кала һәм Ибраһим гәләйһис-сәләмгә улы урынына сарык чалуны насыйп итә.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә Ибраһим гәләйһис-сәләмгә Кәгъбәтулланы төзергә куша. Бу эшендә аңа улы Исмәгыйль дә булыша.

Ибраһим гәләйһис-сәләмнең олы яшьтә булган һәм бала таба алмаган Сара исемле хатыны да бала таба. Аңа Исхак дип кушалар. Бу аларга Аллаһы Тәгаләнең яңа бер бүләге була.

## Бу кыйссадан алган файдалар

- Әтисе иман китермәсә дә, Ибраһим гәләйһис-сәләм аның белән йомшак итеп сөйләште, ата-ана белән йомшаклык күрсәтеп сөйләшү тиеш булганлыктан.

- Ибраһим гәләйһис-сәләм кавемен иманга чакырса да, бик азы иман китерде.
- Аллаһы Тәгаләнең Ибраһим гәләйһис-сәләмне уттан саклап калуы.
- Аллаһы Тәгалә әмер иткәч, Ибраһим гәләйһис-сәләм хәтта бердәнбер баласын корбан итәргә риза булуы.
- Исмәгыйль гәләйһис-сәләмнең Аллаһы Тәгаләнең әмеренә дә һәм әтисенә дә буйсынуы.
- Аллаһы Тәгаләнең Исмәгыйль гәләйһис-сәләмне саклап калуы һәм аның урынына сарык чалырга боеруы.

## 3. Йосыф гәләйһис-сәләм пәйгамбәр

Йосыфның әтисе – Ягъкуп, Ягъкупның әтисе – Исхак, Исхакның әтисе – Ибраһим гәләйһис-сәләм иде. Алар барысы да пәйгамбәрләр булдылар.

Йосыф гәләйһис-сәләмне әтисе Ягъкуп гәләйһис-сәләм бик каты ярата. Ул бик матур һәм сөйкемле бала була.

Көннәрдән бер көнне Йосыф гәләйһис-сәләм гәҗәеп төш күрә. Ул бик зур тәхеттә утыра икән: үнбер йолдыз һәм ай белән кояш аңа сәҗдә кылалар. Йосыф гәләйһис-сәләм бу төше хакында әтисенә сөйли. Ягъкуп гәләйһис-сәләм моңа бик шатлана. Абыйлары бу хакта белеп, шайтан вәсвәсәсенә бирелеп берәр начарлык кылмасыннар өчен, Йосыф гәләйһис-сәләмгә бу төше хакында һичкемгә дә сөйләмәскә куша. Ләкин шайтан Йосыф гәләйһис-сәләм белән абыйлары арасына фетнә сала. Абыйлары үзара киңәшләшеп,

Йосыфны сахрага алып чыгып коега ташларга уйлыйлар. Бу урыннан узган кәрваннар Йосыфны коедан табып алып, аны башка ераграк җиргә алып китәрләр, дип уйлыйлар алар.

Әтиләреннән Йосыфны үзләре белән алып чыгарга рөхсәтен алалар. Көн узгач, алар бер сарыкны чалып, шуның канына Йосыфның күлмәген буйыйлар. Аның үзен коега ташлап, әтиләре янына елаган кыяфәт белән кайтып: "Әтиебез, без Йосыфны караусыз калдырган вакытта аны бүре ашаган, без аны күрми калганбыз", - диделәр. Әтиләре бу хәлгә бик борчыла, кайгыра, ләкин сабыр итә.

Йосыф гәләйһис-сәләм исә, коеда берүзе күпмедер вакыт уздырганнан соң, кое янына суга дип туктаган кәрванчыларның чиләгенә ябышып чыга. Йосыф кәрван белән Мисыр иленә барып җитә. Соңыннан кәрванчы аны патшаның вәзиренә сатып җибәрә.

Вәзир моңа бик шатлана, чөнки хатыны белән аларның балалары булмый. Алар Йосыфны үзләренә бала итеп алалар. Зурая төшкәч Йосыфның матурлыгы, сөйкемлеге тагы да арта. Аның матурлыгын күреп вәзирнең хатынында аңа карата мәхәббәт уяна. Һәм ул Йосыфны гөнаһ эшләргә чакырып, өендәге бөтен ишекләрне бикли. Ләкин Йосыф гәләйһис-сәләм бик ихласлы иде, Аллаһы Тәгалә аның бөтен эшләрен белеп торуын белә иде. Шуңа да ул вәзир хатыны сораган гөнаһлы эшне катгый рәвештә кире кага. Йосыф гәләйһис-сәләм аннан котылыр өчен ишекләргә таба йөгерә. Вәзир хатыны Йосыфны чыгармас

өчен артыннан куа, Йосыфның күлмәген арттан тотып үзенә тарта. Күлмәк ертыла. Ишек алдында алар хатынның ире булган вәзиргә очрыйлар. Вәзирнең хатыны иренә Йосыф хакында, ул аңа начар эшне эшләргә теләде дип, ялган сөйли. Вәзир Йосыфның күлмәге арттан ертылганын күрә һәм монда хатыны гаепле икәнен аңлый. Йосыфка моны онытырга – кешеләргә сөйләмәскә куша.

Йосыф гәләйһис-сәләм исә Раббысына ялвара: “Әй Раббым! Мине чакырган зур гөнаһка караганда миңа зиндан яхшырак. Ул хатыннарның хәйләләрен миннән үзең бетермәсәң, ул вакытта мин аларга авышырмын һәм ярамаган эшне эшләп хәсрәттә булырмын”. Аллаһы Тәгалә аның бу догасын кабул итә. Йосыф гәләйһис-сәләм гөнаһлы эшкә караганда, үзенә зиндан хәерлерәк дип сайлый. Аны зинданга ябалар.

Зинданда аның белән бергә ике егет тә була. Аларның берсе – хәмер ясаучы, ә икенчесе – икмәкче. Көннәрнең берсендә, алар төш күреп, Йосыф гәләйһис-сәләм янына төшләрен юратырга киләләр. Хәмер ясаучысы әйтә: “Мин төшемдә хәмер сыкканымны күрдем”. Ә икмәкче булганы әйтә: “Мин төшемдә икмәк күтәреп йөргәнемне күрдем, ул күтәргән икмәгемнән кошлар ашый иде”.

Йосыф гәләйһис-сәләм башта аларга Аллаһы Тәгаләнең ялгыз бер Үзенә генә иман китерергә һәм гыйбадәт кылырга кирәклегенә вәгазьләп, соңыннан төшләрен юрап әйтә: “Беренчегез зинданнан чыгып әүвәлге урынында хуҗасына хәмер ясаучы булыр, ә икенчегезне асарлар һәм аның башын кошлар ашар”.

Йосыф гәләйһис-сәләм егетләрнең котыла дип юраганына, зинданнан чыккач, аны хаксыз зинданга ябылганын искә төшереп, патшадан чыгаруын сорарга үтенә. Әмма егет зинданнан чыккач Йосыф гәләйһис-сәләмнең үтенечен оныта һәм ул анда тагын бик күп елларга кала.

Көннәрнең берсендә патша бик серле бер төш күрә. Вәзирләрен чакыртып, аларга төшләрен сөйли: "Мин төшемдә җиде симез сыер күрдем, аларны җиде ябык сыер ашый, шулай ук, җиде яшел башаклар һәм җиде кипкән башаклар күрдем". Һәм алардан төшен юрап бирүләрен сорый. Алар аңа: "Без төш юрый белмибез, бездә андый белем юк", - дип әйтәләр. Шул вакытта, зинданнан чыккан егет Йосыф гәләйһис-сәләмне искә төшереп, патшага хәбәр итә һәм аны Йосыф гәләйһис-сәләм янына зинданга кертүен сорый.

Ул Йосыф гәләйһис-сәләм янына барып аңа патша күргән төшне сөйли һәм аны юрап бирүен үтенә. Йосыф гәләйһис-сәләм төшне юрап әйтә: "Җиде ел тоташтан иген чәчегез. Җиде елда уңыш яхшы булыр. Алган уңышны сукмыйча, башагы һәм саламы белән кибәндә сакларсыз, мәгәр үзегез ашар хәтле генә сугып алырсыз. Моның соңында җиде ел ачлык еллары килер. Уңышлы җиде елда җыйган игеннәрегез җиде ачлык елларында ашалып бетәр, мәгәр орлык өчен саклаган аз гына игеннәрегез калыр. Соңыннан ачлык еллардан соң бер ел килер. Ул елда яңгырлар явар, игеннәр һәм җимешләр үсәр".

Патша Йосыф гәләйһис-сәләмнең төш юраганын белгәч, аны

үзенә китерергә куша. Әмма Йосыф гәләйһис-сәләм моны кире кага – башта үзенең зинданда гаепсез утыртылганын ачыклавын сорый. Патша бу эшне тикшергәннән соң, вәзирнең хатыны гаепле икәнлеге, Йосыф гәләйһис-сәләмнең исә, гаепсезгә рәнҗетелгәне ачыклана. Бу хәлдән соң патша Йосыфны зинданнан чыгарып, үзенең вәзире итеп куя.

Йосыф гәләйһис-сәләм юраганча җиде ел муллык була. Соңыннан бар җиргә корылык килә һәм ачлык еллары башлана. Йосыф гәләйһис-сәләм үзенең гаделлеге белән кешеләрнең ихтыяҗына карап, узган муллык елларында тупланган ашлыкны сатып бирә.

Мисыр илендә ашлык барлыгын ишеткәч, Йосыфның абыйлары шунда баралар. Барып җиткәч алар ашлык сорар өчен Йосыф янына керәләр. Ул аларны танып ала, әмма абыйлары аны танымыйлар. Алар аңа шулай итеп мөрәҗәгать итәләр: “Без Ибраһим гәләйһис-сәләм нәселеннән Ягъкуп балалары. Барчабыз үнике идек. Йосыф исемле кечкенә энебезне югалттык. Бинәмин исемлесе әтиебез янында калды. Әти-әниебез белән ундүрт булабыз. Безгә җитәрлек ризык бирмәссең микән?”, - диделәр.

Йосыф гәләйһис-сәләм аларга: “Мин сезгә җитәрлек ризык бирермен, ләкин сез Бинәмин исемле энегезне алып килегез. Алып килмәсәгез, миндә сезнең өчен ашлык булмас”, - дип җавап бирә.

Йосыф гәләйһис-сәләмнең абыйлары кайткач, әтиләренә бөтенесен дә сөйләп бирәләр. Әтиләре Йосыф белән булган хәлне искә төшереп, Бинәминне бирәсе килми. Ләкин соңыннан, Аллаһы Тәгалә исеме белән ант иттереп, Бинәминне кире

алып кайтуларына вәгъдә ала. Һәм Мисырга җиткәч, барысы да бер капкадан кермичә, аерым-аерым капкалардан керергә куша.

Йосыф гәләйһис-сәләмнең абыйлары, әтиләре әйткәнчә, төрле капкалардан керәләр һәм Йосыф янына киләләр. Йосыф гәләйһис-сәләм абыйларына тиешле ризыкны бирә. Алар китер алдыннан, ул үзенең хезмәтчеләренә Бинәминнең йөгенә үлчәү савытын яшереп куярга куша. Бераздан: “Үлчәү савыты югалды”, - дип игълан ителә. Йосыф гәләйһис-сәләм йөкләрнең барысын да тикшереп чыгарга куша. Тикшерүчеләр үлчәү савытын Бинәминнең йөгеннән табып алалар һәм Йосыф гәләйһис-сәләмгә җиткерәләр.

Йосыф гәләйһис-сәләм абыйларына әйтә: “Билгеле булганча, әйбер урлаучы бездә хезмәтче булып кала. Бу аның тиешле җәзасы”. Бу сүзләрне ишеткәч абыйлары елап җибәрә һәм аңа: “Өйдә аның карт әтисе бар. Аның урынына безнең бөтенебезне ал, аны җибәр”, - диләр. Йосыф гәләйһис-сәләм аларның бу сүзләрен кире кага – Бинәминне алып кала.

Алар өйләренә кайтып китәләр. Әтиләре янына кайткач, барча нәрсәләрне сөйләп бирәләр. Ягъкуп гәләйһис-сәләм бу сүзләргә бик кайгыра һәм борчыла.

Соңыннан абыйлары Мисырга барып Йосыф гәләйһис-сәләм янына кереп әйтәләр: “Безгә һәм гаиләбезгә бик каты ачлык килде. Сезгә бераз әйберләр китердек, шуңа карата безгә ашлык үлчәп бир һәм Бинәминне дә биреп җибәр. Әтиебезнең аның

өчен бик хәсрәтләнеп елый-елый күзләре сукрайды”. Бу сүзләрдән соң Йосыф гәләйһис-сәләмнең күңеле йомшара һәм ул үзен танытырга һәм серләрен ачарга уйлый.

Йосыф гәләйһис-сәләм әйтә: “Хәтерегездәме? Йосыфка һәм анын энесе Бинәминга ниләр кылдыгыз?”

Алар: “Әллә син Йосыфмы?”, - диләр.

Йосыф гәләйһис-сәләм: “Әйе мин Йосыф, ә бу минем энем Бинәмин!” – ди.

Абыйлары куркуларыннан калтырап әйттеләр: “Әй Йосыф без хата кылганнардан булдык”.

Йосыф гәләйһис-сәләм: “Бүген мин сезне хөкем итмим. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһы Тәгалә гафу итсен! Минем шушы күлмәгемне алып кайтып әтиемнең йөзенә ябыгыз. Шуннан соң әтиемнең күзләре ачылыр, күрә башлар. Әтием һәм барчагыз Мисырга минем яныма килегез!” – дип туганнарын чакыра.

Йосыф гәләйһис-сәләмнең абыйлары Мисырдан кайтырга чыгып киткәч, әтиләре Ягъкуп: “Мин Йосыфның исен сизәм”, - ди. Янындагылар: “Син элеккечә Йосыф белән саташасың”, - диләр. Уллары кайтып җитеп, әтиләренең йөзенә Йосыфның күлмәген ябалар. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән Ягъкуп гәләйһис-сәләмнең күзләре яңадан ачыла – ул күрә башлый. Шуннан соң барчасы җыелып Мисырга күченәләр. Йосыф гәләйһис-сәләм әти-әнисен хөрмәтләп тәхеткә утырта. Аннары Йосыфны ихтирам итеп барчасы сәҗдә кылалар.

## Бу кыйссадан алган файдалар

- Башкаларга көнчелек кылу яхшыга китерми икәнлеген.
- Абыйлы-энеләләр һәм гомумән туганнар дус-тату яшәргә, бер-берсенә ярдәмләшеп торырга кирәклеген.
- Ягъкуп гәләйһис-сәләм, килгән кайгы-хәсрәтләргә, бик күркәм сабырлык күрсәткәнен.
- Йосыф гәләйһис-сәләмнең, хатын аны гөнаһ кылырга чакырса да, Аллаһы Тәгаләдән куркам дип, бу начар гамәлдән баш тартуы.
- Йосыф гәләйһис-сәләмнең тәкъвалы булуыннан үрнәк алуым.
- Аллаһы Тәгалә Йосыф гәләйһис-сәләмгә төш юрау нигъмәтен биргәнен.
- Аллаһы Тәгалә Йосыф гәләйһис-сәләмне бөек нигъмәтләр белән нигъмәтләндерүе, аны югары дәрәҗәләргә күтәрүе.
- Ягъкуп гәләйһис-сәләмнең гаиләсе, озак вакыт аерылып торганнан соң, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән янә җыелуы.



# 3-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘД ﷺ НЕҢ ТОРМЫШЫННАН




### *1. Кәгъбәне төзү*


Берничә ел рәттән Мәккәдә көчле яңгырлар һәм давыллар булып уза. Бу афәтләрдән соң Кәгъбә төзекләндерүгә мохтаҗ бер хәлдә иде.

Мәккә халкы аның диварларын яңадан төзергә була. Кәгъбә ташлары арасында Хаҗәрүл-әсвәд ташы бар иде. Ул ташны үз урынына куяр вакыт килеп җиткәч, кешеләр арасында зур бәхәсләр килеп чыга. Һәрберсенең бу мөбарәк кара ташны урынына үз куллары белән куясы килә.

Ниһаять, бәхәсләшүчеләр: “Мәчет капкасыннан беренче булып кем керә, бәхәсне шул хөкем итәчәк”, - дип килешәләр.

Беренче булып Мөхәммәд ﷺ керә. “Ул намуслы һәм тугрылыклы, - диделәр кешеләр, - без аның хөкеменә буйсыначакбыз”.

Мөхәммәд ﷺ үзенең өс киемен сала, аны җиргә җәя һәм аның өстенә Хаҗәрүл-әсвәдне куя. Аннары ул кабилә башлыкларына киемнең читеннән тотып, аны таш белән бергә күтәрергә куша. Кара таш шул рәвешле дивар биеклегенә күтәрелгәч, ул аны үз урынына куя.



## 2. Хәдичәгә өйләнү

Мөхәммәд ﷺ нең намуслылыгы һәм тугрылыгын ишетеп, Хәдичә исемле бер ханым аны үзенә эшкә ала һәм сәүдә итәргә Сүриягә җибәрә.

Мөхәммәд ﷺ бу эшне намус белән башкара, сәүдә зур табыш китерә. Хәдичәгә аның намуслы, ышанычлы кеше булуы турында хәбәр ирешә. Озакламый Мөхәммәд ﷺ Хәдичәгә өйләнә. Ул вакытта аңа – 25, ә Хәдичәгә 40 яшь була. Хәдичә игелекле, яхшы күңелле кеше була. Бу никахтан ул бик бәхетле була. Пәйгамбәребез ﷺ гә Касыйм, Габдулла, Зәйнәп, Рокыя, Өммегөлсем һәм Фатыйма исемле балалар таба. Ир балалары кечкенәдән үк вафат булалар, ә кыз балалары ул исән вакытта, кияүгә чыккач үләләр. Бары Фатыйма гына әтисенең вафатыннан соң алты ай узгач үлә.

## 3. Вәхинең иңдерелә башлавы

Мөхәммәд ﷺ кешеләрдән аерымрак, ялгызы булырга ярата иде. Ул Мәккәдән ерак булмаган таудагы Һира исемле тау куы-



шына керә иде. Уйланып, ул анда көннәрен һәм төннәрен гыйбадәттә үткәрә иде. Үзе белән азык-төлек ала. Ашарына беткәч, өенә кайта, ризыклар ала һәм яңадан тау куышына әйләнеп килә иде.

Пәйгамбәребез ﷺ гә 40 яшь булганда, Рамазан аенда Һира тау куышында ятканда аның янына олуг фәрештә Җәбраил гәләйһис-сәләм килә. Җәбраил гәләйһис-сәләм аны нык итеп кочагына кыса. Аннары җибәрә дә әйтә: “Укы! – дип. Мөхәммәд ﷺ аңа: “Мин укый белмим”, - дип җавап бирә. Җәбраил гәләйһис-сәләм боерыгын икенче тапкыр кабатлый, Мөхәммәд ﷺ аңа шулай ук җавап кайтара. Җәбраил гәләйһис-сәләм өченче тапкыр әйтә: “Кешене кан төереннән бар иткән Аллаһы хакына укы! Укы, һәм сине каләм белән өйрәткән игелекле Раббың кешене ул белмәгән нәрсәләргә өйрәтте”. Бу Коръәндәге “Әл-Галәк” сүрәсенең беренче биш аяте иде.

Бу вакыйга Мөхәммәд ﷺ не куркуга сала. Ул тау куышыннан өенә кайткач, дулкынланып, Хәдичәгә: “Ябыгыз минем өстемә, ябыгыз”, - ди. Хәдичә аның өстенә юрган яба да, ни булганын сөйләргә куша. Мөхәммәд ﷺ үзе белән ни булганын сөйләгәннән соң, Хәдичә әйтә: “Шатлан, кадерлем, җанымны кулында тотучының исеме белән ант итеп әйтәм, син пәйгамбәр булачаксың. Ант итәм, Аллаһы Тәгалә сине беркайчан да оятка калдырмас. Чынлап та, син туганлыкны хөрмәт

итәсең, көчсезләрне, җәберләнгәннәрне яклыйсың, кешеләргә карата кунакчыл һәм гадел".

Хәдичә иренең кулыннан тота да, аны укымышлы булган туганы Вәрәка ибне Нәүфәлгә алып китә. Хәдичә Мөхәммәд ﷺ күргәннәре турында сөйләгәч, Вәрәка: "Муса янына төшкән Җәбраил бу. Эх, халык сине куган чакта мин исән булсам иде!" – ди. Мөхәммәд ﷺ гаҗәпләнеп: "Алар мине куачакlармыни?" – дип сорый. "Әйе, - ди Вәрәка, - син алып килгән нәрсә белән килгән кешене дошман күрмәүче юк әле. Әгәр шул көнгә кадәр яши алсам, мин сиңа ярдәм итәрмен". Ләкин, озак та үтми, Вәрәка вафат була.

## *4. Исламга өнди башлау*

Һира тау куышында булган вакыйгадан соң берничә көн үткәч, пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә Аллаһның сүзләре ишетелә башлый: "И киемгә төренгән бәндә! Тор һәм белдер, Аллаһыңны данла һәм киемеңне чистарт, гөнаһтан кач һәм игелекне, үзеңә мал җыю максатында, эшләмә, Раббың хакына түз".

Мөхәммәд ﷺ Аллаһның сүзен үти. Ул, Сафа тавына менеп, халыкны чакыра. Кешеләр җыелгач, ул аларга: "Әгәр мин сезгә, бу тау артында сезне яулап алу өчен уңайлы вакытны көтеп торучы гаскәр бар, дисәм, ышанырсызмы миңа? – дип мөрәҗәгать итә. Алар: "Әйе, син – бер табы да булмаган кеше, һәм без синең алдаганыңны һичвакыт белмибез", - дип җавап бирәләр. "Мин сезгә барын да алдан ачык әйтеп бирүче, сезне мәрхәмәтсез газаптан коткаручы", - ди пәйгамбәр. Кешеләр арасында аның

тәкәббер абыйсы Әбү Ләһаб була. Ул аңа: “Син безне шуның өчен чакырдыңмы?” – ди. Соңыннан Аллаһы Тәгалә аңа карата мондый сүзләр индерә:

تَبَّتْ يَدَا أَبِي لَهَبٍ وَتَبَّ مَا أَغْنَى عَنْهُ مَالُهُ وَمَا كَسَبَ سَيَصْلَى نَارًا ذَاتَ لَهَبٍ وَامْرَأَتُهُ

حَمَّالَةَ الْحَطَبِ فِي جِيدِهَا حَبْلٌ مِنْ مَسَدٍ

“Әбү Ләһабның ике кулы корысын һәм һәлак булсын! Аңа байлыклары һәм җыйган башка маллары ярдәм итмәде. Ул ялкынлы утта яначак. Дәхи хатыны да утын күтәргән хәлдә утка керер. Ул хатынның муенында хөрмә мунчаласыннан ясалган бау булыр”. *(Әл-Мәсәд сүрәсе, 111/1-4).*

Анын хатыны да ире кебек үк явыз, Мөхәммәд ﷺне кулы белән дә, теле белән дә рәнҗетәләр.



## *5. Беренче мөселманнар*

Ислам динен кабул иткән беренче ир кеше - Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, беренче хатын-кыз - пәйгамбәрнең хатыны Хәдичә, беренче малай - аның туганнан туган энесе Гали ибн Әбү Талиб була.

Бервакыт Мөхәммәд ﷺ Гали ибн Әбү Талиб белән шәһәр читенә чыга. Алар кешеләр күзеннән ераккарак китәләр дә намаз укый башлыйлар. Шул вакыт алар янына Галинең әтисе Әбү Талиб килеп чыга һәм туганыннан сорый: "Әйт әле, Мөхәммәд, нәрсә бу?" – ди. Мөхәммәд ﷺ: "Бу – Аллаһ дине, Аның фәрештәләре дине, Аның пәйгамбәрләре дине, атабыз Ибраһим дине. Аллаһ мине аның белән үз коллары янына җибәрде. Син игелекле нәсыйхәт бирерлек һәм хак юлга өндәргә лаек кешеләрнең берсе. Һәм син, моңа ризалык биреп, миңа ярдәм итәргә тиешсең", – ди.

Әбү Талиб болай дип җавап бирә: "Ата-бабам динен ташласам, гарәпләр миңа ни әйтерләр? Әмма, Аллаһы белән ант итәм, мин исән вакытта сине беркемнән дә рәнҗеттермәм" - ди. Аннары ул, малаена борылып: "Ә син ни эшлисең?" – дип сорый. Гали: "Әти, мин Аллаһка һәм Аның рәсүленә ышандым, аның белән бергә намаз кылдым һәм аңа иярдем", - дип җавап бирә. Әбү Талиб әйтә: "Чынлап та, ул гел яхшылыкка гына өнди, аңа ияр", - ди.

Әбү Бәкер Исламга өндәүдә, пәйгамбәрнең иң якын булышчысына әверелә. Яшерен генә ул кешеләрне Исламны кабул

итәргә чакыра, аларда дингә мәхәббәт, сыннарга табынуга нәфрәт уята. Аның тырышлыгы аркасында Госман ибн Гаффан, Әз-Зөбәер ибн әл-Әүвам, Муса ибн Гомәр, Сәгадәт ибн Әбү Вәккас, Билал ибн Рабах, Әммар ибн Ясыйр, Халид ибн Сәет, Хәбиб ибн әл-Арат һәм башка бик күпләр мөселман булалар.

Беренче мөселманнар үз кабиләдәшләре тарафыннан каты җәзага дучар ителәләр. Динсезләр, бер мөселманны түшәмгә бәйләп куеп, аска учак ягалар. Бәхетсез җан төтенгә тончыга, буылып ютәлли башлый, әмма, шуңа да карамастан, үз динендә кала, сынга табынудан ваз кичә. Икенчесен, бау белән бәйләп, чыбыркы белән кыйныйлар, тик ул да үз диненнән кайтмый.

Муса ибн Гомәр дигән егет шәп тормышта яшәргә күнеккән була. Ефәктән генә киенә, алтын бизәнгечләрдән генә йөри. Ислам динен кабул иткәч, гаиләсе аңа иң начар киемнәр генә бирә башлый. Аны казыкка бәйләп куялар, ипи белән су гына биреп торалар. Әмма мондый җәберләүләр дә аны диненнән ваз кичтерә алмый.

Билалга килгәндә исә, аны чишендереп, кайнар кояш нуры астында кызган комга ташлыйлар, күкрәгенә авыр таш куялар. Ә ул бертуктаусыз: “Бердәнбер! Бердәнбер! (ягъни Аллаһы бер, бердәнбер!)” – дип кабатлый.

Сәгадәт ибне Әбү Вәккасның Исламны кабул итүен әнисе бик авыр кабул итә, аңа ачулана, улы яңадан сыннарга табына башлаганчы, авызына ризык алмаска сүз бирә. Шулай өч көн үткәннән соң Сәгадәт аңар әйтә: “Күпме вакыт ач торсаң да мин бер Аллаһка табынудан баш тартмаячакмын”, – ди. Аның

кире чигенмәсен белгәч, әнисе ашый башлый, әмма улын ябып куярга боера. Сәгадәтне һәркөн кыйныйлар. Соңыннан ул, гаилә малыннан мәхрүм булып, качып китә.

Исламны кабул итеп, Әммар ибн Ясир үзенең әтисен дә мөселман булырга күндерә. Исламны әнисе Сөмәйә дә кабул итә. Аларны, үлем җитүен тойсыннар өчен, чыбыркы белән кыйныйлар, башларын суга батыралар. Тик алай да алар үз диннәреннән кайтмыйлар.

Тимерчелек белән шөгыльләнүче Хәббаб ибн әл-Әрапит Исламны кабул итә. Аның хуҗа хатыны Өмме-Һаммар тимерне кыздыра да аның тәненә баса. Әмма Хәббаб кабул иткән диненнән баш тартмый. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән ул бу газаптан котыла.

Аллаһка чын-чынлап ышанган бу кешеләргә тән җәзалары гына комачаулык итә алмый. Алар Аллаһ хакына түзәләр һәм Ислам динен таратуда беренче юл яручылардан булалар.

## *6. Хабәшстанга күчеп китү*

Көрәешләрнең изүе тагын да рәхимсезрәк була башлагач, Пәйгамбәр ﷺ сәхабәләренә Хабәшстанга күчәргә тәкъдим итә. Аларның шактые шунда күчеп китә. Башта 14 ир-ат һәм 4 хатын-кыз, аннары хатын-кыз һәм балалардан тыш, 80 ир-ат китә.

Көрәешләр Хабәшстанга китүчеләргә зыян салырга ниятләп, үзләреннән Әмру ибн Әл-Гас белән Габдулла ибн Рабияны җибәрәләр. Алар Хабәшстан патшасы Негус һәм руханилар-

га бүләкләр тапшыралар, мөселманнар һәм Ислам дине хакында ялган сүзләр (үз илләреннән күчеп килүче мөселманнарны куып чыгарулары өчен) сөйлиләр.

Негус акыллы була, тикшермичә хөкем чыгармый. Ул күчеп килүчеләрне чакырта да, алар кабул иткән дин турында сораша.

Мөселманнар исеменнән Җәгъфәр ибн Әбү Талиб сөйли. Ул Исламга өндәүнең ни икәнен Негуска аңлата, Исламга хәтле нинди булганнарын, сыннарга табынулары турында сөйли. Негус аннан Мөхәммәд ﷺ өйрәтүләреннән нәрсә булса да укуын сорый. Җәгъфәр ибн Әбү Талиб аңа "Мәрьям" сүрәсен укый. Ул аны тыңлый. Сүрә аңа бик нык тәэсир итә – күңеле тулып елый. Шуннан соң Негус мөселманнарны көрәешләргә кайтарып бирүдән баш тарта һәм аларга Хабәшстанда иркенләп яшәргә ризалыгын бирә.

## *7. Олы кайгы елы*



Әбү Талиб үлем түшәгендә ята. Аның янына үз халкының ихтирамлы кешеләре килә. Әбү Җәһил әйтә: "Әбү Талиб! Син безгә ничек кадерле икәнеңне үзең беләсең. Менә инде синең соңгы сәгатьләрең якынлаша. Безнең белән энең арасында нәрсә булганын яхшы беләсең. Әйт аңа, ул безгә тимәсен, без аңа тимәбез. Ул безгә һәм динебезгә кагылмасын, без аңа һәм аның диненә кагылмабыз", - ди. Әбү

Талиб энесе Әбү Габбастан Мөхәммәд ﷺ не чакырып китерүен сорый һәм аңа шул хакта әйтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтә: “Сез: “Аллаһтан башка иләһ юк”, - дип әйтегез һәм Аннан башка табына торган бар нәрсәгезне юк итегез”, - ди. Җыелган кешеләрнең кайберләре моңа каршы: “Мөхәммәд, син күп иләһләрне бердәнбер Аллаһ итмәкчеме?” – дип сорыйлар. Аннары бер-берсенә карашып: “Валлаһи, без теләгән нәрсәгә бер генә тамчы да риза булмаячак бу”, - дип әйтәләр.

Әбү Талиб үлә, Пәйгамбәр ﷺ белән көрәешләр арасында мөнәсәбәт тагы да кискенләшә. Рәсүлуллаһ ﷺ өчен абыйсының үлеме зур кайгы була, чөнки көрәешләр, аңа карата, тагын бер явызлык эшләргә ниятләгәндә, Әбү Талиб алар юлына каршы төшә торган була.

Көрәешләрнең мөселманнарга карата булган мөнәсәбәтләре Хәдичәнең сәламәтлеген какшата. Ул авырый башлый. Авыруы һаман көчәя һәм Әбү Талибның вафатыннан соң берничә көн узгач, Хәдичә үлә. Шулай итеп, Пәйгамбәребез ﷺ тугрылыклы, юатучы, акча белән ярдәм итүче һәм нык булырга өндәүче хатынын югалта.

## *8. Таифка бару*

Бер көнне Пәйгамбәребез ﷺ Мәккә шәһәреннән ерак булмаган Таиф шәһәренә китә. Таиф халкын Ислам диненә чакыра, төрле сыннарга табынудан ваз кичеп, бер Аллаһка табынырга чакыра. Тик беркем дә кабул итми. Кабул итмәү белән генә чикләнмиләр,

куеннарына таш җыйнап, Пәйгамбәр ﷺ гә аталар. Пәйгамбәр ﷺ нең мөбарәк тәне бик күп урыннан җәрәхәтләнә. Аяклары да яралардан йөри алмас хәлгә килә. Бер агач астында хәл алгач, кулын күтәреп дога кыла: “Аллаһым, бу милләткә туры юлны насыйп ит, чөнки алар минем кем икәнемне белмиләр, белсәләр, һич шулай эшләмәсләр иде”.

Бераздан соң мең җәфа белән Мәккәгә кайта. Мәккәдә Ислам динен таратуны дәвам итә.

## *9. Мөхәммәд ﷺ нең Мәккәдән Коддуска төнге сәяхәте һәм күккә ашуы*



Бер төнне Пәйгамбәребез ﷺ һичкемгә һәм һичбер пәйгамбәргә насыйп булмаган хәлләргә лаек була. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез ﷺ не, дөньядан аерып, кеше миллиард елда да булдыра алмаслык җирләргә чыгара һәм гиздерә.

Пәйгамбәр ﷺ бер кичтә Мәккә шәһәрендәге Хәрам мәчетеннән Коддус шәһәрендәге (Иерусалим) Әкса мәчетенә күчеп, анда намаз укый. Бу вакыйга “Исра” дип атала.

Соңыннан ул ﷺ күккә ашып, Аллаһы Тәгалә аңа Җәннәтне, Җәһәннәмне күрсәтә. Пәрдә аркылы Аллаһы Тәгалә белән сөйләшеп, Аллаһ аның өммәтенә биш вакыт намазны фарыз кыла. Бу вакыйгага “Миграҗ” кичәсе диелә.

## *10. Пәйгамбәр ﷺ нең Мәдинәгә һиҗрәт кылуы (күчеп китүе)*

Мәккә кяферләре потларга табынып яшәгәндә, Мәдинә шәһәрендә бик күп кешеләр Ислам динен кабул итә. Алар Мәккәгә Кәгъбәтулланы зиярат итәр өчен киләләр. Акабә дигән җирдә Пәйгамбәр ﷺ белән күрешеп, иман китерәләр. Бу күрешү һәм иман китерүгә “Акабә бәйгате” (“Акабә анты”) диелә.

Мәккә кяферләренең золымыннан газап чиккән бик күп мөселман Мәдинә шәһәренә күчеп китә. Хәзрәти Гомәр һәм Хәзрәти Госман да һиҗрәт итүчеләр белән бергә булалар. Кайбер мөселманнар күчәргә теләсәләр дә, Мәккә кяферләре аларның күченүләренә киртәләр кора.

Кяферләр бер көнне бер өйдә җыелалар. Пәйгамбәр Мөхәммәд ﷺ не “юк итүдән башка чара калмады” дип бер сүздә булалар. Һәм: “Һичшиксез үтерергә!” – дип карар кылалар.

Милади 622 нче елда кяферләр Пәйгамбәребез ﷺ нең өен уратып алалар һәм өйдән чыгуын көтәләр. Әгәр күренсә, шундук үтерәчәкләр. Пәйгамбәребез ﷺ бу төндә үз урынына Гали ибн Әбү Талибне яткыра. Пәйгамбәр ﷺ үзе “Ясин” сүрәсен укый-укый, өен уратып алган кяферләрнең арасыннан чыгып китә.

Һичбер кяфер аны күрми, чөнки Аллаһы Тәгалә аларның күзләрен күрмәс, танымас хәлгә китерә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ Хәзрәти Әбү Бәкер белән бергәләп, Мәккәдән чыгып китәләр. Иртән кяферләр Пәйгамбәребез ﷺ нең урынында йоклап яткан Галине күргәч, шашып калалар. Өметсезлеккә төшәләр. Тиз арада һәр тарафка үз кешеләрен җибәрәләр. Пәйгамбәребез ﷺ исә Әбү Бәкер белән Мәккәдән чыгуга, Сәвр тавындагы бер мәгарәдә өч көнгә кала. Кяферләр эзләнә торгач, шул мәгарәнең каршысына киләләр. Тик мәгарәнең тишегенә, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, бер үрмәкүч пәрәвәз ятмәсе үрә һәм бер күгәрчен, оя корып, җылы йомыркалар өстенә кунаклый. Кяферләр исә, үрмәкүч белән күгәрчен оясын күреп, мәгарәнең эченә күз дә салмыйча китеп баралар.


Хәзрәти Әбү Бәкер Пәйгамбәребез ﷺ гә берәр зарар килүеннән бик курка. Пәйгамбәр ﷺ исә аңа: “Курыкма! Аллаһ безнең белән бергә”, - диеп юата.

Бу өч көн эчендә бер көтүче аларны азык белән тәэмин итә. Өч көннән соң Мәдинә шәһәренә бару өчен туры юлга чыгалар.

Яшерен юлда барганда, аларны эзләүчеләрдән берсе ат белән куып җитә. Тик Аллаһның кодрәте белән атының аяклары комга бата. Урыныннан кузгала алмый. Коты очып, Пәйгамбәребез ﷺ нән коткаруын сорый. Пәйгамбәр ﷺ аның үтенечен кабул итә. Аты котылып, кире кайтып китә. Ул бу якка борылган башкаларны да юлдан бора: “Мин тикшереп чыктым, беркем дә юк”, - дип әйтә.

Мәдинә халкы Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ не Әбү Бәкер белән килеп җитүләрен түземсезлек белән көтәләр. Һәр көнне: “Менәменә килеп җитәрләр”, - диеп, сөенеч белән юлларын күзлиләр.

Ниһаять бер көнне ак киемле мөбарәк юлчылар Мәдинәгә килеп җитәләр. Мөселманнар “Аллаһү Әкбәр! Аллаһү Әкбәр!” дип бер-берсен уздырып, шатланышып Пәйгамбәр ﷺ гә каршы йөгерәләр. Аны искитмәле яхшы каршылыйлар.



Һәркемнең Пәйгамбәр ﷺ не кунак итәсе, үз өенә алып кайтасы килә, әмма Пәйгамбәр ﷺ дөясенең кая барып ятканын көтә. Ниһаять, дөя Сәхли һәм Сөхәйли ибн Әмру дөяләрен туплый торган урынга барып ята.

Шушы урында Пәйгамбәр ﷺ мәчет салдыра. Үз өен төзегәнче ул Әбү Әйюб өендә яши. Мәчет бик гади: идәне җир, түбәсе гади хөрмә агачыннан була.

Һиҗрәт Ислам тарихына гаять зур йогынты ясый. Шунлыктан, хәлифә Гомәр ибн Хаттаб ел исәбен һиҗрәттән башлап саный башлый. Һиҗрәттән соң көчсезлек һәм кимсетелүләр чоры бетә, көч һәм куәтлелек дәвере башлана.

Мәккәдән Мәдинәгә күчкән мөселманнарга “мөһаҗирләр” дип, ә Мәдинәдә аларга төрле-төрле ярдәм күрсәтүчеләргә “әнсарлар” диелә.

Мәдинәдә ныгып, Рәсүлүллаһ ﷺ Ислам дәүләтен төзи. Ул мөһәҗирләр белән әнсарларның үзара туганлашуын тели.

Пәйгамбәр ﷺ Мәдинәдә яшәүче бар халыкка – мөһаҗирләргә, әнсарларга, яһүдиләргә кагылышлы килешү төзи.

Мәдинәи-Мөнәвәрә халкы берләшә, анының җире теләсә кайсы дошман өчен яулап ала алмаслык кальгага (крепостька) әверелә. Биредә яшәүчеләргә һөҗүм итәргә дошман көчсез булып кала.

Зәкят бирү һәм ураза тоту - фарыз. Чикләр билгеләнә һәм Ислам дәүләте ныгый. Тәүлегенә биш тапкыр намазга чакырып азан әйтелә башлый.

## 📖 Йә Мөхәммәд Мостафа

Сиңа булды дин - Ислам, китабың булды Коръән,
Бөтен галәмгә солтан, йә Мөхәммәд Мостафа!
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Аллаһ сине бар итте, Үзенә һәм яр итте,
Рәсүлләргә таҗ итте, йә Мөхәммәд Мостафа!
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Аллаһ сине чакырды, Җәбраил килде алырга,
Һич мөмкин түгел иде бармыйча калырга.
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Сәфәр кылдың күкне син, анда күрдең күпне син,
Җаның һәм дә тәнең дә ашканыңны хаклыйдыр.
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Сәлам бирде Ходаем Үзенең Рәсүленә,
Биш намаз фарыз итте өммәтләре өстенә.
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!


Күп рәхмәт булсын сиңа, чүк сәлам булсын сиңа,
Шәфәгать әйлә безгә, йә Мөхәммәд Мостафа!
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Әссалаваты вәссәламе гәләйкә, йә Рәсүлүлла!
Әссалаваты вәссәламе гәләйкә, йә Хабибулла!
Салләл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

## Бу бүлектән белгәннәрем

- Пәйгамбәребез ﷺ нең кешеләр арасында ышанычлыгы һәм гаделлеге белән билгеле булуы.
- Хәдичәгә өйләнүе һәм ул аңа Касыйм, Габдулла, Зәйнәп, Рокыя, Өммегөлсем һәм Фатыйма исемле балалар табуы.
- Пәйгамбәребез ﷺ гә 40 яшь булганда вәхи иңдерелә башлавы.
- Кешеләрне Исламга өнди башлавы.
- Ислам динен кабул иткән беренче ир кеше - Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, беренче хатын-кыз - пәйгамбәрнең хатыны Хәдичә, беренче малай - аның туганнан туган энесе Гали ибн Әбү Талиб булганы.
- Беренче мөселманнар каты җәзага дучар ителүләре.

- Мөселманнарның Хабәшстанга күчеп китүләре.
- Әбү Талибның һәм Хәдичәнең үлүе олы кайгы китерүе.
- Пәйгамбәребез ﷺ нең Таиф шәһәренә барып, кешеләрне Ислам диненә өндәве, ләкин аны кабул итмәүләре, ә киресенчә аңа таш атулары.
- Пәйгамбәребез ﷺ нең Мәккәдән Коддус шәһәрендәге “Әкса” мәчетенә күчүе (“Исра” вакыйгасы), ә соңыннан күккә ашып, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшүе (“Миграҗ” кичәсе).
- Мәккә кәферләренең Пәйгамбәребез ﷺ не үтерергә җыенулары.
- Пәйгамбәребез ﷺ нең Әбү Бәкер белән Мәдинәгә һиҗрәт (күчү) өчен чыгып китүләре һәм күп авырлыклар кичереп барып җитүләре.
- Мәдинәдә мәчет салынуы.



# 4 -НЧЕ БҮЛЕК

## МӨСЕЛМАННЫҢ КҮРКӘМ ХОЛЫКЛАРЫ

### *1. Тугрылык*

Тугрылык – ул сөйләгән сүзләрдә, эшләгән эшләрдә һәм хәрәкәтләрдә дөрес булу дигәнне аңлата, ягъни ялган сөйләмәү, беркемне дә алдамау, башкаларга карата хәйлә кормау. Тугрылыкны Аллаһы Тәгалә мөселманнарга фарыз кылган. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә:

يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَكُونُوا مَعَ الصَّادِقِينَ

“Әй, мөэминнәр! Аллаһтан куркыгыз һәм тугрылар белән булыгыз”. *(Тәүбә сүрәсе, 9/119).*



Мөселман, сүз сөйләгәндә, өч нәрсәгә игътибар итәр:

- сүз сөйләгәндә, дөрес сөйләр;
- вәгъдә бирсә, вәгъдәсендә торыр;
- хәленнән килмәгән нәрсәләрдә вәгъдә бирмәс.

Тугры булганнарны Аллаһ та, кешеләр дә ярата. Ялганчыларны һәм алдакчыларны Аллаһ та, кешеләр дә яратмый.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә:

يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلًا سَدِيدًا

“Әй, мөэминнәр! Аллаһтан куркыгыз һәм сөйләгән вакытта тугры сөйләгез”. *(Әл-Әхзәб сүрәсе, 33/70).*

Кеше белмәс, сизмәс дип ялганлау, алдалау шикелле эшләрне эшләргә һич ярамый, чөнки ниятләребезне һәм эшләгән эшләребезне Аллаһы Тәгалә һәрвакыт күреп һәм белеп тора. Иңдәге ике фәрештәләребез гөнаһ һәм савапларыбызны язып баралар. Кешеләрне алдасак та (алдарга ярамаган булса да), Аллаһы Тәгаләне алдау мөмкин түгеллеген истән чыгарырга ярамый.

**Мөселман тугры була һәм ялган сөйләми, кешеләрне алдаламый.**

## *2. Мәрхәмәтлек һәм йомшак күңеллелек*

Мәрхәмәтле – ул шәфкатьле һәм ярдәмчел булу дигәнне аңлата. Мөселман каты йөрәкле, каты күңелле түгел, киресенчә, мәрхәмәтле һәм йомшак күңелле булырга тиеш. Шушындый сыйфатларны йөртүче кеше башкалардан һәрвакыт өстен һәм хөрмәткә лаек булыр.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Аллаһы Тәгалә Үзенең рәхмәт һәм мәрхәмәтен йөз өлешкә аерды. Туксан тугыз өлешен үзе янында калдырып, бер өлешен генә җир йөзенә төшерде. Менә бу бер өлеш мәрхәмәт аркылы кешеләр бер-берләренә мәрхәмәт күрсәтерләр".

Каты күңелләр, башкаларга авырлыклар китерүчеләр дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле була алмаслар.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Кешеләргә мәрхәмәт кылмаган кешегә Аллаһы Тәгалә дә мәрхәмәт кылмас".

Мөселманнар алар, бер гәүдәнең әгъзалары кебек: гәүдәнең

әгъзалары, бер-берләренә булышып, ярдәмләшеп, гәүдәнең сәламәтлеген саклаган кебек, мөселманнар да, бер-берләренә таянып, бер-берләренең кайгыларын уртаклашып, мәрхәмәт һәм шәфкать күрсәтеп, араларындагы сөю һәм хөрмәтне арттырырга тиешләр.

Мөселман булган кеше, кешеләргә карата гына түгел, хайваннарга да мәрхәмәтле булыр. Зарары булмаган хайваннарны үтермәс, ач һәм сусыз калдырып яисә юкка кыйнап, хайваннарга авырлык китермәс. Ислам динендә, кешеләрнең генә түгел, хайваннарның да хакы һәм хокукы бар.

Бер вакытны Пәйгамбәребез ﷺ сәхабәләренә Җәһәннәмле булган бер хатын турында сөйләгән. Бу хатын, мәчесенә ачуланып, аны бер бүлмәгә ябып куйган. Мәчесенә аш та, су да бирмәгән, һәм шулай итеп, мәченең ачка үлүенә гаепле булган. Бу хатын, мәчесенә мәрхәмәт кылмаганы өчен Җәһәннәмле булган.

**Мөселман каты йөрәкле һәм каты күңелле түгел, ә мәрхәмәтле һәм йомшак күңелле була.**

## *3. Ярдәмләшү һәм юмартлык*

Юмартлык – ул үзенә нинди дә булса файда килүне өмет итмичә кешеләргә ярдәм итүгә әйтелә.

Кешеләр арасында көчлеләр дә һәм зәгыйфьләр дә, байлар да

һәм ярлылар да, галимнәр дә һәм белемсезләр дә, олылар да һәм кечкенәләр дә бар. Һәрбер кеше, кем булуына карамастан, бер үзе генә яши алмый. Ул башка кешеләрнең ярдәменә дә мохтаҗ. Шул сәбәпле, динебез үзара ярдәмләшүне һәм юмартлыкны фарыз кылган. Юмартлыкның киресе булган саранлык хәрам кылынган.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: “Юмартлык – ботакларын дөньяга сузган Җәннәт агачларыннан берсе. Кем бу ботакларның берсенә тотынса, ул аны Җәннәткә тартыр. Саранлык – ботакларын дөньяга сузган Җәһәннәм агачларыннан берсе. Кем бу агачның ботагына тотынса, ул аны Җәһәннәмгә тартыр”.

Ислам тарихында иң зур юмартлык күрсәткән кеше Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ. Сәхабәләрнең берсе шулай дигән: “Пәйгамбәребез ﷺ нән нәрсә сорасаң да һич кире бормый иде. Булса бирә, булмаса бирергә вәгъдә итә иде”.

Динебездә ярдәм ике өлешкә аерыла: 1) мал һәм акча белән ярдәм итү; 2) кайгылы кешеләрне тынычландыра торган сүзләр белән юату, үгет-нәсыйхәт бирү, кешеләргә хак булган нәрсәләрне аңлату, яхшы киңәш бирү, көләч йөзле һәм татлы телле булу һәм башка моңа охшаган эшләр. Бу ике төрле ярдәмнең дә савабы бар.

Үзара ярдәмләшү һәм юмартлыкның кыйммәтен арттырган нәрсә – кылган изге гамәлләребезнең Аллаһы Тәгалә белән безнең арабызда серле калуыдыр. Ярдәм һәм юмартлык белән мактанырга кирәкми, чөнки яхшы эшләр дә, начар эшләр дә – Аллаһы Тәгаләгә мәгълүм.

## 🕮 Гомәрнең (Аллаһ аннан разый булсын) ярдәм итүе

Кичен урамда йөргәндә, бер өйдә ут янып торганны күреп һәм балалар елаган тавышны ишетеп, хәлифә Гомәр шул якка



юнәлгән. Шунда бер хатынның казанда су кайнатканын күреп: "Бу балалар ни өчен елыйлар, казанда нәрсә пешерәсез?" – дип сораган. Хатын җавабында: "Бу балалар ачлыктан елыйлар, аш пешерәм дип юатып, балаларны йоклату өчен казанда су кайнатам", - дигән. Гомәр моны ишеткәч, әсәрләнеп, тиз генә дәүләтнең Бәйтел-малына барып, бер капчыкка он һәм май салып, аркасына күтәргән. Янындагы хезмәтчесе күтәрергә теләсә дә, кабул итмәгән: "Кыямәт көнендә болар өчен мин соралачакмын", - дип, капчыкны үз аркасына күтәреп, шул хатын өенә барган. Казанга он, май салып, үзе бутап, казан астына үзе утын ягып, аш пешереп, балаларга салып биргән. Шуннан бер якка китеп: "Балаларның елаганнарын күрдем, инде шатланганнарын да

күрим", - дип, балалар ашап туйганчы карап торган. Аларның тамаклары туйгач, үз урыныннан кузгалып китә башлаган. Шул вакыт Гомәрнең кем икәнлеген белмәгән хатын: "Хәлифә булырга Гомәрдән бигрәк син лаек икәнсең, халыкны кайгырту һәм шәфкать синдә күбрәк икән", - дип рәхмәт укып калган.

**Мөселман юмарт булып, саранлык кылмый.**

## *4. Әдәп һәм хая*

Әдәп – тәрбия, күркәм әхлак, нәзакәтлелек димәктер.

Хая – оялу, Аллаһы Тәгаләдән куркып, начар эшләрдән саклану димәктер.

Әдәп һәм хая мөселман булган кеше өчен иң мөһим нәрсәләрнең берсе, чөнки әгәр кешеләрдә әдәп һәм хая булмаса, дөнья тормышының тәртибе бозылыр иде. Кеше эшләгән хата һәм гөнаһларыннан оялмаса, башкалардан тартынмаса, Аллаһы Тәгаләдән курыкмаса, аны начар гамәлләрдән туктатып булмас иде.

Әдәпле кеше башкалар белән үзен тәртипле тотар, олыларны хөрмәт итәр, кешеләргә мәрхәмәтлек һәм йомшак күңеллелек күрсәтер. Андый кеше начар эшләрдән ерак булыр һәм әгәр шундый эшләргә очраса, оялыр, бите кызарыр, үзен гаепле хис итү аркасында борчылыр. Боларга ия булган кеше әдәпле һәм хаяле саналыр.

Ислам динендә әдәп һәм хая кешеләрне ямьсез эшләрдән тукталткан бер калкан, гөнаһлардан саклаучы чара дип кабул ителә.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Оялмаган кеше теләгәнен эшләсен".

Димәк башкалардан оялмаган кеше һәр төрле начар эшләргә дә сәлатле була.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: “Кешеләрдән оялмаган, Аллаһы Тәгаләдән дә оялмас”.

Оялу ике төрле була: 1 – Аллаһы Тәгаләдән оялу. 2 – Кешеләрдән оялу. Аллаһы Тәгаләдән оялу кешеләрдән оялудан да өстенрәк, чөнки Аллаһтан оялу кешеләрне һәртөрле явызлыклардан һәм усаллыклардан туктатыр.

**Мәкальләр, әйтемнәр:**

- Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.
- Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
- Адәмне адәм иткән – әдәп.

**Мөселман баласы үзен һәрвакыт әдәпле тота.**

## *5. Шөкер, шөкер итү*

Шөкер итү – кешенең, үз хәленнән канәгать булып, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен белгертү дигәнне аңлата. Шөкер итү – ул кеше тарафыннан Аллаһы Тәгаләне олылау һәм зурлау.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә санаусыз нигъмәтләр биргән: акыл, рух, гәүдәбезгә көч-куәт, ашау-эчүләребез, саулык һәм башка чиксез нигъмәтләр. Шулай ук, табигатьтәге һәрнәрсәне: һаваны, суны, җиләк-җимешләрне, үсемлекләрне, хайваннарны да бар итүче – Аллаһы Тәгаләдер. Кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылырга

һәм бу нигъмәтләрнең чын хуҗасын һәрвакыт олылап искә алырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә:

وَإِنْ تَعُدُّوا نِعْمَةَ اللَّهِ لَا تُحْصُوهَا

“Аллаһ биргән нигъмәтләрне исәп-хисап итсәгез дә һич тә санап бетерә алмассыз”. *(Ибраһим сүрәсе, 14/34).*

Тормышта кемнән булса да ярдәм күрсәк, аның нинди дә булса нигъмәтенә ирешсәк, аңа рәхмәтләр укыйбыз, ул кешегә хөрмәтебезне белдерергә тырышабыз. Санаусыз ярдәмнәре һәм нигъмәтләре өчен Аллаһы Тәгаләгә һәрдаим шөкер кылырга тиешбез.

Шөкер өч төрле була:

1) Калеб, йөрәк белән шөкер итү – һәр нигъмәтнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгәненә чын йөрәктән ышану.

2) Тел белән шөкер итү – һәр нигъмәтнең Аллаһы Тәгаләдән килгәненә тел белән шөкер итү, ягъни “Әлхәмдүлилләһ” яисә “Аллага шөкер” яки “Алланың биргәненә шөкер” дип әйтү.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: “Аллаһы Тәгалә колына бер нигъмәт бирсә, ул да “Әлхәмдүлилләһ” дисә, бу нигъмәтнең шөкерен үтәгән булыр. Кеше икенче мәртәбә “Әлхәмдүлилләһ” дисә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең савабын арттырыр,

өченче мәртәбә “Әлхәмдүлилләһ” дисә, Аллаһы Тәгалә ул кешенең гөнаһларын гафу итәр”.

3) Әгъзалар белән шөкер итү – бу Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу, Аллаһы Тәгаләнең диненә хезмәт итүдер. Намаз уку, ураза тоту, зәкят бирү, хаҗ кылу кебек гыйбадәтләр белән бергә Аллаһның динен аңлату, тарату һәм бу юлда хезмәт итү дә әгъзалар белән ясалган бер шөкердер.

Безгә ирешкән нигъмәтләрнең барысы да Аллаһы Тәгаләдән дип ышанган мөэмин-мөселман, байлыкка ирешсә, Аллаһ юлыннан бервакытта да тайпылмас, бу нигъмәтләрнең Аллаһтан килгәнен онытмас. Нигъмәте арткан саен шөкере дә арта барыр. Нигъмәткә шөкер итү нигъмәтен арттырыр. Нигъмәтнең кыйммәтен белмәү нигъмәтнең исраф (әрәмшәрәм) булуына сәбәп булыр.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә:

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِنْ شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِنْ كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ

“Дәхи Раббыгыз сезгә белдерде: «Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, минем газабым бик каты», – дип”. *(Ибраһим сүрәсе, 14/7).*

Кеше шөкер кылса, Аллаһы Тәгалә аның күңеленә канәгатьлек, тормышына рәхәтлек һәм тынычлык бирер. Шөкер кылмаучылар күпме баесалар да, күңелләре кайгыдан котылмас, чөнки шөкерсез малның да һәм гомернең дә бәрәкәте булмас.

Шөкер пәйгамбәрләрнең, фәрештәләрнең һәм Аллаһы Тәгаләнең сөекле колларының гадәтләреннәндер. Шөкерне торган

саен арттыра барырга кирәк, чөнки нигъмәтнең исраф (әрәм-шәрәм) булмавына ярдәм иткән иң мөһим нәрсә – шөкердер. Шөкер кылучы һичбер вакыт Аллаһны онытмас. Андый кеше дөньядагы нигъмәтләре белән тәкәбберләнеп, кешеләргә өстен карамас, беркемне дә түбән күрмәс. Нигъмәт ягыннан үзеннән түбәнрәк булган кешеләрнең хәленә карап, алардан дөрес гыйбрәт алыр, үзенең хәленә шөкер итәр.

**Кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылырга һәм нигъмәтләрнең чын хуҗасын һәрвакыт олылап искә алырга тиеш.**

## *Бу бүлектән белгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- Тугрылык – ул сөйләгән сүзләрдә, эшләгән эшләрдә һәм хәрәкәтләрдә дөрес булуну аңлатуын.
- Мәрхәмәтле – ул шәфкатьле һәм ярдәмчел булуны аңлатуын.
- Юмартлык – ул үзенә нинди дә булса файда килүне өмет итмичә кешеләргә ярдәм итүгә әйтелүен.
- Әдәп – тәрбия, күркәм әхлак, нәзакәтлелек дигәнне.
- Хая – оялу, Аллаһы Тәгаләдән куркып, начар эшләрдән саклануны аңлатуын.
- Шөкер итү – кешенең, үз хәленнән канәгать булып, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен белгертүне аңлатуын.

# 5-НЧЕ БҮЛЕК

## ИСЛАМ ӘДӘПЛӘРЕ ҺӘМ ДОГАЛАРЫ

### *1. Мәҗлес әдәпләре һәм догалары*

Мөселман баласы әдәпле-әхлаклы булып, мәҗлестә булганда түбәндәге әдәпләрне үти:

- Берәр мәҗлескә килгәч әдәп белән үзеңә җайлы булган урынга яисә хуҗа тәкъдим иткән урынга утыра.
- Урындыкка утырганда ятмый, аякларның берсен икенчесе өстенә куймый.
- Сөйләүчене әдәп белән тыңлый; кирәкмәгәнгә көлми, теләсә нинди сүзләр сөйләми, сөйләүченең сүзләрен бүлдерми.
- Үзен башкалардан өстен тотмый.
- Мәҗлескә килеп утырганнан соң шушы доганы укый:

اللهُمَّ أَنْزِلْنِى مُنْزِلاً مُبَارَكًا وَأَنْتَ خَيْرُ الْمُنْزِلِينَ

*(Әл-Лааһүммә әнзилнии мүнзилән мүбәәракән вә әнтә хайрул-мүнзилиин)*

Мәгънәсе: “Я Рабби, мине мөбарәк җиргә индер. Әй Раббым, Син иң хәерле индерүчедер”.

- Һәрбер мәҗлестән соң шушы доганы укый:

سُبْحَانَكَ اللهُمّ وَبِحَمْدِكَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ انْتَ أَسْتَغْفِرُكَ وَأَتُوبُ إِلَيْكَ

*(Субхәәнәкәл-Лааһүммә вә би-хәмдикә, әшһәду әл-ләә иләәһә иллә Әнтә. Әстәгфирукә вә әтүүбү иләйкә)*

Мәгънәсе: “Дан һәм мактау Сиңа әй Аллаһ! Синнән башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юклыгына шәһадәт бирәм. Синнән гөнаһларымны гафу итүеңне сорыйм һәм Сиңа тәүбә итәм”.

## *2. Авыруның хәлен белү әдәпләре һәм догалары*

Мөселман баласы әдәпле-әхлаклы булып, авырып киткән туганының яисә дустының хәлен белергә барганда түбәндәге әдәпләрне үти:

- Туганнарының, дусларының авырганнарын ишетсә, хәлләрен белергә бара; яннарына керү мөмкин булмаса, хәлен өйдә булганнардан сорый.
- Авыруның хәлен белергә килгәндә 7 тапкыр түбәндәге доганы укый (укыса бик күркәм булыр):

أَسْأَلُ اللهَ الْعَظِيمَ رَبَّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ أَنْ يَشْفِيكَ

*(Әсъәлүл-Лааһәл-Гәзымә Раббәл-Гәршил-Гәзым әй-яшфиик)*

Мәгънәсе: “Олуг Гарешнең Раббысы Аллаһы Тәгаләдән сиңа шифа бирүен сорыйм”.

- Авыруга сәбәп булган нәрсәләрдән сакланмаганлыгы өчен авыруны әрләми, ә мөмкин кадәр аны тыңлый, күңелен юата, сабырлыкка чакыра, куркытмый, тиз көннәрдә тереләчәгенә өмет уята, сәламәтлеге өчен дога кыла.
- Авыру янында озак утырмый, күңеленә авыр килә торган сүзләр сөйләми.

📖 Гадел мәктәптә хезмәткәр булып эшләүче Ибраһим абыйның авырып киткәнен белә һәм шул хакта сыйныфташла-

рына хәбәр итә: “Ибраһим абый бик әйбәт кеше. Безгә үз балаларына шикелле яхшылык эшли, шул сәбәпле безгә аның хәлен белеп кайтырга кирәк”, - ди. Моны мәктәпнең дин укытучысы ишетә һәм Ибраһим абыйның хәлен белергә баруны бик хуп күрә.

Дәресләр беткәннән соң, укучылар һәм дин укытучылары хастаханәгә юнәләләр. Укучылар Ибраһим абый белән очрашалар, аңа күчтәнәчләрен бирәләр һәм тизрәк сәламәтләнүен теләп дога кылалар. Ибраһим абый бик шатлана һәм килүчеләргә рәхмәтләрен әйтә.

Икенче көнне дин укытучысы дәреснең башында балаларга: “Кичә сез бик саваплы эш башкардыгыз, Ислам динебез кешеләргә карата яхшылык кылырга чакыра. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ үзе дә кешеләр белән изге ният белән сөйләшүче, тыйнак була. Кичә мәктәп хезмәткәре Ибраһим абыйга карата күркәм эш эшләнелде. Ул чынлыкта аны хөрмәт итү һәм шәфкатьлелек иде. Авыруның хәлен белү булды, аңа сәламәтлек теләп дога кылынды”, - диде.

## *3. Һәрвакыт зур файдалар китерә торган догалар*

اللهُمَّ أَرِنَا الْحَقَّ حَقًّا وَارْزُقْنَا الإِتِّبَاعَ إِلَيْهِ وَأَرِنَا الْبَاطِلَ بَاطِلاً وَارْزُقْنَا الإِجْتِنَابَ عَنْهُ

*(Әл-Лааһүммә әринәл-хәкка хәккан вәр-зүкнәл-иттибәгә иләйһи вә әринәл-бәәтыйлә бәәтыйлән вәр-зүкнәл-иҗтинәәбә гәнһү)*

Мәгънәсе: “Әй, Иләһым! Безгә хакны хак итеп күрсәт һәм безне хакка буйсынулы кыйл. Ялганны ялган итеп күрсәт һәм безне аннан өстенрәк, читтәрәк кыйл!”

اللهُمَّ يَا مُقَلِّبَ الْقُلُوبِ ثَبِّتْ قَلْبِى عَلَى دِينِكَ وَطَاعَتِكَ الإِسْلاَمِ

*(Әл-Лааһүммә йәә мүкаллибәл-кулүүби, сәббит калбии илә диииникә вә таагәтикәл-исләәми)*

Мәгънәсе: “Әй, күңелләрне төрлечә бора алучы Раббым! Минем калебемне (күңелемне) динеңә һәм Исламда булган итагатьләргә ныклы кыйл!”

## *Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- мәҗлес әдәпләрен;
- авыруның хәлен белү әдәпләрен.


**Бу бүлектән өйрәндем:**

- мәҗлескә килеп утырганнан соң укыла торган доганы;
- мәҗлестән соң укыла торган доганы;
- авыруны зиярат кылганда укыла торган доганы;
- һәрвакыт зур файдалар китерә торган догаларны.



# 6-НЧЫ БҮЛЕК

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ КИТАБЫ – КОРЪӘН КӘРИМ



### *Коръән Кәримне уку һәм аның гыйлемен үзендә йөртүченең өстенлекләре*

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә әйтә:

إِنَّ الَّذِينَ يَتْلُونَ كِتَابَ اللَّهِ وَأَقَامُوا الصَّلَاةَ

«Шиксез, хак мөэминнәр Аллаһның Китабын укырлар, намазларын вакытында үтәрләр...». *(Фәтыйр сүрәсе, 35/29).*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең хәдис-шәрифләре:

«Сезнең иң хәерлегез – Коръәнне өйрәнүче һәм аны өйрәтүче».

«Коръән укучы мөэмин баллы лимон мисалында булыр: хуш исле, тәме – яхшы. Коръән укымаучы мөэмин хөрмә мисалында булыр: исе юк, тәме – ширбәт. Коръән укучы мөнафикъ рәйхан чәчәге мисалында булыр: хуш исле, тәме – әче. Коръән укымаучы мөнафикъ колоквинт үсемлеге мисалында булыр: исе юк, тәме – әче».

«Кем Аллаһ Китабыннан бер хәреф укыса – аңа савап һәм ул савап унга тапкырлана. Мин әйтмим «Әлиф-ләм-мим» бер хәреф дип, киресенчә, әлиф – хәреф, ләм – хәреф, мим – хәреф».

«Шиксез, кемнең йөрәгендә Коръәннән бер нәрсә дә юк икән, ул ташландык өй шикелле булыр».

«Кем Коръәнне укыды һәм аның белән гамәл кылды Кыямәт көнендә аның ата-анасына таҗ киертелер. Шул таҗның нуры дөнья йортларындагы кояш утына караганда яхшырак булыр. Ә нәрсә уйлыйсыз, шуның белән гамәл кылган кешегә ни булыр икән?»

«Укыгыз Коръән! Шиксез Аллаһы Тәгалә Коръән аңлаучының йөрәген газапламас һәм, шиксез, бу Коръән Аллаһы Тәгаләнең өстәле, һәм кем керде аңа - ул иминлектә, ә кем Коръәнгә гашыйк булды – ул, әлбәттә, шул хәбәр белән сөенсен».

«Шиксез, Аллаһ бу Китап белән халыкларны күтәрә һәм башкаларны бетерә».

«Кыямәт көнендә тоткан ураза һәм Коръән Кәрим шәфәгать итәрләр. Уразасы: «Мин аны көндез ашау һәм теләкләрдән тыйдым, аның өчен шәфәгать итәргә рөхсәт бирче» дип әйтер. Коръән Кәрим: «Мин аны төнлә йокыдан тыйдым, аның өчен шәфәгать итәргә рөхсәт бирче» дип әйтер».

«Көнчелек кылу ике очракта гына рөхсәт ителә: Коръәнне яттан өйрәнеп, көнен-төнен укуга багышлаучы ир кешегә, Аллаһы Тәгалә биргән малны көнен-төнен дин юлына таратучы ир кешегә».


## Фикер кыйлмыйбыз бер дә

Әгәр Коръән иңәр булса
Биек таулар үзәренә,
Куркып, ташлар ярылыр иде,
Фикер кыйлмыйбыз бер дә.

Бу Коръән бик мөкатдәстер,
Анның барча сүзе хактыр,
Анның хөкме – шәригатьтер,
Фикер кыйлмыйбыз бер дә.

Иннә әнзәлнәһү аятьләре
Язылмыштыр бу Коръәндә.
Үзебез укыйбыз көн дә,
Фикер кыйлмыйбыз бер дә.





# ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ

## 3-НЧЕ СЫЙНЫФ



# 1-НЧЕ БҮЛЕК

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ КҮРКӘМ ИСЕМНӘРЕ ҺӘМ СЫЙФАТЛАРЫ

### *1. Иман кәлимәләре*

Мөэмин һәм мөселман булган кешегә – Ислам диненең хаклыгына һәм анда булган һәрбер хөкемгә ышанып – иман китерү һәм ышанганын тел белән әйтү фарыздыр.

Мәгънәләре белән дөрес итеп укырга тиешле булган иман кәлимәләре бар. Күңел белән хаклыгын таныган нәрсәләрне тел белән әйтү өчен шул кәлимәләрне бик дөрес итеп мәгънәләре белән укый белү тиештер. Шул мәшһүр иман кәлимәләрен гарәп телендә әйтү өчен түбәндә аларны, мәгънәләре белән, китерәбез:

*Кәлимәтүн тайибәтүн (күркәм сүз)*

لَآ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ مُحَمَّدٌ رَسُولُ اللهِ

*(«Ләә иләәһә илләә-Ллааһү Мүхәммәдүр-расүүлүллаһ»)*

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы зат (иләһ) юк. Мөхәммәд салләл-Лаһү гәләйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләнең, бәндәләренә шәригать хөкемнәрен ирештерер өчен җибәрелгән, илчесе».

*Кәлимәтү-ш-шәһадәти (шәһадәт кәлимәсе – гуаһлык бирә торган сүз)*

أَشْهَدُ أَنْ لَآ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ

*(«Әшһәдү әл-ләә иләәһә илләә-Ллааһү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһү»)*

Мәгънәсе: «Шәһадәт бирәм: Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы зат (илаһ) юк. Янә шәһадәт бирәм: Тәхкыйк, Мөхәммәд салләл-Лаһү гәләйһи вә сәлләм – Аллаһы Тәгаләнең колы һәм бәндәләргә шәригать хөкемнәрен ирештерер өчен җибәрелгән илчесе».

*Кәлимәту-т-тәүхид (тәүхид кәлимәсе – Аллаһы Тәгаләне Берләү сүзе):*

أَشْهَدُ أَنْ لآ أِلَهَ أِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ. لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِي وَيُمِيتُ وَهُوَ حَيٌّ لاَ يَمُوتُ. بِيَدِهِ الْخَيْرُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

*(«Әшһәду әл-ләә иләәһә иллә-Ллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Ләһүл-мүлкү вә Ләһүл-хәмдү юхии вә юмиитү вә һүә хәйюн ләә ямүүтү. Биядиһил-хайру вә Һүә гәләә күлли шәйин кадиир»).*

Мәгънәсе: «Шәһадәт бирәм: Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы зат (илаһ) юк. Ул Аллаһ ялгыз, Аның тиңдәше юк. Бөтен падишаһлык һәм мактау Аллаһы Тәгаләгә генә хас. Ул Аллаһы Тәгалә терелтә һәм үтерә, ләкин Үзе һәрвакыт терек булып, бер вакытта да үләчәк түгел. Барча хәерле эшләр Аллаһы Тәгаләдән һәм Аның Көч-Кодрәте барча нәрсәгә дә җитә».

*Кәлимәту раддил-куфри (көферлеккә төшүдән сакланып укыла торган сүзләр):*

أَللَّهُمَّ أِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ أَنْ أُشْرِكَ بِكَ شَيْئً وَأَنَا أَعْلَمُ. وَأَسْتَغْفِرُكَ لِمَا لآ أَعْلَمُ. أِنَّكَ أَنْتَ عَلاَّمُ الْغُيُوبِ

*(«Әл-Лааһүммә иннии әгүүзү бикә мин ән үшрикә бикә шәйән вә әнәә әгләму. Вә әстәгфирукә лимәә ләә әгләму. Иннәкә Әнтә гәлләәмүл-гуюб»)*

Мәгънәсе: «Әй Аллаһ! Тәхкыйк, мин, белә торып, Сиңа нәрсәнедер ширек-тиңдәш итүдән сыгынамын. Һәм белмәгән килеш кылынган нәрсәләрдән мине гафу итүеңне сорыймын. Тәхкыйк, Син генә, Раббым, барча яшерен нәрсәләрне Белүчесең».

*Кәлимәтү-л-истигъфәр (гөнаһлар ярлыкауны сораучы сүзләр):*

أَسْتَغْفِرُ اللهَ، أَسْتَغْفِرُ اللهَ، أَسْتَغْفِرُ اللهَ تَعَالَي مِنْ كُلِّ ذَنْبٍ أَذْنَبْتُهُ عَمْدًا أَوْ خَطَئً، سِرًّا أَوْ عَلَانِيَةً. وَأَتُوبُ أِلَيْهِ مِنَ الذَّنْبِ الَّذِي أَعْلَمُ و مِنَ الذَّنْبِ الَّذِي لآ أَعْلَمُ. أِنَّكَ أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

*(«Әстәгфиру-Ллаһә, Әстәгфиру-Ллаһә, Әстәгфиру-Ллаһә Тәгәәләә мин күлли зәнбин әзнәбтүһү гәмдән әү хатаән, сирран әү гәләәниятән. Вә әтүүбү иләйһи минәз-зәнби-лләзи әгләму вә минәз-зәнби-лләзи ләә әгләму. Иннәкә Әнтә гәлләәмүл-гуюб»)*

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгаләдән мине һәрбер гөнаһларымнан ярлыкауны кат-кат телимен, белмичә кыйлган гөнаһларымнан да, хаталык илә кыйлган гөнаһларымнан да, яшерен кыйлган гөнаһларымнан да, ачык кыйлган гөнаһларымнан да. Дәхи, әй Раббым, белеп кыйлган гөнаһларымнан да, белми кыйлган гөнаһларымнан да тәүбә кыйламын (үкенәм һәм аларны эшләмим). Әй Аллаһ, тәхкыйк, Син яшерен нәрсәләрне Белүчесең».

*Кәлимәту-т-тәмҗид (Аллаһы Тәгаләне олуглау һәм мактау сүзләре):*

سُبْحَانَ اللهِ وَالْحَمْدُ للهِ وَلآ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَاللهُ أَكْبَرُ لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ مَا شَاءَ اللهُ كَانَ وَمَا لَمْ يَشَأْ لَمْ يَكُنْ الإِيمَانُ إِقْرَارٌ بِاللِّسَانِ وَتَصْدِيقٌ بِالْقَلْبِ بِمَا جَاءَ بِهِ مِنْ عِنْدِ اللهِ مُحَمَّدٌ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ

*(«Сүбхәәнә-Ллаһи вәл-хәмду ли-Лләһи вә ләә иләәһә илләә-Ллааһу вә-Ллаһу Әкбәр. Ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә би-Лләһил-гәлийил-гәзыым. Мә шәә Әллааһу кәәнә вә мәә ләм яшәъ ләм якүн. Әл-иимәну икраарун бил-лисәәни вә тәсдиикун бил-калби бимә җәә биһимин гиндил-Ләһи Мүхәммәдур-расүүлуллаһ салләл-Лаһу гәләйһи вә сәлләм»)*

Мәгънәсе: «Аллаһы Тәгаләне һәрбер кимчелекләрдән, һәрбер гаепләрдән пакъ дип әйтәмен. Һәрбер макталу белән мактану Аллаһы Тәгаләгә генә хас. Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы зат (иләһ) юк. Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграк. Һич хәл һәм куәт юктыр, мәгәр олуг һәм бөек булучы Аллаһы Тәгалә илә генәдер. Аллаһы Тәгалә нәрсәнең булуын теләсә, ул нәрсә булыр һәм нәрсәнең булуын теләмәсә, ул нәрсә булмас. Иман – ул, Аллаһы Тәгаләнең Рәсүле Мөхәммәд салләл-Лаһу гәләйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгалә тарафыннан алып килгән нәрсәләрнең барчасын, тел белән әйтеп һәм күңел белән дөрес дип тану».

*Иман мүҗмәл (кыскача иман):*

آمَنْتُ بِاللهِ كَمَا هُوَ بِأَسْمَآئِهِ وَصِفَاتِهِ وَقَبِلْتُ جَمِيعَ أَحْكَامِهِ

*(«Әәмәнту би-Лләһи кәмәә һүә биәсмәәиһи вә сыфәәтиһи вә кабилту җәмиигә әхкәәмиһи»)*

Мәгънәсе: «Барча мөбарәк исем һәм сыйфатлары белән Аллаһы Тәгаләгә иман китердем һәм Аллаһы Тәгаләнең барча хөкемнәрен кабул иттем».

*Иман муфәссал (тәфсилле (тулы) иман):*

آمَنْتُ بِاللهِ وَ مَلآئِكَتِهِ وَ كُتُبِهِ وَ رُسُلِهِ وَ الْيَوْمِ الْآخِرِ

وَ الْقَدَرِ خَيْرِهِ وَ شَرِّهِ مِنَ اللهِ تَعَالَى وَ الْبَعْثِ بَعْدَ الْمَوْتِ

*(«Әәмәнту би-Лләһи вә мәләәикәтиһи вә күтүбиһи вә русүлиһи вәл-яүмил-әәхыри вәл-кадәри хайриһи вә шәрриһи минә-Лләһи Тәгәәләә вәл-бәгси бәгдәл-мәүти»)*

Мәгънәсе: «Мин Аллаһы Тәгаләгә, Аның Фәрештәләренә, Китапларына, Пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә, Тәкъдирнең яхшысы – яманы да Аллаһы Тәгаләдән икәнлегенә һәм үлгәннән соң янә терелүгә иман китердем».

**? Күнегүләр:**

1. Шушы иман кәлимәләрен истә калдыр.
2. Иман кәлимәләренең мәгънәләрен үзеңнең якын туганнарыңа аңлатып кара.

## *2. Аллаһы Тәгаләнең исемнәре*

Аллаһы Тәгалә Үзенең күркәм исемнәре белән исемләнгән.


وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَى فَادْعُوهُ بِهَا وَذَرُوا الَّذِينَ يُلْحِدُونَ فِي أَسْمَائِهِ سَيُجْزَوْنَ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ

«Аллаһның күркәм исемнәре бар, чакырыгыз Аны алар белән һәм Аның исемнәрен тиешсез атаучылардан ерак булыгыз. Аларга, кылган эшләре өчен, җәза бирелер».

*(Әл-Әгъраф сүрәсе, 7/180)*

Рәсүлүллаһ ﷺ әйтте: “Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бар, кем аларны санап чыкса, Җәннәткә керә”.

Түбәндә шушы исемнәрнең кайберләренең мәгънәләрен карап үтәрбез.




Аллаһ – Бу исем Аллаһы Тәгаләнең башка исемнәреннән аерылып тора, чөнки Аллаһның бүтән исемнәре аерым-аерым бер мәгънәне аңлаткан булсалар, бу исем исә бөтен сыйфатларын берләштерә. Аны Аллаһтан башкага бирү мөмкин түгел һәм ул башка телләргә тәрҗемә ителми. Бу исем Аның Халикъ (Яратучы) булганын ачык итеп бәян итә.

Әр-Рахмәән – Аллаһы Тәгалә бу дөньяда барча мәхлукатына, шул исәптән кешеләргә (аермасы юк, ул кеше кяферме яисә мөэминме), Мәрхәмәтле (Миһербанлы, Шәфкатьле) булыр.

Әр-Рахиим – Кыямәт көнендә мөэминнәрне генә Рәхмәт күләгәсенә Алучы, Ярлыкаучы, мөэминнәргә генә Мәрхәмәт итүче.

Әл-Куддүүс – Аллаһы Тәгалә бөтен яратылган нәрсәләргә охшаудан ерак, барча гаеп һәм кимчелекләрдән пакъ булган Зат.

Әс-Сәләәмү – Аллаһы Тәгалә җитешсезлек һәм гаепләрдән, начар эшләрдән сәламәт булган, сәламәтлек бирүче Зат. Җәннәттәгеләргә исәнлек һәм иминлек биреп, аларны куркудан саклаучы дигән мәгънәсе дә бар. Аллаһ бервакытта да явызлыкны теләмәс.

Әл-Гәзииз – Аллаһы Тәгалә Көчле, Куәтле, җиңелүләргә дучар булмый торган кодрәтле, изге Зат. Ул бөтен яктан бердәнбер һәм Үзенә булган ихтыяҗы чиксез, Аннан башка һичбер нәрсә дә булмас.

Әл-Гаффәр – Аллаһы Тәгалә гөнаһ-хаталарны Ярлыкаучы Зат, тәүбә итүчеләрнең тәүбәләрен Кабул итүче.

Әл-Хабииру– Галәмдә булган һәм булачак һәр нәрсәдән Хәбәрдар Зат.

Әл-Гәлий – Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән өстен һәм бөек Зат.

Әл-Кәриим – Аллаһы Тәгалә бик Юмарт. Җәзалау, үч алу кулында булган хәлдә Ул юмартлыгы белән гафу итүче, колларының эшләгән гөнаһларына карамыйча, аларга нигъмәтләр бирүче.

Әл-Кавий – Аллаһы Тәгалә Көчле, Аның куәте җитмәс бер эш тә юк. Нинди генә эш булмасын, аны башкару Аның өчен авыр түгел. Теләгәнен эшләүдә, бар итүдә һәм юк итүдә бер көч тә сарыф итмәс – "бул" дип әйтүе җитәр һәм ул булыр.

## ? Сораулар һәм күнегүләр:

1. Аллаһы Тәгаләнең дәреслектә бирелгән 5-6 исемен булса да истә калдырырга тырыш.

2. Аллаhы Тәгаләнең тагы нинди исемнәрен беләсең? Берничәсен дәфтәреңә язып куй.

## *3. Аллаhы Тәгаләнең сыйфатлары*

Аллаhы Тәгаләне тану Аның сыйфатлары аша була. Аллаhы Тәгалә тулы сыйфатлар белән сыйфатланган hәм кимчелек сыйфатлардан пакъ. Аллаhы Тәгаләнең сыйфатлары мәңге hәм алар hичбер нәрсәгә охшамаган.

Аллаhы Тәгаләнең мөбарәк сыйфатлары ике төргә аерыла:

**I. Зәтия (Аллаhы Тәгаләнең Затына кагылышлы булган) сыйфатлары.**

1) Әл-Вуҗүд – Аллаhы Тәгаләнең Барлыгы. Аллаhы Тәгаләнең Барлыгы hичбер нәрсәгә хаҗәте юк hәм Аның Барлыгы башка нәрсә белән бәйле түгел. Аның булмавы мөмкин түгел. Шул сәбәпле, Аның турында «Ваҗибу-л-вуҗүд» («булуы тиешле»), дип әйтәләр. Аллаhы Тәгаләдән кала, барча нәрсә, Аның тарафыннан бар ителгән. Шул сәбәпле, Аллаhы Тәгаләдән кала, бөтен нәрсәләргә «мүмкинү-л-вуҗүд» («булуы мөмкин» – ягъни, аларның барлыкка килүе яисә юкка чыгуы мөмкин), дип әйтәләр.

وَالسَّمَاءَ رَفَعَهَا وَوَضَعَ الْمِيزَانَ

«Аллаh күкне күтәрде hәм hәрнәрсәгә гаделлек белән үлчәү куйды». *(Әр-Рахмән сүрәсе, 55/7).*

2) Әл-Кыйдәмү – Аллаhы Тәгаләнең, башлангыч ноктасы бул-

мыйча, Мәңге булуы һәм Аңа башланып китү (барлыкка килү) хас түгел, ягъни Аның башлангыч ноктасы юк, Аллаһы Тәгалә мәңге булучы, ләкин Ул барча нәрсәләргә башлангыч ноктасы салучы.

هُوَ الْأَوَّلُ وَالْآخِرُ وَالظَّاهِرُ وَالْبَاطِنُ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ

«Ул – Аллаһ һәр нәрсәдән элек бардыр вә һәр нәрсәдән соң да бардыр, Ул бакыйдыр, Аның бетү ихтималы юктыр, барча галәмне төзүе белән Аның барлыгы ачыктыр, вә Аның сыйфаты яшерендер, Аның сыйфатын һичкем белә алмас. Вә Ул һәр нәрсәне белүчедер». *(Әл-Хәдид сүрәсе, 57/3).*

3) Әл-Бәка'ү – Аллаһы Тәгаләнең, бетү ноктасы булмыйча, Мәңге булуы һәм Аңа бетү хас түгел, ягъни Аның бетү ноктасы юк, Аллаһы Тәгалә мәңге булучы, ләкин Ул барча нәрсәләргә бетү ноктасы салучы.

كُلُّ مَنْ عَلَيْهَا فَانٍ وَيَبْقَى وَجْهُ رَبِّكَ ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ

«Җир өстендә булган һәр җан иясе вә һәрнәрсә һәлак булучыдыр. Фәкать олугълык вә хөрмәт иясе булган Раббыңның заты калучыдыр». *(Әр-Рахмән сүрәсе, 55/26-27).*

4) Әл-Вәхдәнийяту – Аллаһы Тәгаләнең Бер булуы. Монда Аллаһы Тәгаләнең берлеге сан ягыннан түгел, ә Аның Затына, сыйфатларына һәм фигылләренә охшаш һичбер нәрсәнең булмавы һәм Аңа тиң булмавы, шәрикләре (иптәшләре) юклыгы мәгънәсендә.

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ

«Әйт (Әй Мөхәммәд ﷺ): «Ул – Аллаһ һич тиңдәше вә охшашы булмаган ялгыз бер генә Аллаһтыр». *(Әл-Ихләс сүрәсе, 112/1).*

5) Әл-Мүхаләфәтү лил-хәвәдис – Аллаһы Тәгаләнең бар ителгән мәхлукларының һичберсенә охшаш булмавы. Барча нәрсәләрне Аллаһы Тәгалә бар иткән һәм Аның алар белән һичбер уртаклыгы юк һәм Ул алар белән охшаш түгел. Безгә Аллаһы Тәгаләнең Затын күз алдыбызга китерү мөмкин түгел һәм Ул, мәхлуклар сыйфатланган сыйфатлар белән сыйфатланмаган, мәсәлән: тән, шәкел, вакыт, урын, әгъзалар һ.б.

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ

«Аллаһка охшаган һичнәрсә юктыр». *(Әш-Шүра сүрәсе, 42/11).*

Коръәндә зекер ителгән Аллаһы Тәгаләнең исем һәм сыйфатлары, мәхлүкъларның сыйфатларына охшаш түгел һәм аларны нәрсә беләндер чагыштырып яисә нәрсәгәдер охшатып исбат итү дөрес булмый. Чөнки Аның Затына, сыйфатларына һәм фигылләренә охшаш һичбер нәрсә юк.

6) Әл-Кыяму би-нәфсиһи – Аллаһы Тәгаләнең барлыгы үзеннән үзе. Үзенең бар булуында Аллаһы Тәгалә һичбер кемгә һәм һичбер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел, ләкин Аңа барча нәрсәләр мохтаҗ. Барча бар ителгән нәрсәләр исә, «әл-кыяму би-гайриһи» («барлыгы үзеннән башкадан»).

يَاأَيُّهَا النَّاسُ أَنْتُمُ الْفُقَرَاءُ إِلَى اللَّهِ وَاللَّهُ هُوَ الْغَنِيُّ الْحَمِيدُ

«Ий кешеләр сез ярлысыз, Аллаһка мохтаҗсыз, Аллаһ бай, һичкемгә мохтаҗ түгел, вә Ул мактаулы, Аның нигъмәт-

ләре өчен шөкер итеп Аны мактарга һәркем бурычлы».

*(Фәтыр сүрәсе, 35/15).*

## II. Сүбүтия (Аллаһы Тәгаләнең Тиеш булучы) сыйфатлары.

1) Әл-Хәятү – Аллаһы Тәгаләнең Тереклеге. Аллаһы Тәгалә Терек булучы һәм Ул бөтен нәрсәләргә дә тереклекне бүләк итүче. Аның тереклеге мәңге, ягъни башлангычы да һәм ахыры да юк.

وَتَوَكَّلْ عَلَى الْحَيِّ الَّذِي لَا يَمُوتُ وَسَبِّحْ بِحَمْدِهِ وَكَفَى بِهِ بِذُنُوبِ عِبَادِهِ خَبِيرًا

«Аларның малына кызыкма, бәлки һәрвакыт Тере, һич үлми торган, Раббыңа тәвәккәл ит, вә Аны мактап тәсбихләр әйт, бәндәләренең гөнаһларыннан хәбәрдар булырга Аллаһ үзе җитә».

*(Әл-Фуркан сүрәсе, 25/58).*

2) Әл-Гилмү – Аллаһы Тәгаләнең Белүе. Аллаһы Тәгалә барча нәрсәләр хакында да абсолют рәвештә Белүче, аермасы юк: элек булганмы яисә киләчәктә булачакмы, яшеренме ул әллә ачыкмы. Аллаһы Тәгалә хәтта күңелләрдәге яшерен ниятләрне һәм теләкләрне дә белеп тора. Аллаһы Тәгаләнең Белеме мәхлукларның белеменә һич охшаш түгел һәм Аның Белеме артмый да, кимеми дә. Аллаһы Тәгаләнең барча нәрсәләр хакында да Белүе гамәлләребезне башкаруга мәҗбүри рәвештә тәэсир итми.

وَعِنْدَهُ مَفَاتِحُ الْغَيْبِ لَا يَعْلَمُهَا إِلَّا هُوَ وَيَعْلَمُ مَا فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ وَمَا تَسْقُطُ مِنْ وَرَقَةٍ إِلَّا يَعْلَمُهَا وَلَا حَبَّةٍ فِي ظُلُمَاتِ الْأَرْضِ وَلَا رَطْبٍ وَلَا يَابِسٍ إِلَّا فِي كِتَابٍ مُبِينٍ

«Яшерен нәрсәләрнең ачкычлары Аллаһ кулында, аларны Аллаһтан башка белүче булмас, вә Ул корыда һәм суда

булган нәрсәләрне Белә, янә агачтан бер яфрак төшсә, аны Ул белә, дәхи туфрак астында кечкенә бер орлык булса һәм җирнең өстендә, я эчендә аз гына юешлек, я корылык булса, әлбәттә, Аллаһ аларны алдан ук белеп, Ләүхүл-мәхфуздә язып куйган». *(Әл-Әнгәм сүрәсе, 6/59).*

3) Әс-Сәмгү – Аллаһы Тәгаләнең Ишетүе. Аллаһы Тәгалә бөтен тавышларны да ишетә: пышылдап әйткәнен дә, каты, ачык, яшерен әйткәнен дә. Нәрсә генә әйтелсә дә, Аллаһы Тәгалә һәрвакыт Ишетә. Аллаһы Тәгаләнең бөтен тавышларны берьюлы ишетүендә һичбер нинди киртә юк һәм бу Аңа һичбер нинди авырлык китерми. Аллаһы Тәгаләнең Ишетүе өчен бер нинди дә әгъзалар булуы кирәк түгел.

رَبَّنَا تَقَبَّلْ مِنَّا إِنَّكَ أَنْتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

«Ий Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син Ишетүче һәм күңелләрне Белүчесең» *(Әл-Бәкара сүрәсе, 2/127).*

4) Әл-Бәсару – Аллаһы Тәгаләнең Күрүе. Аллаһы Тәгалә барча нәрсәләрне күрә, аермасы юк: яктымы ул, караңгымы, яшеренме, ачыкмы. Аның күрүеннән һичбер нәрсә дә яшеренеп калмый.

إِنَّ اللَّهَ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ

«Дөреслектә, Аллаһ һәрнәрсәне Ишетүче вә Күрүчедер».

*(Гафир сүрәсе, 40/19-20).*

5) Әл-Кудрату – Аллаһы Тәгалә Кодрәтле, ягъни һәр нәрсәгә көче җитүче. Аллаһы Тәгалә бетмәс Кодрәт һәм Көчкәия булучы

Зат. Аллаһы Тәгалә бөтен Галәм белән хәкимлек итә, аңа йогынты ясый, үзгәртә, саклый һәм ул Галәмдә Аның Көч-Кодрәтенең йогынтысы булмаган һичбер нәрсә юк. Галәмдәге барча нәрсәләр Аллаһы Тәгаләнең Көч-Кодрәте белән башкарыла.

يُقَلِّبُ اللَّهُ اللَّيْلَ وَالنَّهَارَ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَعِبْرَةً لِأُوْلِي الْأَبْصَارِ وَاللَّهُ خَلَقَ كُلَّ دَابَّةٍ مِنْ مَاءٍ فَمِنْهُمْ مَنْ يَمْشِي عَلَى بَطْنِهِ وَمِنْهُمْ مَنْ يَمْشِي عَلَى رِجْلَيْنِ وَمِنْهُمْ مَنْ يَمْشِي عَلَى أَرْبَعٍ يَخْلُقُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ إِنَّ اللَّهَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

«Аллаһ көндезне вә кичне алмаштырыр берсен берсе артыннан китерү белән, Аллаһның бу эшендә гакыллы вә күзле кешеләргә гыйбрәтләр бар. Аллаһ җир йөзендә булган барча җан иясен судан бар итте. Ул хайваннарның кайберләре корсагы белән йөрер, кайберләре ике аягы белән йөрерләр, кайберләре дүрт аягы белән йөрерләр. Аллаһ Үзе теләгән мәхлукларны бар итәр, бит Аллаһның һәрнәрсәгә көче җитә». *(Ән-Нүр сүрәсе, 24/44-45).*

6) Әл-Ирадәтү – Аллаһы Тәгаләнең Теләве. Аллаһы Тәгаләгә теләк белдерү хас һәм Ул теләгән нәрсәсен теләгәнчә булдыра. Ул сайлый: кайсы нәрсәгә булырга, ә нәрсәгә булмаска, аның урынын һәм вакытын билгели, кайчан һәм кайда аңа булырга икәнен билгели, һәм кайчан һәм кайда булмаска. Аллаһы Тәгалә теләгән нәрсә була, ә теләмәгән нәрсә булмый. *(Әли Гыймран сүрәсе, 3/26).*

لِلَّهِ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ يَهَبُ لِمَنْ يَشَاءُ إِنَاثًا وَيَهَبُ لِمَنْ يَشَاءُ الذُّكُورَ

«Җир вә күкләрнең мөлке Аллаһка хастыр, Үзе теләгән

нәрсәләрне бар итәр. Теләгән кешесенә кыз балалар бирер, теләгән кешесенә ир балалар бирер». *(Әш-Шура сүрәсе, 42/49).*

7) Әл-Кәләмү – Аллаһы Тәгаләнең Сөйләве. Шушы сыйфаты белән Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләргә Китаплар ирештерде, ә кайберләре белән сөйләште. Ләкин, ничек сөйләшүе, безгә мәгълүм түгел, ул авазлар һәм хәрефләрдән тормый. Аллаһы Тәгалә Сөйләү сыйфаты белән әмерен бирә, тыя һәм хәбәр итә.

قُلْ لَوْ كَانَ الْبَحْرُ مِدَادًا لِكَلِمَاتِ رَبِّي لَنَفِدَ الْبَحْرُ قَبْلَ أَنْ تَنفَدَ كَلِمَاتُ رَبِّي وَلَوْ جِئْنَا بِمِثْلِهِ مَدَدًا

«Әйт кешеләргә: «Әгәр диңгез суы яза торган кара булса, Раббымның гыйлем, хикмәт сүзләрен язмак өчен, әлбәттә, диңгез бетәр иде Раббымның гыйлем, хикмәт сүзләре бетүдән элек, әгәр ул диңгез хәтле янә диңгезләрне кара ясасак та».

*(Әл-Кәһф сүрәсе, 18/109).*

8) Әт-Тәквин – Аллаһы Тәгаләнең теләгән нәрсәсен «Бул» дигән әмере белән юктан Бар итүе. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә бердәнбер Бар итүче, Яратучы. Аллаһы Тәгалә Үзенең чиксез (мәңге бетмәс) Гыйлеме белән белеп, Үзенең Теләге белән теләп, чиксез Кодрәте белән барча нәрсәләрне Бар итә, аларга шәкел бирә, ризыкландыра, мәрхәмәтле була, нигъмәтләндерә, җанны бирә һәм ала, бәла-казалар җибәрә.

إِنَّمَا أَمْرُهُ إِذَا أَرَادَ شَيْئًا أَنْ يَقُولَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

«Аллаһ бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать «Бул!», дип әйтер һәм ул нәрсә бар булыр». *(Ясин сүрәсе, 36/82).*

## Изге күңелле балыкчы

Изгелеге белән билгеле булган бер кеше яши. Диңгез янында яшәве сәбәпле, ул балык тоту белән шөгыльләнә. Тоткан балыгын сатып, гаиләсенә акча таба.

Шулай бер көнне ул балыкка үзе белән уллары Мөхәммәд, Әхмәд һәм Мәхмүдне дә ала. Балыкчы уллары белән дога кылганда, шулай дип сорый: اللَّهُمَّ ارْزُقْنَا وَأَنْتَ خَيْرُ الرَّازِقِين *(Әллааһүммә-рзүкөнәә вә Әнтә хайрур-Раазикын)* "Әй Аллаһ, безне ризыкландыр, Син бит ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе".

Юлда Әхмәд әйтә:

- Аллаһ бирсә, бүген без күп балык тотарбыз. Шулай бит, әтием?

Әтиләре:

- Әй, улым, Аллаһы Тәгалә ялгыз бер Үзе Белүче, Аңа тапшырдык, Аллаһы Тәгалә безгә хәерле ризыкларны насыйп итсен, - ди.

Мөхәммәд:

- Балык тоткан вакытта өстебезгә яңгыр явудан куркам, - диде.

Әтиләре әйтте:

- Әй Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә безгә хәерлесен кылсын. Аллаһы Раббыбыз элек булган нәрсәләрне дә, хәзер булып торган нәрсәләрне дә, тиздән һәм киләчәктә була торган нәрсәләрне дә – барлык нәрсәләрне дә Белүче.

Алар көймәгә утырып диңгезгә чыгалар һәм зур җәтмә салып, балык тота башлыйлар. Балыкчының бу эшендә уллары аңа бик теләп ярдәм итәләр. Өйлә вакыты җиткәч, балыкчы һәм

аның уллары тәһарәт алып, өйлә намазын укырга әзерләнәләр.

Мәхмүд әтисенә сорау бирде:

- Әтием! Ни өчен без намаз укыр алдыннан тәһарәт алабыз?

Әтисе әйтте:

- Тәһарәт ул - чисталык (пакълык), ә чисталык - иманнан. Кешеләр чиста булучыларны яраталар. Пакълык ул тәнне һәм акылны яктыртып җибәрә. Аллаһы Тәгалә пакъ мөселманны ярата. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

أَنَّ اللهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ المُتَطَهِّرِينَ

“Шиксез, Аллаһ тәүбә итүчеләрне һәм пакъ булганнарны ярата”. *(Әл-Бәкара сүрәсе, 2/222).*

Өйлә намазын укып бетергәннән соң әтиләре улларына әйтте:

- Намазын укырга тырышучы мөселманны Аллаһы Тәгалә сөя, чөнки намаз кешене бер тәртипкә гадәтләндерә һәм ул тәнне чыныктыра, аңа көч бирә һәм мөселманны яхшы гамәлләр кылуга этәрә.

Төн җитте. Дөнья караңгыланды. Күктә ай чыкты һәм йолдызлар калыкты.

Әхмәд сорады:

- Әй, әтием! Ни өчен син озак итеп күккә карап торасың?

Әтисе әйтте:

- Әй, улым! Мин Аллаһы Тәгаләнең Бар һәм Бер булуына дәлил булып торучы айны һәм якты йолдызларны күзәтәм. Һәм шуларга карап Аллаһы Тәгаләнең нинди олугъ Зат һәм бөтен

нәрсәгә дә көче җитүче Кодрәт иясе икәнлегенә бөтен күңелем белән инанам.

Әхмәд:

- Әтием! Ни өчен Аллаһы Тәгалә йолдызларны яратты?

Әтисе:

- Аның сәбәпләре күп, улым. Мәсәлән: кешеләр йолдызлар ярдәмендә юл табалар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَهُوَ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ النُّجُومَ لِتَهْتَدُوا بِهَا فِي ظُلُمَاتِ الْبَرِّ وَالْبَحْرِ قَدْ فَصَّلْنَا الْآيَاتِ لِقَوْمٍ يَعْلَمُونَ

«Янә Ул – Аллаһ, сезнең өчен йолдызларны бар кылды, караңгы төннәрдә сахраларда вә диңгезләрдә йөргән вакытыгызда юл табар өчен маяк итеп. Белгән кешеләр өчен, тәхкыйк, аятьләребезне ачык бәян кылдык». *(Әл-Әнгам сүрәсе, 6/97).*

Әхмәд, Аллаһы Тәгаләнең бөтен нәрсәгә дә кодрәтле Зат икәнлеген сөйләүче, яттан белгән бер мөнәҗәтне укыды:

Юк нәрсәне бар кылыр, агар суны пар кылыр,
Су буларын кар кылыр, парны яңгыр итәр Ул.

Һәр кемсәне яратыр, җир йөзенә таратыр,
Кемне изгегә каратыр, кемне кяфер итәр Ул.

Үлек икән – тергезер, эченә җан кергезер,
Аягүрә йөргезер, терекне үлек итәр Ул.

Барчага көч-кодрәт бирер, кемгә каза иңдерер,
Кемгә атлас кидерер, кемне фәкыйрь итәр Ул.

Иртә белән балыкчы һәм уллары яр буенда туктыйлар. Әтисе улларына иртәнге намазны укыр өчен тәһарәт алырга куша.

Әхмәд:

- Әтием! Ни өчен без һәрбер намаз алдыннан тәһарәт алабыз? Без бит ясту намазына гына тәһарәт алган идек, - диде.

Әтисе әйтте:

- Улым! Бер алган тәһарәт белән берничә намаз укырга дөрес була. Ләкин тәһарәт бозылырга мөмкин, мәсәлән: йокласаң яисә берәр җирең җәрәхәтләнеп, аннан кан чыкса яки арт ягыңнан җил чыкса я бәдрәфкә кереп хаҗәтеңне үтәсәң (кечкенә яисә зур хаҗәт буенча тышка чыксаң).

Намаздан соң әтиләре һәм уллары шатланып өйләренә кайталар, чөнки Аллаһы Тәгалә аларны күп балык белән ризыкландыра.

Әтиләре әйтте:

- Әлхәмдүлилләһ (Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз), Аллаһы Тәгалә безне күп балык белән ризыкландырды һәм шул сәбәпле шушы балыктан кайбер якыннарыбызга, туганнарыбызга һәм күршеләребезгә дә өлеш чыгарырга тиеш булабыз. Әхмәд! Бу балыкны Дәрвишләр бистәсендә яшәүче әниеңнең бертуган апасы дәү апагызга илтеп бир. Ә син, Мөхәммәд, олы яшьтәге күршеләребез Ярулла абзый белән Хөсниҗамал

апага кертеп чык. Ә син, Мәхмүд, бу балыкны авыру дустыбыз Хәбибрахман абыйга илтеп бир.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтә: “Аллаһы Тәгалә каршында дусларның иң яхшысы - дусларына карата яхшы мөгамәләдә булганнары, Аллаһы Тәгалә каршында якыннарның иң яхшысы - якыннарына карата яхшы мөгамәләдә булганнары”.

Балыкчы тоткан балыкны сатып, балаларына яңа кием ала. Балалар бик шатланып, әтиләренә рәхмәтле булалар.

Балыкчыны балалары да, дуслары, күршеләре, якыннары да ярата, чөнки ул аларга карата яхшылык кыла, аларны хөрмәт итә һәм кешеләрнең берсенә дә начарлык эшләми.

**? Күнегүләр:**

1. Аллаһы Тәгаләнең Зәтия сыйфатларын беренче багана итеп, Сүбүтия сыйфатларын икенче багана итеп дәфтәреңә язып куй.
2. Аллаһы Тәгаләнең Зәтия һәм Сүбүтия сыйфатларын истә калдыр.

## *4. Аллаһы Тәгалә - Гафу итүче, Шәфкатьле*

Аллаһы Тәгалә Ишетүче һәм Күрүче, кешеләрнең бөтен гамәлләрен күрә һәм сүзләрен ишетә, Кыямәт көнендә аларны хисап итә дип әйтелгән иде. Аллаһы Тәгалә яхшы һәм изге гамәлләргә савап яза, начар гамәлләргә исә, гөнаһ яза.

Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә булган рәхмәте шул ки: гөнаһны эшләүче үзенең хата эшләгәнен белсә, эшләгәненә үкенсә, Аллаһы Тәгаләдән гафу итүен сораса, Аңа тәүбә итсә һәм киләчәктә аны эшләмәсә, шиксез, Аллаһы Тәгалә аны гафу итә һәм

аны газап итүдән коткара. Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә - Гафу итүче, Шәфкатьле. Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَمَنْ يَعْمَلْ سُوءًا أَوْ يَظْلِمْ نَفْسَهُ ثُمَّ يَسْتَغْفِرِ اللَّهَ يَجِدِ اللَّهَ غَفُورًا رَحِيمًا

“Берәү яман эшләр кылса яки үзенә золым итсә, соңыннан тәүбә итеп Аллаһтан ярлыкауны сораса, әлбәттә, Аллаһны ярлыкаучы һәм шәфкать итүче табар”. *(Әт-Ниса сүрәсе, 4/110).*



Әй, бала, Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларыңны кичерүен, сиңа Шәфкатьле булуын һәрвакыт сора, шиксез, Аллаһы Тәгалә - Шәфкать итүче.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَاكْتُبْ لَنَا فِي هَذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ إِنَّا هُدْنَا إِلَيْكَ قَالَ عَذَابِي أُصِيبُ بِهِ مَنْ أَشَاءُ

وَرَحْمَتِي وَسِعَتْ كُلَّ شَيْءٍ فَسَأَكْتُبُهَا لِلَّذِينَ يَتَّقُونَ وَيُؤْتُونَ الزَّكَاةَ وَالَّذِينَ هُمْ بِآيَاتِنَا يُؤْمِنُونَ

“Я Рабби! Безгә һидәятле күркәм тормышны нәсыйб ит! Һәм Ахирәттә күркәм тормышны бир! Тәхкыйк без Синең хөкемнәреңә итагать иттек, туры юлыңа күнелебезне салдык! Аллаһы Тәгалә әйтте: «Үзем теләгән кешегә газабымны ирештерермен һәм рәхмәтем (шәфкәтем) дә киңдер, һәрнәрсәне сыйдырды. Ул рәхмәтебезне кяфердән вә Аллаһ хөкемнәрен бозудан сакланучы тәкъва кешеләргә бик тиз бирербез, ул тәкъва кешеләр зәкятләрен бирерләр һәм Безнең аятьләребезгә ышанырлар”. *(Әл-Әгъраф сүрәсе, 7/156).*

**Мин Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларымны кичерүен, миңа Шәфкатьле булуын һәрвакыт сорыйм. Шиксез, Аллаһы Тәгалә – Шәфкать итүче.**

**Габдулла Тукай. Ана илә бала.**

- Җавап бирсәң икән, әнкәй, минем әйткән сөальләргә,
Гаҗәпләндем бу дөньяга вә анда барча хәлләргә:
Ничек булган, ничек үскән хисапсыз дәү бу урманнар?
Бу һәйбәт ямь-яшел кырлар каян килгән вә булганнар?
Вә һәртөрле үсемлекләр бизәнгән чәчәкләр берлә,
Вә төрле күбәләкләр дә күңел ачкан алар берлә,
Агар су, татлы, салкын, саф гаҗәиб чишмәләр, күлләр,
Куаклыкларда сайрар сандугачлар һәм дә былбыллар,
Суда йөзгән балыклар һәм үсеп торган бу зур таулар,
Чебен, черки вә ерткычлар, кәҗә, ат, барча җанварлар?
- Яраткан, әйләгән мәүҗүд (барлыкка китергән) боларның барчасын Тәңрең,
Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән, бәгъўрем.

## *Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем*


**Бу бүлектән мин белдем:**

- Аллаһы Тәгаләнең кайбер исемнәрен һәм аларның мәгънәләрен.
- Аллаһы Тәгаләнең “Зәтия” сыйфатларын.
- Аллаһы Тәгаләнең “Сүбүтия” сыйфатларын.

- Аллаһы Тәгалә Гафу итүче һәм Шәфкатьле, кешеләрнең тәүбәләрен кабул итүче.
- Хата-гөнаһ кылган һәрбер кешедә Аллаһы Тәгаләгә тәүбә-истигъфар итү мөмкинлеге бар (Аллаһы Тәгалә аны гафу итүе өчен) дигәнне.

**Бу бүлектән өйрәндем:**

- Иман кәлимәләрен:
  - Кәлимәтүн тайибәтүн (күркәм сүзен)
  - Кәлимәтү-ш-шәһадәти (шәһадәт кәлимәсе – гуаһлык бирә торган сүзен)
  - Кәлимәтү-т-тәүхид (тәүхид кәлимәсе – Аллаһы Тәгаләне Берләү сүзен)
  - Кәлимәтү раддил-күфри (көферлеккә төшүдән саклanып укыла торган сүзләрен).
  - Кәлимәтү-л-истигъфәр (гөнаһлар ярлыкауны сораучы сүзләрен).
  - Кәлимәтү-т-тәмҗид (Аллаһы Тәгаләне олуглау һәм мактау сүзләрен).
  - Иман мүҗмәл (кыскача иманны).
  - Иман муфәссал (тәфсилле (тулы) иманны).



# 2-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАЛАРЫ

### *1. Әйюб гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Әйюб гәләйһис-сәләм дәүзенең нәселе буенча Ибраһим гәләйһис-сәләмгә барып тоташа. Әйюб гәләйһис-сәләм бик бай булып, балалары да күп була. Аллаһы Тәгалә биргән бу нигъмәтләргә ул бик шөкерле (рәхмәтле) булып, Аның әмерләрен үтәп, тыйганнарыннан тыелып яши торган була.

Бервакыт Әйюб гәләйһис-сәләм бик каты авырып китә. Аның тәне бик каты ябыга. Шуның өстенә аңа бирелгән байлыкларның барысы да юкка чыга. Бөтен балалары һәлак була.



Кешеләр боларны күреп, берберсенә: "Әйюбнең Аллаһка гыйбадәт кылуы, хәзерге хәлендә файда бирерме икән соң?", - дип әйтештеләр.

Кешеләр барысы да аның яныннан ераклаштылар һәм араларын өзделәр. Бары тик хатыны аның белән булып, ярдәм күрсәтте һәм Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә булды.

Әйюб гәләйһис-сәләм бу авырлыклардан төшенкелеккә бирелмәде. Ул боларга сабыр итте, Аллаһы Тәгаләне зикер итүдән туктамады. Аллаһы Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать итте: "Әй Раббым, шайтан миңа авырлык һәм каты мәшәкать китер-

де, малымны һәм балаларымны һәлак итте. Син рәхмәт итүчеләрнең иң Рәхимлесе, мине дә рәхмәтеңнән ташлама!”

Аллаһы Тәгалә Әйюб галәйһис-сәләмнең догасын кабул итте. Аңа: “Әй Әйюб, аягың белән җиргә тип”, - дип әйтелде. Типкәннән соң салкын чишмә һәм кайнар чишмә чыкты. Ул кайнар чишмәдә юынды һәм салкын чишмәдән эчте. Шунда ук, сәламәтләнеп, әүвәлге хәленә килде. Шулай ук Аллаһы Тәгалә Әйюб галәйһис-сәләмгә балаларын да ике өлеш арттырып бирде.

Аллаһы Тәгалә аның хәлен җиңеләйткәч, ул Раббысына шөкераналар кылды һәм кешеләрне бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга чакырды. Аларны Җәннәт белән өметләндерде һәм Җәһәннәм белән куркытты. Ахыргы көннәренә кадәр кешеләрне иманга чакырды.

**Бу кыйссадан алган файдалар**

- Әйюб галәйһис-сәләм Аллаһы Тәгалә аңа биргән нигъмәтләре өчен бик шөкерле (рәхмәтле) булып, Аның әмерләрен үтәп, тыйганнарыннан тыелып яши торган булды.
- Әйюб галәйһис-сәләм бик каты авырып китсә дә, байлыгы һәм балалары һәлак булса да, Аллаһы Тәгаләне истә тотудан туктамады, биргән сынауларга сабырлык итте.
- Иманга чакыручы кеше барча авырлыкларга сабыр итәргә тиеш.

## *2. Муса гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Муса гәләйһис-сәләм яшәгән вакытта Мисыр җирендә Фиргавен хәкимлек итә иде. Ул бик тә залим һәм тәкәббер булып, кешеләрне үтереп, хатыннарны көч белән ала торган була. Хәтта, ул үзен “иләһ” дип белгертеп, аңа табынырга куша.

Көннәрдән бер көнне Фиргавен шушы патшалыгы, байлыгы бер егет туу сәбәпле юкка чыгачагын белә. Шуннан куркып, ул һәрбер туган ир-ат баланы үтереп, кызларны гына калдырырга куша.



Бу вакытларда Муса гәләйһис-сәләмнең әнисе анын белән йөкле була. Муса гәләйһис-сәләм дөньяга килгәч әнисе анын өчен бик курка. Ләкин Аллаһы Тәгалә, әлбәттә, Үзенең киләчәк пәйгамбәрен ярдәмсез калдырмый. Аллаһы Тәгалә Муса гәләйһис-сәләмнең әнисенә аны сандыкка салып диңгезгә төшерергә кирәклеген белдертә. Муса гәләйһис-сәләмнең әнисе шуны эшли дә. Сандык диңгез буйлап агып китә һәм, ни гаҗәп, Фиргавен сарае урнашкан яр буена килеп туктый.

Бу вакытта, яр буена суга дип төшкән Фиргавеннең хезмәтчеләре сандыкны күреп алалар һәм аны Фиргавен хатынына илтеп бирәләр. Ачып карасалар, сандык эчендә бик сөйкемле һәм матур бала ята. Шушы арада Фиргавен үзе килеп керә һәм баланы күреп ала. Хатыны аннан ул баланы үзләрендә калдырырга ялварып сорый. Ул риза була.

Бераздан бала (Муса гәләйһис-сәләм) ачыгып елый башлый һәм аны ашатырга дип имезүче хатын эзли башлыйлар. Кем генә килмәсен – бала аны кабул итми. Муса гәләйһис-сәләм хакында хәбәрне белеп торучы әнисенең апасы, моннан файдаланып, Фиргавен хатынына әйтә: "Мин сезгә бер хатынны табып биримме, ул хатын сезнең өчен баланы имезеп тәрбияләр". Фиргавеннең хатыны моңа бик риза була. Муса гәләйһис-сәләмнең әнисен чакырып китерәләр. Муса гәләйһис-сәләм әнисенең сөтен имә.

Әнисе баласын күреп бик шатлана.

Фиргавеннең хатыны Муса гәләйһис-сәләмне ярата. Шуның өчен Мусаның имезүче әнисе белән бергә торуын сорый. Шулай итеп Муса Фиргавен йортында тәрбияләнеп үсә.

Көннәрдән бер көнне, Муса гәләйһис-сәләм патша сараеннан чыгып, шәһәр урамнарында йөргәндә, ике сугышкан кешене күреп ала. Аларның берсе Муса гәләйһис-сәләм булган Бәни Исраил кавеменнән булса, икенчесе Фиргавен кавеменнән иде. Бәни Исраил кавеменнән булганы аннан ярдәм сорый. Ул үз кавеменнән булганын яклап икенчесенә кулы белән суга. Ул кеше җиргә егылып үлеп китә. Муса гәләйһис-сәләм моңа

исе китә һәм бик үкенә. Ул аңа җиңелчә генә сукты, аны үтерергә теләмәгән иде.

Моннан соң Муса гәләйһис-сәләм шәһәрдә куркып йөри башлый. Икенче көнне ул тагын ике кешенең сугышканын күрә. Аларның берсе алдагы көндә булган Бәни Исраил кавеменнән булса, икенчесе Фиргавен кавеменнән иде. Кичә Мусадан ярдәм сораган кеше янә аннан ярдәм сорый. Ул ярдәм итәм дип баргында икенчесе әйтә: "Әй Муса! Кичә үтергән кешене үтергәнең кебек, син мине дә үтермәкче буласыңмы?" Шунда кешеләр узган көндә теге кешене үтерүче Муса гәләйһис-сәләм булганын белеп алалар. Аны кулга алырга дип Фиргавен гаскәрен җибәрә. Муса гәләйһис-сәләмгә бу хәбәрне ирештерәләр. Ул Мисырдан тиз арада чыгып китәргә мәҗбүр була.

Муса гәләйһис-сәләм Шөгәйб гәләйһис-сәләм исемле пәйгамбәр яшәгән Мәдйән җирләренә барып җитә. Шәһәргә кергәч, ул кешеләрнең коедан су алып хайваннарын эчергәннәрен күрә. Алар янында үзләренең хайваннарын су эчертә алмый читтә басып торган ике кызны күреп ала. Алар янына барып, хайваннарына су эчертергә ярдәм итә. Аннары агач күләгәсенә барып утыра. Ул шулай утырганда кызларның берсе бик оялып кына Муса гәләйһис-сәләм янына килеп: "Безнең сарыкларыбызны эчерткәнең өчен, әтиебез сиңа хакын бирмәкче", - диде.

Муса гәләйһис-сәләм кызларның әтисе Шөгәйб гәләйһис-сәләм янына килгәч, башыннан кичкән вакыйгаларны сөйли. Шөгәйб әйтте: "Муса, курыкма, син залим патшадан котылдың. Син монда тынычлык табарсың. Минем янымда сигез ел

сарыкларымны көткәнең өчен, үземнең бер кызыма өйләндерермен. Әгәр ун ел тутырасың икән, анысы синең изгелек эшләреңнән булыр".

Шөгәйб галәйһис-сәләм янында вәгъдә биргән сигез ел урынына, ун ел вакытын тутыргач, Муса галәйһис-сәләм хатыны һәм балалары белән Мәдйәннән чыгып, Мисыр җиренә юнәлә.

Юлда ул Синай җирендәге Тур тавы янында ут күреп ала һәм гаиләсенә: "Мин килгәнче монда торып торыгыз", - дип ут яктысына таба юнәлә. Аңа якыная төшкәч, тавыш ишетә: "Әй Муса! Мин синең Раббың, башмакларыңны сал. Син Тува исемле изге урындадыр. Мин сине пәйгамбәрлеккә сайладым. Дөреслектә, Мин – Аллаһ, Миннән башка иләһ юк. Миңа гыйбадәт ит һәм Мине зекер итәр өчен намаз укы! Дөреслектә, Кыямәт көне киләчәк. Аның кайчан булуы яшерелгән, вакыты җиткәч һәрбер кеше үзенең гамәле өчен тиешлесен алуы өчен. Берәүнең Кыямәт көненә ышанмавы һәм нәфесенә ияреп начар эшләрне эшләве, сине Кыямәт көненең булачагына ышанудан тыймасын. Ул вакытта син һәлак булырсың".

Соңыннан Аллаһы Тәгалә әйтә: "Әй Муса, кулыңдагы таягыңны җиргә ташла". Муса галәйһис-сәләм таягын җиргә ыргыта. Ул таяк тиз шуышып йөрүче еланга әверелә.

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Курыкма, бу еланны тотып ал, Без аны әүвәлге халәтенә кайтарырбыз". Муса галәйһис-сәләм аны тотып алгач ул янә таякка әверелә.

Соңыннан Аллаһы Тәгалә әйтә: "Инде уң кулың белән сул

култык астына сук: уң кулыңны култыгыңнан чыгар, күзне чагылдыра торган ак һәм зарарсыз булыр – бу синең пәйгамбәр икәнеңә икенче галәмәт булыр”.

Шушы ярдәмнәрнең Аллаһы Тәгаләдән икәнлеген белгәч, Муса гәләйһис-сәләмнең йөрәге тынычланды. Ул Раббысыннан, аның белән бергә Аллаһы Тәгаләнең диненә чакырыр өчен, туганнарыннан булган Һарунны җибәрүен сорады.

Шуннан соң Муса гәләйһис-сәләм белән Һарун гәләйһис-сәләм, җир йөзендә бозыклык таратучы Фиргавенне бер Аллаһка гыйбадәт кылырга һәм начарлыктан читләшүгә чакырырга дип, Мисыр җиренә юнәләләр.

Алар Фиргавен янына кергәч, ул Муса гәләйһис-сәләмне танып ала. Алар Фиргавенне йомшаклык белән бер Аллаһы Тәгаләгә иман китерүгә чакыра башлыйлар.

Фиргавен әйтә: “Муса! Сезнең Раббыгыз кем?”

Муса гәләйһис-сәләм: “Безнең Раббыбыз – Үзе бар иткән мәхлукларына һәрнәрсәне бирде, соңыннан Үзе биргән нәрсәләрдән файдаланырга кешеләргә юл күрсәтте”, - ди. Фиргавен: “Элек үлгән кешеләрнең хәлләре ничек?”

Муса гәләйһис-сәләм әйтә: “Аларның хәлләрен Аллаһы Тәгалә Үзе генә белүче”.

Фиргавен әйтә: “Муса! Сихерең белән безне Мисыр җиреннән чыгарырга килдеңме? Без дә синең сихерең кебек сихер белән килербез. Сихерләребезне күрсәтү өчен бер урынга килергә сүз бир. Биргән сүзебезгә без дә, сез дә каршылык күрсәтмик”.

Муса гәләйһис-сәләм: “Җыелачак көн сезнең бәйрәмегез булсын, Мисыр халкы ул урынга төшкә хәтле җыелсын”, - ди.

Фиргавен кавеме белән хәйлә кыла. Сихерчеләрен җыеп, сүз бирелгән урынга киләләр.

Муса гәләйһис-сәләм әйтә: “Аллаһы Тәгаләгә ялганны яла якмагыз, Аллаһы Тәгалә сезне Үзенең газабы белән һәлак итәр. Аллаһы Тәгаләгә ялганны яла ягучы, әлбәттә, һәлак булды”.

Фиргавеннең сихерчеләре Муса гәләйһис-сәләмнең сүзләрен ишеткәч, үзара талаштылар һәм сүзләрен яшерделәр. Сихерчеләр әйтте: “Бу ике ир сихерчеләр. Алар сихерләре белән сезне үз җирегездән чыгарырга һәм хак динегезне артка калдырып, үз диннәренең өстен булуын телиләр”.

Фиргавен: “Муса белән Һарунга каршы хәйлә һәм сихерләрегезне җыегыз, соңыннан сафка тезелеп килегез. Бүген җиңгән кеше өстен чыгар”, - ди.

Фиргавеннең сихерчеләре җепләрен һәм таякларын җиргә салгач, алар елан булып йөри башлыйлар. Бу еланнар Мусага тере еланнар булып күренәләр. Муса шул вакытта күңелендә курку тойды.

Шул вакытта Аллаһы Тәгалә аңа әйтте: “Әй Муса, курыкма, син алардан өстенрәк. Таягыңны җиргә ташла!”

Муса гәләйһис-сәләм таягын җиргә ташлый. Таяк аларның бөтен нәрсәләрен ашап бетерә. Сихерчеләр бу нәрсәләргә исләре китеп, иман китерәләр, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итеп, сәҗдәгә егылалар һәм: “Һарун белән Мусаның Раббысына иман китердек”, - дип әйтәләр.

Фиргавен сихерчеләргә әйтә: “Сез минем рөхсәтемнән башка Һарун һәм Мусаның Раббысына иман китердегезме? Мин сезнең уң кулыгызны һәм сул аягыгызны кисәрмен, хөрмә ботакларына асып куярмын. Шул вакытта белерсез минме әллә Мусаның Раббысымы катырак газап итүче һәм кайсыбызның газабы даими булыр икәнен?!”

Иман китергән сихерчеләр әйтә: “Әй Фиргавен! Мусаның пәйгамбәр икәненә күрсәткән көчле дәлил булган могҗизаны һәм безне яратучы Аллаһы Тәгаләне сиңа алыштырмыйбыз. Син безнең белән нәрсә теләсәң шуны эшлә. Син тәкәбберләнеп бу дөньяда гына хөкем итә алырсың, әмма Ахирәттә хөкем итә алмассың”.

Фиргавеннең боларга бик нык ачуы килә. Барчасы да аны “иләһ” дип уйлыйлар һәм ул үзенең гади кеше икәнлеген белгертергә теләми иде. Муса гәләйһис-сәләм кешеләргә, аны үзенең сараенда тәрбияләп үстергәнен, әйтмәсен дип аңа яхшылык күрсәткәнен искә төшерә башлый. Ләкин Муса гәләйһис-сәләм Раббысы тарафыннан үзенә йөкләнгән дәгъвәтне дәвам итәчәген белдерә.

Фиргавен әйтә: “Әгәр син миннән башканы “иләһ” тотсаң, мин сине төрмәгә ябачакмын”.

Муса гәләйһис-сәләм: “Әгәр пәйгамбәрлегемә ачык дәлилләр китерсәм дә ул эшне эшләрсеңме?” – ди.

Фиргавен: “Әгәр дөрес пәйгамбәр булсаң, дәлилеңне китер”, - дип боера.

Муса гәләйһис-сәләм таягын җиргә ташлый. Ул еланга

әверелә һәм сихерчеләрнең кеше күзенә елан булып тоелган таякларын ашап бетерә. Кешеләр бу хәлне күреп куркып калалар. Фиргавен курыкканын сиздермәс өчен, Мусага тизрәк тагын берәр могҗиза күрсәтергә куша.

Муса гәләйһис-сәләм икенче могҗиза итеп кулын кесәсенә тыга. Аннан чыгаруга, аның кулы күзне чагылдырырлык ак булып нур сибә башлый.

Кешеләр Муса гәләйһис-сәләмнең пәйгамбәр икәнлегенә ыщаналар, әмма Фиргавен аларга: "Муса сихерче", - дип әйтә.

Фиргавен үзенең гаскәренә Муса гәләйһис-сәләмне һәм аңа ияргән кешеләрнең барысын да газапларга дигән әмер бирә. Фиргавеннең мәкерлеге турында Аллаһы Тәгалә Муса гәләйһис-сәләмгә белгертә һәм иман китергән барча кешеләрне ияртеп, Фалыстын җиренә юнәлергә куша. Муса гәләйһис-сәләм шулай эшли дә. Аларның артларыннан Фиргавен гаскәре белән куа чыга. Алар шулай Фиргавеннән качып барганда каршыларында диңгез очрый.

Шул вакыт, Муса гәләйһис-сәләм ярдәм сорап Раббысына ялвара. Аллаһы Тәгалә Муса гәләйһис-сәләмгә таягы белән диңгезгә сугарга куша. Ул Раббысының әмеренә буйсынып, таягы белән диңгезгә суга. Диңгез Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән икегә аерылып, коры юл ачыла. Муса гәләйһис-сәләм үзенә ияргәннәр белән шул юлдан диңгезнең икенче ягына чыга. Артларыннан куып килүче Фиргавен дә гаскәре белән шул юлга кереп китә. Аллаһы Тәгалә аларның өсләренә диңгезне каплый һәм алар барчасы да су астында калып батып үләләр.

**Бу кыйссадан алган файдалар**

- Мисыр җирендә залим һәм тәкәббер Фиргавен хәкимлек итә иде. Ул үзен “иләһ” дип белгертеп, үзенә табынырга куша иде.
- Аллаһы Тәгаләнең Муса гәләйһис-сәләмне әнисенә кайтаруы.
- Муса гәләйһис-сәләмнең Фиргавен сараенда тәрбияләнүе.
- Муса гәләйһис-сәләмнең залим булучы Фиргавеннән качып Мисыр җиреннән чыгып китүе.
- Муса гәләйһис-сәләмнең Шөгаебның кызларына изгелек кылуы.
- Аллаһы Тәгаләнең Муса гәләйһис-сәләм белән сөйләшүе һәм аңа пәйгамбәрлек йөкләнелүе.
- Аллаһы Тәгаләнең Муса гәләйһис-сәләмгә могҗизалар бирүе.
- Муса гәләйһис-сәләмгә күрсәткән могҗизалар сәбәпле сихерчеләрнең иман китерүләре.
- Аллаһы Тәгалә диңгезне икегә аерып, Муса гәләйһис-сәләмне һәм аңа иман китергәннәрне коткаруы, ә Фиргавенне һәм аның гаскәрен батырып һәлак итүе.

## *3. Дауд гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Дауд гәләйһис-сәләм, әле пәйгамбәр булганчы, Бәни Исраил кавеменең патшасы булып, гаделлек белән хөкем итә торган булган. Соңыннан Аллаһы Тәгалә аны пәйгамбәр итеп сайлый һәм аңа Забур исемле китап иңдерә.

Аллаһы Тәгалә Дауд гәләйһис-сәләмгә биргән нигъмәтләреннән шул була – ул Раббысын бөекләп, пакъләп тәсбих әйтсә, аңа кушылып таулар һәм кошлар да тәсбих әйтәләр иде.

Дауд гәләйһис-сәләм Раббысына шөкер итүче һәм күп гыйбадәт кылучы, көн аша ураза тотучы иде. Аллаһы Тәгалә аңа, шулай ук, тимерчелек һөнәрен белгерткән һәм ул тимердән сугышта саклану кораллары һәм җиһазлары ясый торган булган.

Дауд гәләйһис-сәләм, Аллаһы Тәгалә аңа күп нигъмәтләр һәм көч-куәт бирүенә карамастан, кешеләргә карата золымлык итмәде, тәкәбберләнмәде. Киресенчә ул, тагын да күбрәк шөкер-гыйбадәт кылып, араларны гаделлек белән хөкем итте. Әгәр хөкем итүдә ялгышканлыгын сизсә, шул ук вакытта Раббысыннан гафу итүен сорый торган булды. Аның шундый икәненә бер мисал китерик.

Көннәрдән бер көнне, ул үзенең гыйбадәт йортына гыйбадәт кылырга дип кергәч, аның янына көтмәгәндә, ике кеше килеп керә. Дауд гәләйһис-сәләм аларны көтмәгән булганлыктан сискәнеп, куркып кала. Алар аңа: “Курыкма, без синең яныңа гадел хөкем итүең өчен килдек”, - диләр. Аларның берсе: “Әй Дауд, бу минем туганым, аның 99 сарыгы бар һәм ул минем бердәнбер сарыгымны золым кылып алды да, үзенекен 100гә тутырды”, - ди. Дауд гәләйһис-сәләм икенчесен тыңлап та тормыйча беренчесенә: “Ул синең сарыгыңны алып, сиңа золым кылган”, - дип араларын хөкем итә.

Алар киткәч, Дауд гәләйһис-сәләм Раббысы аны сынага-

нын һәм кисәткәнен аңлады һәм тиз арада Раббысына ялварып гафу сорады, тәүбә итте.

### Бу кыйссадан алган файдалар

- Дауд гәләйһис-сәләм Раббысын бөекләп, пакъләп тәсбих әйтсә, аңа кушылып таулар һәм кошлар да тәсбих әйтәләр иде.
- Дауд гәләйһис-сәләм Раббысына шөкер итүче һәм күп гыйбадәт кылучы, көн аша ураза тотучы иде.
- Аллаһы Тәгалә аңа күп нигъмәтләр һәм көч-куәт бирүенә карамастан, кешеләргә карата золымлык итмәде, тәкәбберләнмәде.
- Дауд гәләйһис-сәләм хөкем итүдә ялгышканлыгын сизсә, шул ук вакытта Раббысыннан гафу итүен сорый торган иде.



# 3-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘД ﷺ НЕҢ ТОРМЫШЫННАН

### *1. Бәдер сугышы*

Көрәешләрнең кәрваны Сүриядән Мәккәгә киләчәге турында мөселманнар белеп алалар. Мөселманнар уңайлы форсаттан файдаланып калырга уйлыйлар. Кәрванга һөҗүм итү өчен кылыч белән генә коралланган кечерәк бер отряд юлга чыга. Әбү Суфьян җитәкчелегендәге кәрван үзенә һөҗүм әзерләнгәнен сизенә. Ул, көнбатышка борылып, диңгез буйлап китә һәм кәрванны коткарып кала.



Мөхәммәд ﷺ һәм аның сәхабәләре, зур байлык төягән кәрванның юлына аркылы төшкән дигән хәбәрне көрәешләргә җиткерәләр. Аларга үз мөлкәтләрен мөселманнардан сакларга барудан башка юл калмый.

Кәрванның котылуын белгәч, кайбер көрәешләр: “Мәккәгә кайтырга кирәк”, - дип әйтәләр. Әбү Җәһилнең моңа нык ачуы чыга һәм кайтырга теләми.

Пәйгамбәр ﷺ сәхабәләрне җыеп, булачак сугыш хакында киңәшә. Мөһаҗирләр дә, әнсарлар да Пәйгамбәр ﷺ не, “сугышка барырга әзер” дигән җаваплары белән шатландыралар.


Мөселманнар Бәдергә килеп җитәләр. Су өчен бассейн казыйлар, башка коеларны ком белән күмәләр. Аннары мөселманнар тезеләләр, алар - 313 кеше 1000 мәҗүсигә каршы торырга тиеш булалар.

Аерым кешеләрнең сугышыннан соң, мәҗүсиләрнең шактый танылган кешеләре үтерелә, ә мөселманнарның ышанычы арта бара.

Сугыш һәр тарафтан өчәр кешенең очрашуы белән башланып китә. Аннары һәр ике як та һәҗүмгә күчә, бер-берсенә якыная. Мөселманнар батырларча сугышалар. Аллаһ аларга үз фәрештәләре белән булыша һәм кыйммәтле, теләп алган җиңү бүләк итә. Мәккә кяферләреннән барысы 70 кеше үлә, 70 кеше әсир алына. Мөселманнардан 14 кеше шәһит була (дин өчен сугышып үлә).

## 2. Өхед тавы янындагы сугыш

Бәдер сугышында зур югалтуларга дучар булгач, көрәешләр үч алу планы кора башлыйлар: көч туплыйлар һәм 3000 кешелек гаскәр төзиләр. Алар шулкадәр узыналар ки, Мәдинә юлында булган Әбва авылына барганда, Пәйгамбәребез ﷺ нең әнисе Әминәнең каберен ачып, сөякләрен казып чыгаралар.



Пәйгамбәр ﷺ гә көрәешләрнең ниятләре һәм нинди көч җыю хәбәре ирешә. Ул дошманны ничегрәк каршы алу турында киңәшә башлый. Рәсүл ﷺ һәм башкалар мөселманнарның шәһәрдә калуын һәм ныгуын кулайрак күрә. Яшьләр исә дошман белән шәһәрдән чыгып сугышуны кулайрак күрә.


Пәйгамбәр ﷺ теләмичә генә шәһәрдән чыгарга ризалык бирә. Бу сугыш ифрат авыр була. Кайбер мөселманнар Пәйгамбәр ﷺ нең боерыкларын үтәми, шул сәбәпле мөселманнар авыр хәлдә калалар.

Өхед тавы янына килеп, Пәйгамбәр ﷺ илле укчыны таулы җирдәге текә ярлы тар үзәнгә (тарлавыкка) куя. Аларга беркая да китмәскә куша һәм атлы гаскәргә ук яудырырга тиеш икәнлекләрен аңлата.

Ике як та сугышка әзерләнә. Көрәешләрдән икәүдән-икәү сугышырга чакырып, Тальха чыга. Аның белән Гали ибн Әбү Талиб сугыша һәм җиңә. Гомуми сугыш башлана.

Мөселманнар үзләреннән дүрт тапкыр артык булган дошманга нык каршы торалар һәм аны качарга мәҗбүр итәләр. Бу

вакытта таудагы укчылар сугыш бетте дип уйлыйлар һәм дошман ташлап калдырылган әйберләрне уртаклашырга төшәргә уйлыйлар. Башлыклары каршы килеп караса да, күпчелек аның сүзләрен тыңламый.



Дошман моннан файдаланып, арттан мөселманнар өстенә ташлана. Ул тау башында калган укчыларны кырып бетерә, аска төшә һәм мөселманнар белән сугыша. Мөселманнарның сафы таркала. Алар үзләренең көчкуәтләрен югалталар һәм коточкыч җиңелүгә дучар булалар. Бу сугышта хәтта Пәйгамбәр ﷺ нең яңагы яралана, битеннән кан ага башлый. Мөселманнардан 70 кеше шәһит булып китә. Алар арасында Пәйгамбәр ﷺ нең абыйсы Хәмзә ибн Габдел-Моталлиб тә була.

Өхед сугышы мөселманнарга зур сабак була.

## *3. Худәйбия вакыйгасы*

Бер вакытны Пәйгамбәребез ﷺ төшендә, сәхабәләре белән бергә, Мәккә шәһәренә кереп, анда хаҗ гамәлләрен үтәгәнлеген күрә. Пәйгамбәребез ﷺ нең Хәрам мәчетенә баруга күңеле кузгалып, гомрә хаҗына хәзерләнергә куша. Бу хакта Мәдинә шәһәре тирәсендәге гарәп кабиләләренә дә хәбәр итела, ләкин алар Пәйгамбәребез ﷺ гә кушылырга ашыкмыйлар.

Пәйгамбәребез ﷺ бер мең дүрт йөз сәхабәсе белән Мәккәгә бару юлына чыга. Алар, сугышырга дип түгел, ә гомрә хаҗын кылырга дип кенә баралар. Үзләре белән корбанлык өчен җитмеш дөя алып китәләр.

Әмма көрәешләр аларның Мәккәгә керүләрен теләмиләр. Мөселманнарны туктату өчен, аларга каршы кораллы кешеләр җибәрәләр. Пәйгамбәребез ﷺ, алар белән очрашырга һәм сугышырга теләмичә, икенче юлга борыла.

Мөселманнар Худәйбия дигән җиргә килеп урнашалар. Монда килүләренең максатларын сорар өчен көрәешләр алар янына төрле кешеләр җибәрәләр. Гыйбадәт кылырга, гомрә хаҗын үтәргә дип ният иткәннәрен белгәч, кайтып көрәешләргә сөйлиләр. Ләкин көрәешләр, быел аларның кире кайтып китүләрен, ә гомрә хаҗын кылыр өчен икенче елны килүләрен телəделәр.

Пәйгамбәребез ﷺ көрәешләрне күндерү өчен үзенең кияве Госман р.а.г. не һәм тагын ун кешене җибәрә. Ләкин аларның үгетләве файдасыз була. Көрәешлар риза булмыйлар. Соңыннан Госман р.а.г. һәм аның белән булучыларны тоткарлап, шәһәрдән чыгармыйлар. Мөселманнар арасында аны үтергәннәр дигән хәбәр дә тарала. Бу хәбәрдән соң мөселманнар сугышка әзерләнәләр.

Мөселманнарның сугышка әзерләнү хәбәре көрәешләрне куркуга сала. Соңыннан мәккәлеләр, сиздермичә генә һөҗүм итәр өчен, 50 кешене җибәрәләр. Аларның бөтенесе (качып котылган башлыкларыннан кала) әсирлеккә эләгәләр. Мәккәлеләр


моны белгәч, сугышыр өчен тагын бер төркем җибәрәләр. Аларның да уникесе тагын әсирлеккә эләгә. Бу аларны тагын куркуга сала. Алар, мөселманнар белән килешү төзү өчен, Сүһәйл ибн Гамрне җибәрәләр. Алар ике яктан да алган әсирләрне кайтаруга килешәләр. Шуннан соң Госман һәм аның белән булучылар җибәрелә. Соңыннан Сүһәйл шартлар тәкъдим итә. Алар арасында кабул итәргә мөмкин булганнары да, мөмкин булмаганнары да була. Шуңа карамастан, Пәйгамбәребез ﷺ бу шартларны кабул итә. Бу килешү буенча, мөселманнар зарар күрәчәк кебек иде. Ләкин Аллаһының рәхмәте белән нәтиҗәсе алай булмады. Башта разый булган кяферләр соңыннан бу килешүнең күп урыннарын үзгәртүне сорап ялваралар. Пәйгамбәребез ﷺ тагын бер елдан соң Мәккәгә кабат кайту өчен, үзенең сәхабәләре белән бергә Мәдинәгә кире кайта.

## *4. Патшаларга һәм хакимнәргә илчеләр җибәрү*

Худәйбия килешүе төзелгәннән соң мөселманнарның хәле яхшыра. Пәйгамбәребез ﷺ Ислам диненә өндәп, патшаларга һәм хакимнәргә хатлар яза. Хатларына ул көмештән эшләнгән "Аллаһның Расүле Мөхәммәд" дип уелган мөһер баса.

Ул Византия императорына, Басра әмиренә, Мисыр хакименә, Фарсы шаһы Хөсрәүгә, Баһрейн патшасына, Оман патшаларына, Йәмән патшасына хатлар җибәрә.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хатларының эчтәлекләре бер-берсе белән охшаш булалар. Алар Бер Бөек Кодрәтле Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт итүгә өндиләр.



Кайбер патшалар һәм хакимнәр, чапкыннар аша, ихтирам белән сугарылган җаваплар җибәрәләр. Мисыр хакиме әдәпле җавап белән бергә бүләкләр дә җибәрә.

Кайберләре, тәкәбберләнеп, хатларны ертып ташлыйлар. Мәсәлән, моны Фарсы патшасы шулай эшли. Әле өстәвенә Йәмәндәге үз вәкиленә Пәйгамбәребез ﷺ не үзенә көч белән алып килүне таләп итә.

Кайберләре Ислам динен кабул итәләр. Мәсәлән, Баһрейн патшасы Исламны кабул итә, шулай ук, Оманның ике патшасы да аның үрнәгенә ияреләр. Пәйгамбәребез ﷺ аларны үз халыклары белән хакимлек итәргә калдыра.

Пәйгамбәребез ﷺ нең Басра әмиренә җибәрелгән чапкыны гына тиешле урынга барып җитә алмый. Аны Сүриягә якын бер җирдә үтерәләр. Соңыннан Пәйгамбәребез ﷺ бирегә гаскәрен җибәреп, илчеләрне үтерергә ярамаганлыгына сабак бирә.

## *5. Хайбәр ныгытмасын алу*

Һиҗрәтнең 7нче елында Пәйгамбәребез ﷺ Сүрия юлы өстендә булган Хайбәр ныгытмасын ала. Аны алу өчен каты сугыш була. Гали ибн Әбү Талиб бу сугышта бик зур каһарманлык күрсәтә. Сугышның иң кызган вакытында Галинең кулыннан калканы төшә. Шунда ул ныгытманың ишеген күтәреп, аны калкан итеп куллана. Һичкемнең күзләре моңа ышанмый. Мәгәр Аллаһы Тәгалә биргән бер куәт белән бу булмас кебек күренгән вакыйга була.

Ныгытмадан алынган байлык исәбенә мөселманнар Византия һәм Фарс белән сугышу өчен гаскәрләрен тәэмин итәләр. Бу сугышта мөселманнардан 15 кеше вафат була.


## *6. Аллаһы Тәгалә бүләк иткән гыйбадәт*

Һиҗри белән 7нче елда, Худәйбия килешүе буенча, Пәйгамбәребез ﷺ хаҗга барырга тиеш була. Ул узган елда хаҗ кылырга рөхсәт ала алмаган кешеләр, барлыгы ике мең кеше, Мәккәгә чыгалар. Үзе белән корбанлыкка 60 хайван һәм, көрәешлар һөҗүме була калса дип, корал алалар.

Мәккәгә керер вакыт җиткәч, мөселманнарның Кәгъбә тирәсен әйләнеп йөрүләрен күрергә теләмичә, көрәешлар Мәккәдән чыгып китәләр. Мөселманнар каршылыксыз Мәккәгә керәләр һәм изге урыннарны әйләнәләр. Зияратлары тәмамлангач, һәммәсе бергә Мәдинәгә кайтып китәләр.

## *7. Мәккәи Мөкәррәмне фәтех иту*

Көрәешлар Худәйбия килешүен бозалар һәм моңа бик үкенәләр. Килешүне ныгыту һәм озынайту өчен алар башлыклары Әбү Суфьянны җибәрәләр. Ул теләгәненә ирешә алмыйча кайта.



Пәйгамбәребез ﷺ башта ук көрәешларның килешүне бозачакларын белеп тора. Шул сәбәпле, көрәешлар белмәсен һәм сугышка әзерләнмәсеннәр өчен, ул яшертен генә зур гаскәр туплый башлый. Аның уе, Мәккәнең изгелегенә кагылмыйча гына, көрәешларны буйсындыру иде.

Мөселманнар гаскәрен әзерләү Рамазан ае уртасында тәмамлангач та, Пәйгамбәребез ﷺ зур гаскәре белән юлга чыга.

Мәккәгә якынлашканда Пәйгамбәребез ﷺ нең абыйсы Габбас килеп мөселман була. Бу хәл Пәйгамбәребез ﷺ дә туганы өчен шатлану белән бергә җиңүгә ышанычны да арттыра. Ул бер җирдә ун мең учак ягарга куша. Бу көрәешларны куркыту өчен эшләнә. Гаскәриләр Мәккә янында штаб коралар. Бу хәлләрне күргән мәккәлеләр буйсынырга мәҗбүр булалар.

Пәйгамбәребез ﷺ Мәккәгә керә. Кәгъбәдән потлар алып ташлана. Пәйгамбәр ﷺ Билалга Кәгъбәгә менеп азан әйтергә, намаз вакыты җиткәнлеген белдерергә куша. Мәккә халкы, төркем-

төркем булып, мөселманлыкны кабул итә башлый. Пәйгамбәребез ﷺ күп кешеләрне кичерә, алардан үч алмый.

Рәсүлүлла ятим үзе,
Ятимнәрдә аның күзе,
Әгәр күрсә ятимнәрне,
Барып сөяр иде үзе.

Рәсүлүлла ятим булган,
Ятимнәрнең хәлен белгән,
Аларның башларын сыйпап,
Авыр хәлләренә кергән.

## *Бу бүлектән белгәннәрем*

**Бу бүлектән мин белдем:**

- Бәдер сугышының мөселманнарның җиңүе белән тәмамлануын.
- Өхед сугышының мөселманнарның җиңелүе белән тәмамлануы һәм алар өчен зур сабак булуын.
- Худәйбия вакыйгасын.
- Пәйгамбәребез ﷺ нең патшаларга һәм хакимнәргә илчеләр җибәрүен.
- Һиҗрәтнең 7нче елында Хайбәр ныгытмасы алынуын.
- Һиҗри белән 7нче елда көтелгән хаҗ кылуларын.
- Мәккәи Мөкәррәмә фәтех ителүен.

# 4 -НЧЕ БҮЛЕК

## ТУГРЫ ХӘЛИФӘЛӘР

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ не сау-сәламәт вакытында күреп мөселман булган кешеләр сәхабә дип аталалар. Барысы 114 мең чамасы сәхабә булган. Алар – һәркайсы бик игелекле һәм изге кешеләр. Пәйгамбәребез белән булып, бездән элек мөселман булулары һәм безгә Ислам диненең ирешүенә сәбәп булулары өчен, сәхабәләрнең һәркайсын дус һәм якын күрергә тиешбез. Сәхабәләрнең иң олугълары Мөхәммәд ﷺ нең якын дуслары - Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, Гомәр ибн Хаттаб әл-Фарук, Госман бин Гаффан Зин-Нурайн, Гали ибн Әбү Талиб Хәйдар.

### *1. Әбү Бәкер әс-Сиддыйк*

Әбү Бәкер әс-Сиддыйк Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ вафат булганнан соң сайланган беренче хәлифә, сәхабәләрнең һәм Хүләфәи-Рашидиннарның иң өстене, Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең беренчесе булып, олуглардан беренче булып Ислам динен кабул иткән иде.

Әбү Бәкер әс-Сиддыйк көрәешларның олугларыннан, гарәпләрнең нәсел, чыгышларын һәм тарихларын иң яхшы белүчеләрдән, араларында иң ышанычлы, абруйлы кеше иде. Хәмер эчүне, тәртипле һәм кешелекле булуга зарар китерә дип, Ислам дине килгәнчегә кадәр үк үзенә тыйган иде.

Яшь вакытында ук сәүдәгәр булып, кием белән сату итә иде.

Сату өчен ерак җирләргә – Шам һәм Йәмән җирләренә

кәрван белән сәфәр итә иде һәм ул шуның белән көрәешлар-
ның зур байларыннан санала иде.

Пәйгамбәребез ﷺ Ислам диненә дәгъвәт итә башлагач та Әбү Бәкер иман китерә, хакыйкатьне бик тиз аңлап, динне кабул итә. Рәсүлүлллаһ ﷺ дә Әбү Бәкер кебек акыллы, абруйлы бер кешенең иманга килүеннән бик шатлана.

Ислам динен кабул иткәннән соң Әбү Бәкер бөтен байлыгын, бөтен фикерләрен шул юлга сарыф итә башлый. Никадәр авырлыклар күрсә дә, Ислам дине өчен тырышуына һичбер кимчелек китерми. Иң авыр вакытларда да Рәсүлуллаһ ﷺ не хәтердә тота, үзеннән күбрәк аны кайгырта.

Рәсүлүллаһ ﷺ Мәдинә шәһәренә һиҗрәт иткәндә дә юлдаш итеп үзенә иң ышанычлы булган дусты Әбү Бәкерне ала. Мәдинәдә ул сәүдә белән шөгыльләнә. Мәдинәдә беренче мәчет булган, Рәсүлүллаһ ﷺ мәчетенең урыны да, Әбү Бәкернең акчасына сатып алынган иде.

Пәйгамбәребез ﷺ вафатыннан соң ул хәлифә итеп сайлана. Хәлифәлек вазифасында гадел һәм мәрхәмәтле булып, кул астында булган бөтен кешеләрне үз гаиләсе кебек кайгырта, кулыннан килгән кадәр һәммәсенә ярдәм итә, беркайчан да үзен зурга санамый.

Әбү Бәкер әс-Сиддыйк ике ел һәм өч ай хәлифә булып торганнан соң, 63 яшендә вафат була. Җәназасын Гомәр ибн Хаттаб укый. Кабере Пәйгамбәребез ﷺ янында.

### Әбү Бәкер радыя-ллаһү гәнһе

Күргән заман инанган – Әбү Бәкер әс-Сиддыйктыр,
Өстен булып таянган – Әбү Бәкер әс-Сиддыйктыр.

Моңлашканда елаган – коллыкка бил баглаган,
Эч-бәгърене даглаган – Әбү Бәкер әс-Сиддыйктыр.

Бер сүзеннән кайтмаган, серен һичбер әйтмәгән,
Гафил булып ятмаган – Әбү Бәкер әс-Сиддыйктыр.

## *2. Гомәр ибн Хаттаб әл-Фәрук*

Гомәр ибн Хаттаб әл-Фәрук сәхабәләрнең олугларыннан, Хүләфәи-Рашидиннарның икенчесе, Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең икенчесе. Нәселе Пәйгамәребез ﷺ белән кушыла.

Гомәр әл-Фәрук, Ислам дине килгәнче, көрәешның олугларыннан иде. Мәккә халкы тарафыннан илче булып, чит илләр белән сөйләшү һәм сугыш алып бару аның вазифасы иде.

Гомәр ибн Хаттаб үзенең туган шәһәре Мәккәи-Мөкәррәмәдә көчле һәм кырыс булуы белән мәшһүр иде. Гомәрнең Исламны кабул иткәнче, мөселманнар аның катылыгыннан күп авырлыклар күрәләр иде. Пәйгамәребез Мөхәммәд ﷺ аңарда күп яхшы сыйфатлар күрә һәм Аллаһы Тәгаләдән Гомәрне Исламга күндерүен сорый иде (дога кыла иде).

Бер көнне көрәешларның танылган кешеләренең җыелы-

шында Ислам динен юк итәргә, пәйгамбәребезне үтерергә карар кылалар. Ләкин бу куркыныч эшкә кем алыныр? Гомәр шунда ук уртага чыгып, бу эшне аңа бирүләрен сорый. Кылычын кулына алып юлга чыга.

Юлда Гомәргә бер кеше очрый. Ул Гомәрнең коточкыч карашыннан куркып: “Болай кылыч тотып кая юнәлдең?”, - дип сорый. Гомәр: “Мөхәммәдне үтерергә барам”, - ди. Теге кеше: “Иң беренче үзеңнең гаиләңә кара. Сеңлең дә, киявең дә Исламны кабул иттеләр”, - ди.

Гомәр ибн Хаттаб сеңлесе Фатыйма һәм аның ире Ислам динен кабул итүләрен, Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Рәсүленә иман китергәннәрен белгәч, бик каты ачулана. Гомәр ибн Хаттаб, аларны үтерергә дип, сеңлесе һәм ире өенә юнәлә.

Гомәр сеңлесенең гаиләсе яшәгән өенә килеп җитә, аларның Коръән Кәрим укыганнарын ишек төбендә тыңлап тора. Гомәр, өйләренә килеп кергәч, алар Коръән язылган битләрне яшереп куялар. Гомәр алардан нәрсә укыганнары турында сорый. Сеңлесе: “Без бер нәрсә дә укымыйбыз”, - дип җавап бирә. Гомәр бик нык ачуланып: “Димәк, ишеткәннәрем дөрес икән”, - дип кияве өстенә ташлана. Сеңлесе ирен коткарыр өчен арага кермәкче була, ә Гомәр аңа ачулы тавыш белән: “Син Ислам динен кабул иттеңме, әй Фатыйма?”, - ди.

Фатыйма елаган килеш бөтен көче белән: “Әйе, мин Ислам динен кабул иттем, Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Рәсүленә иман китердем, Аллаһтан башка һичбер илаһ юк һәм Мөхәммәд ﷺ Аллаһның хак Рәсүле икәненә шәһадәт бирдем”, - ди.

Сеңлесеннән бу сүзләрне ишеткән Гомәр башта берни аңламый. Бу күренештән аңа бик авыр була, сеңлесенең елавы аның йөрәген йомшарта. Ул аның кулына тоткан Коръән аятьләре язылган битләрне бирүен сорый.

Фатыйма Коръән аятьләре язылган битләрне ул тәһарәт алганнан соң гына бирәчәген әйтә. Гомәр тәһарәт алганнан соң, Коръән аятьләре язылган битләрне кулына ала һәм аятьләрне игътибар белән укый башлый:

طه مَا أَنْزَلْنَا عَلَيْكَ الْقُرْآنَ لِتَشْقَى إِلَّا تَذْكِرَةً لِمَنْ يَخْشَى تَنْزِيلًا مِمَّنْ خَلَقَ الْأَرْضَ وَالسَّمَاوَاتِ الْعُلَا

“Та Һа. Мәгънәсен Аллаһ белә. Ий Мухәммәд г-м, Без сиңа Коръәнне иңдермәдек коры мәшәкатьләнмәгең өчен, мәгәр иңдердек ул Коръәнне Аллаһтан куркучыларны вәгәзьләвең өчен. Ул җирне вә бөек күкләрне яратучы Аллаһтан иңдерелмеш булды”. *(Та һа сүрәсе, 20/1-4).*

Гомәргә бу аятьләр бик нык тәэсир итә, Коръәннең күңелгә рәхәт биргәнен тоя, аның кальбе иман нуры белән яктыра. Хәзер ул бөтенләй икенче кешегә әйләнә. Ул: “Мин дә инандым, Аллаһтан башка иләһ юк, Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе”, - ди. Ул Ислам динен кабул итәр өчен Мөхәммәд ﷺ белән очрашуны тели.

Барып ишеген кага. Кылыч белән килгәнгә күрә, аңа ишекне ачарга теләмиләр. Өй эчендә, Гомәр кебек үк куркуны белмәс, Хәмзә исемле сәхабә дә була. Ул аны кертергә куша.

Ишек ачыла. Өй эчендә Гомәрне Рәсүлебез Мөхәммәд ﷺ каршы ала һәм көлемсерәп кенә сорап куя: “Гомәр, нигә килдең?” Ул: “Мөселман булырга килдем”, - ди. Пәйгамбәребез: “Аллаһү Әкбәр!”, - дип әйтә. Анда булган сәхабәләр дә бер тавыштан тәкбир әйтәләр.

Пәйгамбәребез ﷺ һәм бөтен мөэминнәр Гомәрнең Ислам динен кабул иткәненә бик шатланалар. Потка табынучылар моңа бик кайгыралар.

Гомәрнең Ислам динен кабул итүе белән күп кенә нәрсәләр үзгәрә. Моннан соң мөселманнар Кәгъбәдә курыкмыйча намаз укый башлыйлар. Гомәр Ислам дине өчен бөек эшләр башкара.

Әбү Бәкер, авырткан вакытында, сәхабәләрнең олуглары белән киңәшләшеп, аларның ризалыгы белән Гомәрне хәлифә итәргә васыять иткән була. Шул сәбәпле, Әбү Бәкер вафатыннан соң, Гомәр хәлифә була һәм ул “Әмирул-мүъминин” дип атала башлый. Шушы вакытта үзенең бөтен көчен, фикерләрен Ислам файдасына корбан итә.

Гомәр ибн Хаттаб ун ярым елдан артыграк хәлифә булганнан соң, мәчеттә иртәнге намазның фарызына керешә. Шул вакыт бер мәҗүси булучы кол хәнҗәр белән чәнчеп, аны берничә җиреннән җәрәхәтли. Бу кол юлда очраган сәхабәләрдән унөч кешене чәнчеп, аларның да җидесе вафат була. Соңыннан ул үзен дә чәнчеп һәлак итә (явызның явызлыгы үзенә кайта).

Гомәр әл-Фәрук алган җәрәхәтләрдән вафат булгач, бөтен мөселманнар бик каты кайгыралар. Гомәр әл-Фәрук вафат булганда 63 яшендә булып, җәназасын Саһиб Руми укый.

**Гомәр радыя-ллаһү гәнһе**

Икенче яры булган – гадел Гомәрдер,
Мөэминлектә яр булган – гадел Гомәрдер.

Мәккә ишеген ачтырган, барча потны ваттырган,
Рәсүл күңелен тындырган – гадел Гомәрдер.

Шәригатьне баш тоткан, юлны раст тоткан,
Хакыйкатьне бик белгән – гадәләтле Гомәрдер.

## *3. Госман бин Гаффан Зин-Нурайн*

Госман бин Гаффан сәхабәләрнең олугларыннан, Хүләфәи-Рашидиннарның өченчесе, Җәннәт белән шатланндырылган ун сәхабәнең өченчесе. Әбү Бәкернең тырышлыгы белән Ислам динен кабул итүчеләрнең беренчеләреннән була. Нәселе Пәйгамәребез ﷺ белән кушыла.

Госман Пәйгамәребез ﷺ нән алты яшькә кечерәк була. Ул көрәешларның мәшһүр һәм ышанычлы сәүдәгәрләреннән булып, сату белән Шам тарафына да барып йөри, холкы күркәм, үзе халык арасында хөрмәтле, юмарт бер зат иде.

Ислам динен кабул иткәннән соң, көрәеш халкы тарафыннан төрлечә газаб һәм җәфа күрә. Шуның өчен хатыны Рукайә (Пәйгамәребез ﷺ нең кызы) белән Хабәшстан (Эфиопия) җиренә һиҗрәт иткәннәрнең (күчеп киткәннәрнең) беренчесе була.

Пәйгамәребез ﷺ Мәдинәгә һиҗрәт иткәннән соң, ул

да анда һиҗрәт итә һәм һәрвакыт Рәсүлүллаһ ﷺ белән бергә була. Бәдер сугышы вакытында аның хатыны Рукайә авырып китә. Аны каравы сәбәпле ул сугышта катнаша алмый. Бу хатыны вафат була. Пәйгамәребез ﷺ аңа икенче кызын – Умм Гүлсумны хатынлыкка бирә. Шуның өчен аңа “Зин-Нүрайн” (“Ике нурның иясе” – Пәйгамбәребез ﷺ нең ике кызының ире) дигән кушамат бирәләр.

Гомәр ибн Хаттаб, вафаты алдыннан, хәлифәне ачык итеп билгеләмәде, ә сәхабәләрнең олугларыннан алтысын әйтеп: “Шулардан берсен хәлифә булуын яхшы күрәм”, - диде. Шуның өчен алар киңәшләшеп, үз араларыннан Госман бин Гаффанны хәлифә итеп сайлыйлар. Шушы сайлауларын халыкка игълан итәләр.

Госман бин Гаффан хәлифә булганнан соң, әүвәлге алты елы гаять яхшы үтә. Халык арасында гыйлем, мәгърифәт һәм байлык бик артканлыктан, һәм Госман бик мөлаем һәм миһербанлы булганлыктан, аны бик яраталар.

Ләкин Госман вакытында Ислам дәүләте бик зурая. Ул үзе дә картаеп, сиксән яшьләренә якынлаша. Аны төрлечә гаепли башлыйлар. Халык арасында фетнә чыга. Араларында начар ниятле булганнары котыртып, Госман бин Гаффан өе янына килеп, аны камап алалар. Берничәсе өенә кереп, Коръән Кәрим укыган вакытында Госман бин Гаффанны үтерәләр. Ул шәһит булып китә. Аллаһы Тәгалә аннан разый булсын.

**Госман радыя-ллаһү гәнһе**

Өченчесе яр булган – Госман ба хәядер (тыйнак),
Һәр нәфестә яр булган – Госман ба хәядыр.

Хак Рәсүлнең кияве, динебезнең һәрнәрсәсе житеше,
Бәндәләрнең азат итүчесе – Госман ба хәядыр.

## *4. Гали ибн Әбү Талиб Хәйдар*

Гали ибн Әбү Талиб Хәйдар сәхабәләрнең олугларыннан, Хүләфәи-Рашидиннарның дүртенчесе, Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең дүртенчесе, Рәсүлүллаһ ﷺ нең кече кызы Фатыйманың ире иде. Пәйгамбәребез ﷺ нең нәселенә иң якын булганы. Пәйгамбәребез ﷺ нең хатыны Хәдичәдән соң, Ислам динен кабул итүчеләрдән булып, егетләрнең иң беренчесе иде.

Пәйгамбәребез ﷺ һиҗрәт иткәндә, әманәтләрен тапшырырга һәм йомышларын үтәргә Гали ибн Әбү Талибны калдыра. Пәйгамбәребез ﷺ өеннән чыгып китә. Көрәешлар, аны үтерер өчен, йортын камап алган булсалар да, аның чыгып киткәнен сизмиләр, чөнки Аллаһы Тәгалә аны алардан саклый.

Көрәешлар ишек тишегеннән карагач, өй эчендә йоклап ятучы кешене күрәләр һәм алар аны Рәсүлүллаһ ﷺ дип, үз планнарын тормышка ашырырга уйлыйлар. Көтеп торулары озакка сузылгач, алар бөтен көчләре белән өйгә ташланалар. Ятакта йоклап ятучы Пәйгамбәр ﷺ түгел, ә Гали ибн Әбү Талиб

була. Ул бу гамәле белән үзен куркыныч астына куя. Ләкин Гали ибн Әбү Талиб, яшь булуына карамастан, алардан курыкмый, чөнки Аллаһы Тәгалә аны саклавына нык ышана.

Гали Пәйгамбәребез ﷺ әйтеп калдырган эшләрне бетергәннән соң, җәяү Мәдинәгә һиҗрәт итә. Юлда бик күп мәшәкатьләр күрә. Мәдинәгә килгәндә аяклары шешеп каный башлый. Пәйгамбәребез ﷺ Галине шул хәлендә күргәч, аны кочаклап, күзләреннән яшьләр агызып, Гали ибн Әбү Талибка дога кыла.

Гали ибн Әбү Талиб, сәхабәләрнең иң галиме булганлыгыннан, мөселманнарга гыйлеме һәм фикерләре белән дә күп хезмәтләр итә. Ул күп кешеләрнең иманлы булуларына, туры юл табуларына сәбәпче була, аларга Ислам хөкемнәрен аңлата.

Госман бин Гаффан үтерелгәннән соң, Мәдинә халкы Гали ибн Әбү Талибтан хәлифә булуын үтенәләр. Башта ул ризалашмый, әмма соңыннан риза була. Ул хәлифә булган вакытында халык икегә аерыла: төрле фетнәчеләр барлыкка килә, фетнәләре зурга китеп, бик зур һәлакәткә сәбәп була.

Гали ибн Әбү Талиб дүрт ел һәм тугыз ай хәлифә булып хезмәт итә. Аны иртәнге намазга барганда бер фиркa тарафдары һәлак итә. Гали ибн Әбү Талибка бу вакытта 63 яшь иде.

### Гали радыя-ллаһү гәнһе

Дүртенчесе яр булган – Әсәдулла (Арыслан) Галидер,
Һәм мигъраҗда яр булган – Әсәдулла Галидер.

Әйткән сүзе рәхмани, күрсәң йөзе нурани (нурлы),
Динсезләрне кырани – Әсәдулла Галидер.

Тырышлык бавы билендә, Аллаһ искә алу телендә,
Зөлфөкаре (кылычы) кулында – Әсәдулла Галидер.

Менеп чыкса Дөлдөлгә (атының исеме), кубадыр ки зилзилә,
Динсезләргә кот чыгу – ул арыслан Галидер.

Бу хөрмәтле дүрт ярдан һәм башка яраннардан
Разый булган барыннан – ул Иләһым Үзедер.

## *Бу бүлектән белгәннәрем*

**Бу бүлектән мин белдем:**

- Хүләфәи-Рашидиннарның иң беренчесе булган Әбү Бәкер әс-Сиддыйкның тормышын.
- Хүләфәи-Рашидиннарның икенчесе Гомәр ибн Хаттаб әл-Фәрукның тормышын.
- Хүләфәи-Рашидиннарның өченчесе Госман бин Гаффан Зин-Нүрайнның тормышын.
- Хүләфәи-Рашидиннарның дүртенчесе Гали ибн Әбү Талиб Хәйдарның тормышын.



# 5-НЧЕ БҮЛЕК
# ИСЛАМ ӘДӘПЛӘРЕ ҺӘМ ДОГАЛАРЫ

## *1. Берәр зарар һәм зыян килсә укыла торган дога*

عَسَى رَبُّنَا أَنْ يُبْدِلَنَا خَيْرًا مِنْهَا إِنَّا إِلَى رَبِّنَا رَاغِبُونَ

*(Гәсәә Раббүнәә әй-юбдиләнәә хайран минһәә. Иннәә илә Раббинәә рагыйбүүн)*

Мәгънәсе: “Шаять Раббыбыз Аллаһы Тәгалә безнең хәлебезне яхшы гына алыштырыр. Тәхкыйк, без Раббыбызга ихлас кыйлучылардан”.

## *2. Кием әдәпләре һәм догалары*

Кием киюдән максат гаурәтне каплау, салкыннан яисә эсседән, зарардан саклау. Шулай ук, башкаларга күркәм күренү дә. Хакыйкый камиллек киемдә түгел, шул сәбәпле аның белән мактанмаска, башкаларның киеменә мәсхәрә күзе белән карамаска кирәк. Киемгә карата шундый әдәпләр бар:

- Мөселманның киеме гаурәтен каплап тора. Егетләрнең гаурәте кендекләре турысыннан башлап, тез асларына кадәр булган тән өлеше. Кызларның тәненең һәр җире гаурәт, бары тик йөзләре, беләзекләренә кадәр ике учлары һәм тубыкларына кадәр аяк башлары гаурәт түгел.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَابَنِي ءَادَمَ قَدْ أَنْزَلْنَا عَلَيْكُمْ لِبَاسًا يُوَارِي سَوْءَاتِكُمْ وَ رِيشًا وَ لِبَاسُ التَّقْوَي ذَالِكَ خَيْرٌ ذَالِكَ مِنْ ءَايَاتِ اللهِ لَعَلَّهُمْ يَذَّكَّرُونَ

“Ий Адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар. Тәкъвалык киеме исә сезнең өчен хәерлерәк. Ошбу зекер ителгән нәрсәләр Аллаһы Тәгаләнең галәмәтләре, шаять кешеләр вәгазьләнерләр”. *(Әл-Әгъраф, 7/26).*

- Мөселман киемнәрен саклап тота һәм чисталыкта йөртә.
- Мөселман егетләре кигән чалбарлары тәнгә сыланып тормаска һәм күлмәкләре үтә күрелмәле булмаска тиеш.
- Мөслимә кызларының киеме гади, гаурәтләрен каплаган, иркен булырга һәм үтә күрелмәле булмаска тиеш.
- Егетләрнең киеме кызларның киеменә, хатын-кызларның киеме ир-егетләрнең киеменә охшамаска тиеш.
- Кием киелгәндә ошбу дога укылыр:

الْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي كَسَانِي هَذَا الثَّوْبَ وَرَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّي وَلاَ قُوَّةٍ

*(Әлхәмду лил-Ләһи-лләзи кәсәәнии һәәзә-с-сәубә вә разәканииһи мин гайри хәүлин миннии вә ләә куввәтин)*

Мәгънәсе: “Бу киемне миңа кидергән Аллаһы Тәгаләгә мактаулар булсын. Ул аны миңа бүләк итте, үземнең көч-куәтемә генә таянып мин аны булдыра алмас идем”.

- Киемне салганда بِسمِ الله (Бисмилләһи) дип әйтә.

## 🕮 Татар мәкальләре, әйтемнәре

- «Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар».
- «Пөхтә кигән – матур кеше, шапшак кигән – ялкау кеше».
- «Әйберне саклап кисәң, көн дә яңа булыр».

## 3. Төчкерү әдәпләре һәм әйтелә торган догалары

- Төчкерергә теләгәндә, төчкерергә кирәк һәм аны тыярга кирәк түгел.
- Төчкергәндә, читкә борылып яисә авызын һәм борынын кулы яки кульяулык белән капларга.
- Төчкергән кеше الحَمْدُ لله *"Әлхәмдули-Лләһ"* ("Аллаһка барча мактауларыбыз") дип әйтергә тиеш, аның бу сүзләрен ишеткән кеше يَرْحَمُكَ الله *"Ярхәмукә-Ллаһ"* ("Аллаһ сине кичерсен") дип әйтергә тиеш, ә бу сүзләрен ишетүче يَهْدِيكُمُ الله *"Яһдиикумү-Ллаһ"* ("Аллаһ сезне туры юлга күндерсен") дип әйтергә тиеш.
- Әгәр кеше төчкереп тә, *"Әлхәмдули-Лләһ"* дип әйтергә онытса, аңа искә төшерергә кирәк.
- Мөселман булмаганнар төчкергәндә *"Яһдиикумү-Ллаһ"* ("Аллаһ сезне туры юлга күндерсен") дип әйтергә.

## Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем

**Бу бүлектән мин белдем:**

- Төчкерү әдәпләрен.
- Кием әдәпләрен.

**Бу бүлектән мин өйрәндем:**

- Берәр зарар һәм зыян килсә укыла торган доганы.
- Кием кигәндә һәм салганда укыла торган догаларны.
- Төчкергәндә укыла торган догаларны.

# 6-НЧЫ БҮЛЕК

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ КИТАБЫ – КОРЪӘН КӘРИМ



### *Коръән Кәрим турында сорау-җавап*

**Сорау:** Коръән нинди Китап ул?

**Җавап:** Аллаһы Тәгалә тарафыннан Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә күктән иңдерелгән, изге бер Китаптыр.

**Сорау:** Коръән Кәрим Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә ни рәвешле иңдерелде?

**Җавап:** Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримне Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә фәрештәләрнең иң олугы Җәбраил (аңа Аллаһның сәламе булсын) аша иңдерде. Җәбраил (аңа Аллаһның сәламе булсын) Коръәнне аңа укый иде һәм ул Пәйгамбәребез ﷺ нең калебенә беркетелә иде.

**Сорау:** Пәйгамбәребез ﷺ гә Коръән тулысынча берьюлы иңдерелдеме?

**Җавап:** Юк, аять-аять, сүрә-сүрә иңдерелде. Аллаһы Тәгалә тарафыннан вакыты белән бер аять, вакыты белән бер

сүрә рәвешендә иңдерелеп торды.

**Сорау:** Пәйгамбәребез ﷺ гә Коръән Кәримнән аятьләр яки сүрәләр иңдерелгәннән соң ул нәрсә эшли иде?

**Җавап:** Иңдерелгән аять-сүрәләрне Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ махсус язучы сәхабәләренә укый иде, ә алар аны язып һәм ятлап ала иде. Алар Пәйгамбәребез ﷺ исән вакытта аның әмере белән Коръәннең барысын да язып чыкканнар иде. Башка сәхабәләр дә аларны язып һәм ятлап ала иделәр.

**Сорау:** Коръән тагын нинди исемнәр белән атала?

**Җавап:** "Әл-Китаб", "әл-Мүбин", "әл-Кәрим", "әл-Кәләм", "әл-Фүркан", "әт-Тәнзил" һ.б. исемнәр белән дә атала.

**Сорау:** Коръәндә ничә сүрә бар?

**Җавап:** 114 сүрә бар.

**Сорау:** Коръәндә иң зур сүрә кайсы?

**Җавап:** "Әл-Бәкара" сүрәсе.

**Сорау:** Коръәндә иң кыска сүрә кайсы?

**Җавап:** "Әл-Кәүсәр" сүрәсе.

### Габдулла Тукай. Тәәссер (Тәәсирләнү)

Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән, -
Газаплар мәгънәви бер кул илә алынадыр җаннан.

Оча дилдән  бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөктән.

Ходаем! Син тыйган эшләр тәмам әкътагъ вә әбтәр, дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһе хак! Аллаһе әкбәр!» - дим.



# ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ

4-НЧЕ СЫЙНЫФ



# 1-НЧЕ БҮЛЕК

## МӨСЕЛМАН КАЛЕНДАРЕ ҺӘМ МӨСЕЛМАН БӘЙРӘМНӘРЕ

### *1. Мөселман календаре*

Мөселманнар елларны Пәйгамбәребез ﷺ нең Мәккәи Мөкәррәмәдән Мәдинәи Мөнәвәрәгә һиҗрәт иткән (күчкән) елыннан башлап хисаплыйлар. Ул вакыйга милади белән 622 нче елда 17 нче августта була. Бу хисаплауга “һиҗри ел” дип әйтәләр.

Мөселманнар һиҗри елны ай йөреше белән хисаплыйлар. Кояш баеганнан соң, күктә ай бик нәзек алтын урак шикелле булып күренгән вакытта ай башы башлана. 29 яисә 30 көннән соңра, икенче ай күренгәч, икенче ай башлана. 12 ай бер елга хисап ителә.

Гарәпчә ай исемнәре шушылар: мөхәррәм, сәфәр, рабигыл-әүвәл, рабигыл-ахир, җәмадил-әүвәл, җәмадил-ахир, рәҗәб, шәгъбән, рамазан, шәүвәл, зөл-кәгъдә, зөл-хиҗҗә.

Ел башы мөхәррәм башында башлана. Күбесенчә мөхәррәм – 30 көннән, сәфәр – 29 дан, рабигыл-әүвәл – 30 дан, рабигыл-ахир – 29 дан, җәмадил-әүвәл – 30 дан, җәмадил-ахир – 29 дан, рәҗәб – 30 дан, шәгъбән – 29 дан, рамазан – 30 дан, шәүвәл – 29 дан, зөл-кәгъдә – 30 дан, зөл-хиҗҗә – кайсы елларда 29 дан, кайсыларында 30 дан килер. Шул сәбәпле ай елы кайсы елларда 354, кайсыларында 355 көн булыр.

Ай хисабында тәүлекнең башы кояш баеганнан соң башлана. Һәр көннең кичәсе үзеннән элек булыр. Яңа айның беренче кичәсе – иске айның ахыргы көненнән соңгы кичә. Икенче кичәсе беренче көненнән соңгы кичә.

## *2. Мөселман бәйрәмнәре*

Мөселманнарның бер ел эчендә мөбарәк көннәре һәм кичәләре шушылар була: Һиҗри ел башы көне, Гашура көне, Һиҗрәт кичәсе, Мәүлид кичәсе, Рәгаиб кичәсе, Миграҗ кичәсе, Бәраәт кичәсе, Фәтех Мәккә көне, Кадер кичәсе, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Гарәфә көне, Тәшрик көннәре.

**Ел башы көне** – мөхәррәм аеның беренче көне. Ай хисабы буенча яңа ел башланган көн.

**Гашура көне** – мөхәррәм аеның 10нчы көне. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ һәм сәхабәләр шушы көнне мөбарәк санап, ураза тота торган булганнар. Күп пәйгамбәрләр бу көндә зур афәт һәм бәлаләрдән котылганнар.

**Һиҗрәт кичәсе** – сәфәр аеның 27нче кичәсе. Шушы кичәдә Пәйгамбәребез ﷺ, Әбү Бәкер әс-Сиддыйк белән, Мәккәи Мөкәррәмәдән чыгып, 12нче рабигыл-әүвәлдә Мәдинәи Мөнәвәрә шәһәренә барып җиткәннәр. Бу һиҗрәттән соң Ислам дине төрле тарафларга тарала. Шул сәбәпле мөселманнарның еллары шушы елның мөхәррәм аеннан башлап хисап кыйлына.

**Мәүлид кичәсе** – 12нче рабигыл-әүвәлдә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ 571 нче елда 27 апрельдә – 12нче рабигыл-әүвәлдә дөньяга килгән. Бу көн, бөтен дөнья мөселманнарының,

дөнья һәм Ахирәт бәхет-сәгадәтләренә сәбәп булган пәйгамбәребезнең туган көне булу сәбәпле, мөбарәк көннәрдән санала. Бу көнне мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә, мөселманнар өйләрендә Коръән мәҗлесләре үткәрәләр, Пәйгамбәребез ﷺ гә салаватлар әйтәләр.

**Рәгаиб кичәсе** – рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кичә. Бу кичәдә Пәйгамбәребез ﷺ нең әтисе Габдулла белән әнисе Әминәнең никяхлары булып, беренче мәртәбә күрешкәннәр.

**Миграж кичәсе** – рәҗәб аеның 27нче кичәсе. Бу кичәдә Пәйгамбәребез ﷺ күккә ашып, Аллаһы Тәгалә белән пәрдә аркылы сөйләшә. Биш вакыт намаз уку шушы кичәдә фарыз ителә.

**Бәраәт кичәсе** – шәгъбан аеның 15нче кичәсе. Риваятьләргә караганда, бәндәләрнең бер еллык бәхет-сәгадәте шушы кичәдә билгеләнә. Шуның өчен бу кичә изгеләрдән санала. Бу кичәдә мәрхүмнәргә догалар кылына, фәкыйрьләргә хәер-сәдака өләшенә, мөселманнар бер-берсенә кунакка йөрешә.

**Мәккәне алу (Фәтех Мәккә) көне** – рамазан аеның 21нче көне. Бу көндә Пәйгамбәребез ﷺ 12 мең гаскәре белән Мәккәи Мөкәррәмәне кяферләр кулыннан алып, кыйблабыз Кәгъбәи–Мөгаззәмәдән сыннарны чыгарган.

**Кадер кичәсе** – рамазан аеның 27нче кичәсе. Бу кичә елның кайсы көнендә булуы ачык мәгълүм булмаса да, риваятьләр буенча, күбесенчә Рамазан аенында 27нче кичәсенә туры килүе ихтимал ителә. Бу кичәдә изге гамәлләрнең савабы башка кичәләргә

караганда күпкә артыграк. Бу һәм рамазан ае тәмамланыр алдыннан булучы башка төннәр – йокламыйча, Аллаһы Тәгаләдән ярлыкавын теләп-ялварып, намаз-гыйбадәт белән уздырыла торган төннәр дип санала.

**Ураза бәйрәме (Гайдел-фитыр) көне** – шәүвәл аеның беренче көне. Рамазан аеның уразасы тәмам булганнан соң бәйрәм ителә торган көн. Бу көндә гайд намазы укыла, фәкыйрьләргә, ятимнәргә һәм мохтаҗларга ураза тәмамлану шатлыгы белән фитыр сәдакасы бирелә.

**Гарәфә көне** – корбан бәйрәме көненнән әүвәлге көненә, зөл-хиҗҗә аеның 9нчы көненә туры килә. Хаҗ гамәлләре шушы көннәрдә эшләнәләр. Һәр ел бөтен дөньядан җыелган хаҗилар, “Гарәфә көнендә” Гарәфә тавында дога һәм гыйбадәттә булалар. Бу көндә якын туганнарның каберләрен зиярат итү, сәдакалар өләшү, якын туганнарга бүләкләр өләшү була.

**Корбан бәйрәме (Гайдел-Корбан) көне** – зөл-хиҗҗә аеның 10нчы көне. Бу көндә мөселманнар гайд намазы укыйлар, корбан чалалар, догалар кылалар. Шулай ук табын мәҗлесләре җыеп, туганнарын, дусларын, кардәшләрен чакырып юмартлык күрсәтәләр, вәгазьләр сөйләнәләр.

**Тәшрик көннәре** – зөл-хиҗҗә аеның 11нче, 12нче һәм 13нче көннәре. Бу көннәр дә бәйрәм көннәре. Гарәфә көненең иртә намазыннан башлап, 13нче зөл-хиҗәнең икенде намазына кадәр, җәмәгать намазларыннан соң, мөселманнар “тәкбир тәшрик” исемле тәкбирне әйтерләр.

**Җомга көн** – барча мөселманнар өчен олуг бәйрәм көне. Бу көндә мөселманнар мәчеткә җыелып җомга вәгазен һәм хотбәсен тыңлыйлар, җомга намазын укыйлар. Бу көндә өйдә, җомга көнен хөрмәтләп, бәйрәм табыннары әзерләнә, тәүбәләр ителә, догалар кылына, сәдакалар бирелә.

📖

Раббым Аллаһдыр минем,
Динем Исламдыр минем,
Кыйблам Кәгъбәдер минем,
Бирдер Аллаһым минем.

Ул Мөхәммәд Мостафа -
Пәйгамбәремдер минем,
Шәфәгатьчемдер минем,
Бирдер Аллаһым минем.

Аллаһым сүзе - Коръән
Пәйгамбәренә килгән.
Безгә ул Китап булган
Бирдер Аллаһым минем.

Адәмдер минем Атам,
Һавадыр минем Анам,
Милләтемдер Ибраһим
Бирдер Аллаһым минем.

# 2-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЛӘР КЫЙССАЛАРЫ

### *1. Сөләйман гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Сөләйман гәләйһис-сәләм Дауд гәләйһис-сәләмнең улы иде. Аллаһы Тәгалә аны пәйгамбәрләрдән сайлап, бер Аллаһка гына гыйбадәт итүгә чакыру белән йөкләде. Аллаһы Тәгалә аңа кошлар һәм хайваннар телен белгертте. Ул алар белән сөйләшә ала иде. Шулай ук, җеннәрне аңа буйсындырып, алар аның хезмәтчеләре иде.

Аллаһы Тәгалә аңа шундый көч-кодрәт биргәнлеген белеп, кешеләр дә, җеннәр дә Сөләйман гәләйһис-сәләмгә буйсыналар иде. Аллаһы Тәгалә Сөләйман гәләйһис-сәләмгә искиткеч зур байлык, патшалык бирә. Аңа җеннәр генә түгел, җилләр дә буйсынып, теләген үти иделәр.

Көннәрдән бер көнне Сөләйман гәләйһис-сәләм үзенең гаскәре белән барганда бер кырмысканы очрата. Ул кырмыскаларның патшасы була. Ул башка кырмыскалар өчен борчылып: “Әй кырмыскалар! Йортларыгызга кереп качыгыз, югыйсә Сөләйман үзенең гаскәре белән сезне күрмичә таптап китәр”, - дип калганнарны кисәтә. Сөләйман гәләйһис-сәләм моны ишетеп елмая һәм: “Әй Раббым, үземә һәм әти-әниемә биргән нигъмәтләреңә шөкер кылырга миңа насыйп ит. Син риза булган изге гамәлләр кылырга ярдәм бир һәм рәхмәтең белән мине изге бәндәләрең арасына керт!”, - ди.

Сөләйман гәләйһис-сәләм үзенең патшалыгында булган һәркем, һәрнәрсә өчен борчыла иде. Моңа карата бер мисал китерик. Көннәрдән бер көнне, Сөләйман гәләйһис-сәләм үзенең патшалыгында Һөдһөд (Удод) кошын югалта. Һөдһөд кошының кайдалыгына җавап ишетмәгәч, ачулана һәм: “Сорамыйча киткәне өчен, кайтканнан соң, югалып торганының сәбәбен аңлата алмаса, мин аңа каты җәза бирермен”, - ди.

Һөдһөд кайткач, Сөләйман гәләйһис-сәләм аннан: “Син кайда булдың?”, - дип сорый. Һөдһөд аңа: “Мин син белми торган Йәмән җирендә, Сәбә шәһәрендә булдым. Анда Бәлкыйс исемле хатын-кыз патшалык итә. Ул үзе дә һәм аның патшалыгы карамагында булганнар да кояшка табыналар. Аның алтын, якут һәм мәрҗәннәрдән бизәлгән бик матур тәхете бар”, - ди. Сөләйман гәләйһис-сәләм: “Мин аңа хат җибәрермен һәм синең дөресме, әллә ялганмы сөйләгәнеңне белермен”, - ди.

Сөләйман гәләйһис-сәләм хат яза һәм Һөдһөдкә биреп әйтә: “Менә бу хатымны алып барып алларына сал, соңыннан читкәрәк китеп карап тор, ничек җавап бирерләр”.



Һөдһөд Сөләйман гәләйһис-сәләм кушканча эшли. Бәлкыйс хатны алып укый һәм киңәшләшер өчен вәзирләрен җыя һәм: “Миңа ни эшләргә икән?”, - дип вәзирләреннән сорый. Вәзирләре: “Әгәр син Сөләйман белән сугышырга телисең икән, без әзер. Безнең көчебез җитәрлек, ләкин үзең уйла”, - дип җавап бирәләр. Бәлкыйс аларга: “Без аның ни кадәр көч-куәтле булганын белмибез. Шуңа күрә аның көч-куәтен белер өчен сезне Сөләйманга бүләкләр белән җибәрәм һәм сез анда аның патшалыгының куәтен белеп кайтырсыз”, - ди.

Бәлкыйсның илчеләре бүләкләр белән Сөләйман гәләйһис-сәләмгә килгәч, аның патшалыгының никадәр зур һәм көчле икәнлеген күреп аптырыйлар. Сөләйман гәләйһис-сәләм аларга: “Сез миңа мал белән ярдәм итәсезме? Аллаһы Тәгалә миңа биргәне сез биргән малдан хәерлерәк. Барыгыз, бүләкләрегезне алып кайтып Бәлкыйска тапшырыгыз. Әгәр сез иман китермәсәгез, без әлбәттә сезгә гаскәр белән барырбыз. Аларга каршы торырга көчегез булмас”.

Сөләйман гәләйһис-сәләм, Бәлкыйсның һәм кавеменең аның янына итагать итеп килүен белгәч, ул янындагы җеннәргә һәм кешеләргә әйтә: “Кайсыгыз Бәлкыйс үзе килгәнче миңа аның тәхетен алып килеп куяр?” Җеннәрдән бер көчлесе: “Син урыныңнан торганчы мин аны алып киләм”, - ди. Икенчесе исә: “Син күз ачып йомганчы, мин ул тәхетне китереп куя алам”, - ди. Һәм шул мизгел эчендә Бәлкыйснең тәхете Сөләйман гәләйһис-сәләмнең күз алдына китереп куелды.

Соңыннан Бәлкыйстан : “Бу синең тәхетеңме?”, - дип

сорый. Бәлкыйс үзенең Йәмәндә калган тәхете ничек Фалыстынга шул арада килүенә гаҗәпләнеп: “Бу тәхет минеке”, - дип җавап бирә.

Бәлкыйсны тагын бер гаҗәеп хәл көтә. Сөләйман гәләйһис-сәләм сараеның идәннәре пыяладан булып, астыннан су ага торган иттереп эшләтелгән була. Бәлкыйс сарайга кергәч суга басам дип күлмәген күтәргәч, Сөләйман гәләйһис-сәләм: “Курыкма! Син пыяла идәннән барасың, аның астында су, киемең юешләнмәс”, - дип тынычландыра. Бәлкыйс: “Әй Раббым, кояшка табынып үземә золымлык кылдым, инде барча галәмне тәрбия итүче Аллаһы Тәгаләгә иман китердем”, - ди.

Сөләйман гәләйһис-сәләм бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга чакыруын ахыргы көненә кадәр дәвам итә.

### Бу кыйссадан алган файдалар

- Сөләман гәләйһис-сәләм Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкерана кылып, тагын да күбрәк гыйбадәттә булды.
- Берәр кешенең, вакыйганың начарлыгы-яхшылыгы турында тикшереп карамыйча, нәтиҗә ясамаска (Сөләман гәләйһис-сәләм Һөдһөд кошын тикшермичә җавапка тартмады).
- Сөләман гәләйһис-сәләм үзенең патшалыгында булган һәр җан иясе өчен борчылуы.

**“Әй Раббым, үземә һәм әти-әниемә биргән нигъмәтләреңә шөкер кылырга миңа насыйп ит. Син риза булган изге гамәлләр кылырга ярдәм бир һәм рәхмәтең белән мине изге бәндәләрең арасына керт!” (Сөләйман гәләйһис-сәләм догасы)**

## *2. Юнус гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Юнус гәләйһис-сәләм пәйгамбәр итеп Гыйрак җирендә яшәүче кавемгә җибәрелә. Ул кавем дә, башка кавемнәр кебек, төрле потларга табына иде.

Юнус гәләйһис-сәләм кавемен бер Аллаһы Тәгаләгә иман китерергә кирәклеген, потларга табынуның файдасы да, зарары да юклыгын аңлата. Әүвәл яшәгән кавемнәрнең дә, шундый тормыш алып барулары сәбәпле, һәлак булганнарын да искә төшерә. Әмма кешеләр бу сүзләргә һәм нәсыйхәтләргә игътибар итмиләр, аны кире кагалар. Юнус гәләйһис-сәләм аларны, Аллаһы Тәгалә аларга каты газап җибәрәчәк дип тә куркытып карый. Ләкин алар: “Без сиңа ышанмыйбыз һәм ата-бабаларыбыздан калган нәрсәләрне ташламыйбыз. Әгәр син безгә газап килә дип куркытасың икән, әйдә җибәр ул газапны, газапла безне!” - диләр.

Юнус гәләйһис-сәләм бу хәлләргә бик кайгыра һәм ул: “Минем иманга чакыруым беткәндер инде”, - дип уйлап, Раббысының әмереннән тыш, икенче җиргә дин таратырга дип, чыгып китә.

Юнус гәләйһис-сәләм шәһәрдән чыгып киткәннән соң Аллаһы Тәгалә аның халкына газап җибәрә. Шул вакытта алар Юнус гәләйһис-сәләмнең сүзләре дөрес икәнлегенә ышанып,

Аллаһы Тәгаләгә ялваралар. Аллаһы Тәгаләдән газапны туктатуын сорап дога кылсын дип, Юнус гәләйһис-сәләмне күпме генә эзләсәләр дә, таба алмыйлар. Күпмедер вакыттан соң Аллаһы Тәгалә газабын туктата.

Юнус гәләйһис-сәләм шәһәрдән чыгып байтак кына узгач, диңгез буена җитеп көймәгә утырып китә. Көймә диңгез уртасына җиткәч көчле дулкыннар күтәрелеп аны чайкый башлыйлар. Кешеләр, әгәр көймәнең авырлыгын җиңеләйтмәсәк, ягъни көймәдән кемнедер суга ташламасак, барыбыз да батып үләчәкбез дип шобага салалар (ыргыткан акчасы иләк яки күн ягы белән төшкән кешегә чыгуы). Суга ташларга тиешле булып Юнус гәләйһис-сәләм чыкты. Кешеләр аның һәрвакыт Аллаһы Тәгаләне зурлаучы кеше икәнен күргәннәр иде. Шуңа да, аны суга ату ярамас дип икенче тапкыр шобага салалар. Әмма икенчесендә дә, өченчесендә дә аңа чыкты. Аны суга ташламыйча чаралары калмый. Юнус гәләйһис-сәләмне диңгез уртасына суга аталар.

Көймәдәгеләрнең күз алдында аны бер зур балык йота. Юнус гәләйһис-сәләм балык карынында кырык көн тора. Кавеменә киләсе газапны искә алып һәм аларны тагын да иманга чакырырга кирәклеген уйлап, Аллаһы Тәгаләдән аны кире кайтаруын сорый (дога кыла).

Аллаһы Тәгалә Юнус гәләйһис-сәләмнең догасын кабул итә. Аллаһның әмере белән балык аны диңгез ярына чыгара. Аллаһы Тәгалә аңа, ял итүе һәм сәламәтләнүе өчен, киң яфраклы бер зур агач үстерә.

Күпмедер вакыттан соң, Юнус гәләйһис-сәләм кавеме янына юнәлә. Кавеме аны шатланып каршы ала. Аллаһы Тәгаләгә иман китергәннәрен хәбәр итәләр. Юнус гәләйһис-сәләм бу хәбәргә бик шатлана.

**Бу кыйссадан алган файдалар**

- Аллаһы Тәгалә догаларны дога кылучыларның кайда булуларына карамастан (хәтта балык карынында да) кабул иткәнен аңладым.
- Аллаһы Тәгалә кушканча яшәгән кеше (кавем) – бәхетле кеше (кавем). Тыңлаулы бала – бәхетле бала.
- Кеше Раббысын җиңеллектә дә, авырлыкта да искә алырга тиеш.

## *3. Гайсә гәләйһис-сәләм пәйгамбәр*

Гайсә гәләйһис-сәләм пәйгамбәр турында сөйләгәнче, аның әнисе Гыймран кызы Мәрьям турында сөйләрбез. Мәрьям үзе Зәкәрия гәләйһис-сәләм тәрбиясендә үсә. Ул һәрвакыт гыйбадәттә һәм зекердә була. Бәни Исраил кавеме арасында үзенең игелеге, пакълеге һәм гыйффәтлеге белән танылган бик әдәпле, һичвакытта ялгыш эш кылмас кыз була.

Бервакыт, ул үзенең гыйбадәт кыла торган бүлмәсендә, аны чакыручы тавыш ишетә (ул фәрештәләр иде): “Әй Мәрьям, Аллаһы Тәгалә сине барча хатын-кызлар арасыннан сайлап алды, гөнаһлардан пакълады һәм сине галәмдәге барча хатын-кызлардан өстен кылды”.

Көннәрдән беркөнне Мәрьям, госел коену ният белән, шәһәрдән чыгып китә. Шәһәргә кайту юлына чыккач, аның каршысына яшь егет сурәтендә Җәбраил фәрештә очрый. Мәрьям аннан куркып әйтә: "Мин синең начарлыгыңнан Аллаһы Тәгаләгә сыгынамын, әгәр син тәкъва мөэмин булсаң, миңа якын килмә". Җәбраил г.с. әйтә: "Дөреслектә, мин синең Раббыңның илчесе. Син саф кыз бала көенчә бер ир бала табачаксың, мин шуны хәбәр итәргә килдем". Мәрьям әйтә: "Минем ничек балам булсын? Мине һичбер ир тотканы юк һәм мин зина кылучы да булмадым". Җәбраил г.с. әйтә: "Әй Мәрьям, әлбәттә син дөрес сөйлисең, ләкин Аллаһы Тәгаләгә атасыз бала тудыру бик җиңел, әгәр Ул "Бул!" дисә ул эш, һичшиксез, була". Шул ук вакытта Мәрьям балага йөкле була.



Мәрьям балага йөкле булуын аңлап, кавеменнән аерылып, ерак җиргә китә. Рәхмәт фәрештәләре аңа төрле ризыклар китерәләр һәм төрле ерткыч хайваннардан саклыйлар.

Мәрьям, баласын

табу нияте белән, хөрмә агачы янына килә. Ул карт хөрмә агачының башы күптән корыган була. Кыш көне булганлыктан аның яфраклары коелган һәм хөрмәсе дә булмый. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән шул ук вакытта хөрмә агачы чәчәк ата, шунда ук җимешләре өлгерә. Аллаһы Тәгалә аңа хөрмә агачының кәүсәсен әкерен генә селкетергә кушкач, аннан өлгергән хөрмә җимешләре төшә. Мәрьям аларны авыз итә, аның баласы туа. Бу туган бала киләчәктә пәйгамбәр булачак Гайсә гәләйһис-сәләм була.

Мәрьям баласы Гайсәне күтәреп үзе яшәгән җирлеккә килә. Кешеләр аны ташлар атып куарга ниятлиләр. Аллаһы Тәгалә Мәрьямгә кешеләр белән сөйләшмәскә кушканга, ул бишектәге баласына ишарәләп, аларга аның белән сөйләшергә куша. Алар әйтәләр: “Син бездән көләсеңме? Бишектәге бала белән без ничек сөйләшик ди?” Шул вакытта Гайсә гәләйһис-сәләм әйтә: “Мин Аллаһы Тәгаләнең колы, Ул миңа Инҗил исемле китап бирде һәм мине пәйгамбәр кылды. Кайда гына булсам да, кешеләр өчен мине файдалы кылды һәм миңа намаз укырга, зәкят бирергә әмер итте. Шулай ук, әниемә изгелек итүче кылды, мине тәкәбберләнүче һәм үзенә гөнаһ эшләүче кылмады. Туган көнемдә, үлгән көнемдә һәм кабердән кубарылган көнемдә Аллаһы Тәгаләдән миңа тынычлык булыр”.

Мәрьям, улы Гайсә гәләйһис-сәләмгә һәм үзенә яһүдиләрнең зарары тияр дип куркып, бер туганы белән Мисыр җиренә китеп, анда 12 ел торалар. Соңыннан кире Мисырга кайтып, Нәсыйра авылында торалар.

Гайсә галәйһис-сәләмгә 30 яшь тулгач, ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан пәйгамбәр итеп сайланып, аңа Инҗил китабы иңдерелә. Инҗил китабында соңгы пәйгамбәр булып пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһис-сәләм киләчәге хакында да әйтелгән була. Гайсә галәйһис-сәләм үзенең кавемен Аллаһы Тәгаләнең диненә чакыра башлый. Ул аларга төрле могҗизалар күрсәтә: кешеләрнең күз алдында үлгәннәрне торгыза; балчыктан бер кош ясап, аны очырта; туганда ук сукыр булганнарны күзле итә; ала тәнле булганнарны алалыктан коткара, су өстеннән йөреп күрсәтә. Гайсә галәйһис-сәләм аларга шуның хәтле могҗизалар күрсәтсә дә, алар аның пәйгамбәрлеген дә, аңа иңдерелгән Инҗилне дә кабул итмиләр. Аңа бары тик 12 кеше иман китерә.

Гайсә галәйһис-сәләм аларга Инҗилдә килгән хөкемнәрне өйрәтә. Бер кичендә ул әйтә: “Бу төн үтеп таң атканда, арагыздан берегез мине бик аз акчага дошманнарга сатачак”. Ул әйткәне дөрес була. Аңа ияргән шәкертләреннән берсе, яһүдиләр янына барып, акчага сатылып, алар җыелган йортны күрсәтә. Яһүдиләр йортны чолгап алалар, бу сатылган кешегә йортка кереп, Гайсә галәйһис-сәләм андамы-юкмы икәнен белеп чыгарга кушалар. Ул йортка керә һәм Гайсә галәйһис-сәләм шунда шәкертләре белән дип әйтергә чыга. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә аны Гайсә галәйһис-сәләм кыяфәтенә кертә, ә Гайсә галәйһис-сәләмнең үзен күккә ашыра. Яһүдиләр исә, Гайсә галәйһис-сәләм кыяфәтенә кертелгән кешене тотып алып агачка кадаклап үтерәләр.

**Бу кыйссадан алган файдалар**

- Аллаһы Тәгалә Кодрәтенең чиге юк һәм Ул бирәр нәрсә булуын теләсә, аңа “Бул!”, - дип кенә әйтә һәм ул була.
- Гайсә гәләйһис-сәләмнең әнисенә карата ягымлы һәм яхшы холыклы булуы.
- Кардәшеңне сату, байлыкка кызыгып иманыңны сату Аллаһы Тәгалә тарафыннан нык җәзалана – фаҗигага китерә. Аллаһы Тәгалә сатлык җаннарны, имансызларны яратмый.

# 3-НЧЕ БҮЛЕК

## ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘД ﷺ НЕҢ ТОРМЫШЫННАН

### *1. Тәбүк вакыйгасы*

Пәйгамбәребез ﷺ Византия дәүләтенең зур гаскәр җыюын һәм мөселманнарга яу белән әзерләнүен ишетә. Мөселманнар бу сугышка әзерләнә башлыйлар. Әбү Бәкер булган малының бөтенесен дә бирә. Гомәр ибн Хаттаб байлыгының яртысын бирә. Госман ибн Гаффан ун мең динар, 300 дөя һәм 50 ат бирә. Башкалар да үз байлыкларына һәм мөмкинчелекләренә карап бирәләр.

Мөселманнар гаскәре утыз мең кешедән тора. Алар бернинди дә тормыш әсәре булмаган Тәбүк дигән җиргә барып җитәләр. Ләкин монда Византия сугышчыларын очратмыйлар. Мөселманнарның көчен һәм Аллаһы Тәгалә хакына үләргә әзер икәнлекләрен белеп, византиялеләр чигенгәннәр. Пәйгамбәребез ﷺ Тәбүктә бер ничә көн була, кешеләрне кабул итә. Соңыннан ул гаскәре белән кире Мәдинәгә таба чыгып китә. Ислам диненең һәм мөселманнарның абруе арта.

### *2. Хушлашу хаҗы*

Һиҗри белән 10нчы елда Пәйгамбәребез ﷺ хаҗ кыла. Бу хушлашу хаҗы була. Аның белән гаҗәеп күп кеше бара – аларның саны 90 меңләп була. Бу юлы Пәйгамбәр ﷺ барлык хатыннарын да ала.

Мәккәгә килеп анда хаҗ гамәлләрен үти. 8нче зөл-хиҗҗәдә ул Минага китә һәм анда төн үткәрә. Тугызында Гарәфәт тавында була, ә кичен исә хушлашу вәгазен сөйли, һәм анда Ислам диненең кайбер мөһим өлешләрен искә ала.

## 3. Рәсүлуллаһ ﷺ нең вафаты

Милади белән 632нче елда һиҗрәтнең 11нче елында Пәйгамбәребез ﷺ авырый башлый. Көче азая, хәттә мәчеткә намаз укырга да чыга алмый.

Пәйгамбәребез ﷺ унөч көн авырый. Бу көннәрдә ул башта чират буенча хатыннары өендә яши. Авыруы көчәйгәч, ул алардан Әбү Бәкернең кызы Гайшә өендә калдыруларын сорый. Алар ризалык бирәләр. Авыруы исә һаман көчәя. Бу вакытта ул кешеләр алдында үзе урынына намаз укуны Әбү Бәкергә тапшыра.

Рабигыл-әүвәл аеның 12нче дүшәмбе көнне иртәнге намазны уку өчен мәчеткә чыга. Әбү Бәкер имам булып тора, аңа ияреп намаз укый. Өенә кайтуга авыруы тагы да көчәя. Башын Гайшә анабызның кочагына салган хәлдә рухы фани дөньядан аерыла һәм ул: “Иң Бөек Иптәш янына... иң Бөек Иптәш янына...” дигән сүзләре белән Бөек Раббысы хозурына китеп бара.

Пәйгамбәребез ﷺ һиҗринең 11нче елында, рабигыл-әүвәл аеның 12ндә, дүшәмбе көнне, 63 яшендә вафат була. Милади белән 633нче елның 8 июне була бу.

Пәйгамбәребез ﷺ не өч кат кәфенлеккә урыйлар. Кешеләр аның белән бәхилләшергә төркем-төркем булып киләләр, дога кылалар. Аннары аны вафат булган җирендә – Гайшә өендә күмәләр. Кабер җирдән бер карыш күтәрелеп тора.




## *4. Рәсүлүллаһ ﷺ ның сыйфатлары*

Рәсүлүллаһ ﷺ урта буйлы, түгәрәк ак йөзле, зур күзле, күзенең карасы чем-кара, агы бераз кызгылт, озын һәм нечкә кашлы, борыны озынчарак, уртасы аз гына күтәренке һәм очтан бөгелә төшкән, зуррак авызлы, киң мангайлы, керфекләре куе, куе кара сакаллы, ак һәм сирәгрәк тешле, киң күкрәкле, эре сөякле, беләкләре тулы, тәне тыгыз итле иде. Күренешкә гаять ягымлы булып, беренче күргән кешегә дә үзен сөйдерә торган күренештә һәм кыяфәттә иде.

Йөреше егетләрчә булып, тирә-якка каранмый, алдына гына карап йөри торган иде. Чисталыкка зур игътибар бирә иде һәм халыкны да шуңа бик кызыктыра иде. Чәчен тарауны ярата иде. Хушбуйлана һәм хушбуйны бик сөя иде. Тырнакларын гел

кисеп тора, озын йөртми иде. Халыкны пакъ йөрергә, юынырга кызыктыра һәм ким дигәндә атнасына бер мәртәбә булса да коенырга куша иде.

## *5. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең хатыннары*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ вафат булганнан соң аның 9 хатыны кала. Пәйгамбәр ﷺ белән яшәгән хатыннарның гомуми саны 11 була. Икесе (Хәдичә һәм Хузайма кызы Зәйнәб) Пәйгамбәребез ﷺ бу дөньядан киткәнче вафат булалар.

Пәйгамбәр ﷺ Хувайлид кызы Хәдичәгә 23 яшендә өйләнә һәм ул 28 ел дәвамында аның бердәнбер хатыны була. Бу никахтан ул бик бәхетле була. Хәдичә аңа Касыйм, Габдулла, Зәйнәп, Рокыя, Өммегөлсем һәм Фатыйма исемле балалар таба. Ир балалары кечкенәдән үк вафат булалар, ә кыз балалары ул исән вакытта, кияүгә чыккач үләләр. Бары Фатыйма гына әтисенең вафатыннан соң алты ай узгач үлә. Пәйгамбәр ﷺ гә 51 яшь булганда Хәдичә вафат була (һиҗрәт итүгә 2 ел кала).

Хәдичә вафат булган елны Пәйгамбәр ﷺ Мәккәдә Әбү Бәкер р.а.г. кызы Гайшәне ярәштерә һәм Әбү Бәкер р.а.г. белән аны алу турында килешә. Хакыйкый никах 3 елдан соң Мәдинәдә була.

Гайшәне ярәшкәннән соң, ул Замаа кызы Сәүдәгә өйләнә. Сәүдә Әс-Сакран ибн Амр исемле бер мөселманнан тол булып калган була. Әс-Сакран Хабәшстанга һиҗрәт иткән мөселманнарның берсе, соңыннан ул Мәккәгә кайтып шунда вафат була. Сәүдә үз ире белән бергә Ислам динен кабул итә һәм аның белән бергә һиҗрәт кыла, бөтен авырлыкларны һәм газапларны кичерә.

Пәйгамбәр ﷺ нең аңа өйләнүе, аны тәэмин итү һәм

мөэминнәрнең анасы дәрәҗәсенә күтәрү өчен була. Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, Пәйгамбәр ﷺ анын өчен мәчеткә янәшә торак булдыра.

Бәдер сугышыннан соң һиҗри белән 2нче елда Пәйгамбәр ﷺ Гомәр ибн Хаттаб кызы Хафсага өйләнә. Аның ире Хунайс ибн Хузафа Әс-Сахмия Ислам динен беренчеләрдән кабул иткән. Ул вафат булып 7 ай үткәч Пәйгамбәр ﷺ Хафсага өйләнә.

Пәйгамбәр ﷺ нең Гайшә һәм Хафсага өйләнүләре, өйләнү өчен генә түгел, ә үзенең якын ярдәмчеләренең Исламны җәелдерүдә, сугышларда, җитәкчелек итүдә һәм башка эшләрдә Пәйгамбәр ﷺ нән аерылмыйча ияреп йөрүче сәхабәләренең (Әбү Бәкер, Гомәр ибн Хаттаб) кызларына өйләнү була.

Бану Мусталакь сугышында (һиҗри белән 5 нче елда) ул Харс кызы Джувайриягә өйләнә. Аның өйләнүе Джувайриянең дәрәҗәсен күтәрү һәм аның әтисен Ислам диненә якынайту өчен була. Джувайриянең әтисе Бану Мусталакъ кабиләсенең башлыгы була. Мөселманнар алар белән сугышкач, Джувайрия әнсарларның берсенә әсирлеккә төшә. Ул үзен әсирлеккә төшүчедән сатып алмакчы була. Ләкин әсирлеккә алучы, аның кабилә башлыгының кызы булуын белеп, бәясен күтәрә. Ул Пәйгамбәр ﷺ янына ярдәм сорап килә. Пәйгамбәр ﷺ әйтә: «Мин сиңа моннан да яхшыракны тәкъдим итимме?» Ул: «Ә нәрсә ул?», - дип сорый. Пәйгамбәр ﷺ әйтә: «Мин синең йолымыңны түлим (выкуп) һәм сиңа өйләнәм». Ул шуңа риза була. Шуннан соң аның әтисе дә Исламны кабул итә. Бу, Пәйгамбәр ﷺ тара-

фыннан җиңелгән кабилә башлыгының кызына өйләнү иде һәм бу никах белән Пәйгамбәр ﷺ анның әтисен үзенә җәлеп итә.

Хәйбәр җиңүеннән соң (һиҗри белән 7 нче елда) Пәйгамбәр ﷺ Сафиягә өйләнә, ул яһуди башлыкларының берсенең кызы була. Хайбәр ныгытмасын алганда Сафия әсирлеккә төшә һәм Пәйгамбәр ﷺ гә кайбер мөселманнар әйтә: «Сафия ул Бану Курайз һәм Надир кабиләләренең бикәсе, шул сәбәпле ул синең өчен генә кулай». Әсирлектән коткару һәм анның дәрәҗәсен күтәрү өчен Пәйгамбәр ﷺ аны азат итеп, өйләнә. Пәйгамбәребез ﷺ анның әтисен, ирен һәм халкын (дингә өндәү юлында) юк итүгә сәбәпче булса да, Сафия Пәйгамбәребез ﷺ нең вафат булуына хәтле аңа тугры булып кала. Ул чын мөэмин хатын була.

Һиҗри белән 8 нче елда Пәйгамбәребез ﷺ 26 яшьлек Мәймүнәгә өйләнә. Мәймүнә мөселманнарны әл-Када гомрәсендә күргәч, Ислам динен бик кабул итәсе килә. Габбас р.а.г. Пәйгамбәр ﷺ белән шуның хакта сөйләшә (Габбас р.а.г. Пәйгамбәребез ﷺ нең әтисе абыйсының улы иде) һәм аңа өйләнергә тәкъдим итә. Пәйгамбәребез ﷺ шуңа риза була. Пәйгамбәребез ﷺ Мәймүнәгә өйләнүне, көрәешлар белән уртаклыкка ирешү өчен куллана.

Һиҗри белән 2нче елда Пәйгамбәребез ﷺ Хузайма кызы Зәйнәбкә өйләнә. Зәйнәб, Бәдер сугышында шәһит булып киткән, Харис бин Убайданың хатыны. Зәйнәб үзе матур булмаса да, фәкыйрьләргә ярдәм итүдә дан казану сәбәпле, аны «Уммүл-Мәсәкин» («Фәкыйрьләрнең анасы») дип йөртәләр. Пәйгамбәребез ﷺ аңа өйләнгән вакытта ул инде яшь

булмый. Ул Пәйгамбәребез ﷺ белән ике ел да яшәмичә вафат була.

Әбү Умайя ибн Әл-мушра кызы Умму Сәләм (үз исеме Һинд) Әбү Сәләм ибн Абдәл-Әсадның (исеме Абдулла) хатыны булып, аның берничә баласы (Гомәр, Зәйнәб һәм Рокайя) бар иде. Әбү Сәләм Өхед сугышында катнашып җәрәхәтләнә. Аның җәрәхәте төзәлә һәм Пәйгамбәребез ﷺ аны Бану Асад кабиләсенә каршы сугышта байрак тотучы итеп билгели. Бу сугыштан ул җиңү белән кайта, ләкин Өхед сугышында алган җәрәхәт ачылып, ул үлә. Үлем хәлендә ятканда Пәйгамбәребез ﷺ килеп аның өчен Аллаһы Тәгаләдән сорады. Иренең вафатыннан 4 айдан соң Умму Сәләмне Пәйгамбәребез ﷺ ярәшә. Башта ул: "Балаларым күп һәм мин яшь түгелмен", - дип кияүгә чыгарга теләми. Ләкин Пәйгамбәребез ﷺ, аңа өйләнгәнче һәм балаларын үз өстенә тәрбиягә алганчы ярәшүне дәвам итә. Димәк, Пәйгамбәребез ﷺ нең Зәйнәбкә һәм Умму Сәләмгә өйләнүе аның ике сәхабә гаиләсен тәэмин итүе өчен була.

Рамлә Умму Хабиб - Әбү Суфьян ибн Харба кызы (мөшрикләрнең әйдәүчесе һәм Мәккәнең җитәкчесе) була. Ул – Убайдуллаһ ибн Джахшның (әтисе Пәйгамбәр ﷺ апасының малае иде) хатыны. Убайдуллаһ мөселман була һәм аның хатыны Рамлә дә Ислам динен кабул итә. Ә аның әтисе кяфер булуын дәвам итә. Рамлә, әтисе тарафыннан җәберләнүдән куркып, йөкле хәлендә ире белән Хабәшстанга һиҗрәт кыла. Анда кызы Хабибәтуа һәм аны Умму Хабиба, дип йөртә башлыйлар. Ләкин ире Убай-

дуллаһ, Ислам диненнән ваз кичеп, нәсара динен кабул итә. Ире, Рамләның да Исламнан ваз кичүен тели, ләкин ул Исламга тугры кала һәм бөтен авырлыкларга сабыр итә. Соңыннан Пәйгамбәр ﷺ Хабәштанның патшасы Наджашка хат җибәрә. Шул хатта Умму Хабибка өйләнүдә аңа вәкил булуын сорый. Наджаш шул хакта Умму Хабибка җиткерә. Умму Хабиб үз тарафыннан Хәлид ибн Сәгыйд дигән кешене вәкил итә. Шул рәвештә никах кылуга килешү үтә. Хәйбәр сугышыннан соң Хабәштанга һиҗрәт кылучылар Мәдинәгә кайткач, Умму Хабиб Пәйгамбәребез ﷺ нең өенә керә. Мәдинә шәһәре халкы Пәйгамбәребез ﷺ нең Умму Хабибка өйләнүен бәйрәм итә.

Пәйгамбәр ﷺ нең Джахш кызы Зәйнәбкә өйләнүе кайбер хөкемнәрнең чыгарылуына сәбәп була. Зәйнәб Умайманың кызы (Умайма ул – Абд Мутталиб кызы, ягъни Пәйгамбәр ﷺ нең апасы). Зәйнәб Пәйгамбәр ﷺ нең тәрбиясендә үсә. Шул сәбәпле ул Пәйгамбәр ﷺ өчен кызы һәм сеңеле дәрәҗәсендә була. Пәйгамбәр ﷺ аны бик яхшы белә һәм аның тууыннан алып балигыга хәтле үсүен күрә. Пәйгамбәр ﷺ аны Зәйдкә (кайчандыр Хәдичә тарафыннан сатып алынган кеше) ярәштерә. Ләкин Зәйнәбнең абыйсы Абдуллаһ моңа риза булмый. Ул көрәеш нәселеннән булган сеңлесе өчен моны зур хурлык дип исәпли. Дөрестән дә, ул вакытта гарәпләрдә бу зур хурлык исәпләнә. Затлы нәселдән булган кызларга колларга (гәрчә ул кол азат ителгән булса да) кияүгә чыгу килешми торган була.

### Йә Рәсүлем!

Йә рәсүлем Мөхәммәд, кыйлдың галәмгә рәхмәт,
Чиктең дөньяда зәхмәт өммәт өчен, Мостафа.
Саллəл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Аллаһүммә бу галәмне синең өчен яратты,
Әүвәлгедән ахырынача синең исемең таратты.
Саллəл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Әүвәлге пәйгамбәрләр һәммәсе белде сине,
Син идең хәтем ән-нәбийә, барчасы өммәт сиңа.
Саллəл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

Китабың булды Коръән - бөтен галәмгә солтан!
Син Мөхәммәд Мостафа, безгә шәфәгатьче син.
Саллəл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!


Син Аллаһның хәбибе, гөнаһларның табибы,
Һәркем сине искә алды, йә Мөхәммәд Мостафа!
Саллəл-Лаһү гәләйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!

## *Бу бүлектән белгәннәрем*

**Бу бүлектән мин белдем:**

- Византия дәүләте мөселманнарга каршы сугышка әзерләнсә дә, үз ниятен тормышка ашырмавын. Моның белән Ислам диненең һәм мөселманнарның абруе артуын.

- Һижри белән 10нчы елда Пәйгамбәребез ﷺ нең Хушлашу хаҗын кылуын.
- Пәйгамбәребез ﷺ һиҗринең 11нче елында, рабигыл-әүвәл аеның 12ндә, дүшәмбе көнне, 63 яшендә вафат булуын (миладие белән 633нче елның 8 июнендә).
- Пәйгамбәребез ﷺ вафат булган җирендә – Гайшә өендә күмелүен.
- Расүлүллаһ ﷺ ның сыйфатларын.
- Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең хатыннарын: Хувайлид кызы Хәдичә, Гайшә, Замаа кызы Сәүдә, Хафса, Харс кызы Джувайрия, Сафия, Мәймүнә, Хузайма кызы Зәйнәб, Умму Сәләм, Умму Хабиб, Джахш кызы Зәйнәб.



# 4 -НЧЕ БҮЛЕК

## МӨСЕЛМАННЫҢ КҮРКӘМ ХОЛЫКЛАРЫ

### *1. Тырышлык*

Тырышу һәм тырышлык – динебезнең әһәмиятле мәсъәләләреннән берсе. Аллаһы Тәгалә тырышуны да гыйбадәтләрнең берсе итеп саный һәм аны фарыз кыла.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا

“Аллаһ биргән малны, Аллаһ юлына биреп, Ахирәтне кәсеп ит, дөньядан да үз өлешеңне онытма”. *(Әл-Касас сүрәсе, 28/77).*

Дөнья тормышы өчен тырышмаганнар ярлы булып калырлар, көчләрен, куәтләрен югалтып, башка кешеләрнең кул астына төшәрләр. Мондый кешеләр гыйбадәтләрен дә төгәл иттереп үти алмаслар, мәдәният һәм мәгърифәттән аерылырлар, надан булып калырлар. Бу кешеләрнең диннәре, иманнары зәгыйфьләнер, дөнья кайгысыннан диннәрен кайгыртырлык хәлләре калмас, алар тормышта авыр хәлләргә төшәрләр.

Дөньяга артык бирелеп Ахирәтен оныткан кешеләрнең хәлләре дә моңа охшар. Дин, иман зәгыйфьләнер, мәчетләрдә намаз укучылар азаер, кешеләр арасында өлфәт һәм мәхәббәт бетәр. Кешеләрнең дәрәҗәсе акча белән генә үлчәнер. Тәкәбберлек артыр, дуслык һәм кардәшлек азаер.

Бу хәлләрнең икесе дә аяныч. Шуның өчен мөселман дөнья

тормышын да дөрес итеп алып барырга, Ахирәтне дә онытмаска тиеш.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: “Чын мөселман Ахирәттән дә, дөньядан да ваз кичмәс. Дөньясын калдырып, бары тик Ахирәте өчен тырышучы хәерле, яхшы мөселман булмас. Ахирәтен калдырып бары тик дөньясы өчен тырышучы да хәерле, яхшы мөселман булмас. Кешенең хәерлесе, яхшысы дөньясы өчен Ахирәтен калдырмас, Ахирәте өчен дөньясын калдырмас. Икесен дә бергә алып барыр һәм башкаларга авырлык китермәс”.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: “Дөнья өчен һич үлмәс кебек тырыш, Ахирәт өчен иртәгә үләчәк кебек тырыш”.

Мөселман кешесе – дөнья һәм Ахирәт эшләрен тигез алып барыр. Дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле яшәү – мөселманның хакы. Дөньяда бәхетле булыр өчен, Ахирәтне онытмыйча, тырышлык белән яшәргә кирәк, чөнки дөнья тормышы безгә вакытлыча бирелгән, ул бик тиз үтеп китәчәк. Ахирәт тормышы гына мәңгедер.

Пәйгамбәребез ﷺ иң еш кыла торган догаларының берсе “Раббәнә әтинә” догасы булган:

رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الآخِرَتِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّار

*(Раббәнә әәтинәә фид-дүнья хәсәнәһ вә фил-әхирати хәсәнәһ вә кынәә гәзәбән-нәәр)*

Мәгънәсе: “Әй Раббыбыз! Безгә дөньяда да, Ахирәттә дә яхшылык һәм гүзәллек бир. Безне Җәһәннәм утыннан сакла”.

*(Әл-Бәкара сүрәсе, 2/201).*

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Дөнья Ахирәтнең кырыдыр. Ул кырга нәрсә чәчсәң, Ахирәттә шуны җыярсың".

**Мөселман кешесе дөнья тормышын да дөрес итеп алып бара, Ахирәтне дә онытмый.**

### Салих бабай васыяте

Салих бабай олы яшьтәге, мәрхәмәтле, гомерен Аллаһы Тәгаләгә итагать итүгә багышлаган ир иде. Авылындагы мәчеттә намазларын җәмәгать белән укуны бер дә калдырмый иде. Балаларын үзе белән йөртеп, аларга тәһарәт алуны һәм намаз укуны өйрәткән иде.

Аллаһы Тәгалә аңа ризыкны кәсеп итүгә юлларын ачкан иде. Аның зур бакчасы булып, анда алмагач, слива, груша, миләш агачлары, карлыган, кура җиләге бар иде. Шулай ук, җире булып, анда бәрәңге, помидор, кыяр, суган, җиләкләр үсә иде. Аның зур йорты да бар иде.

Аллаһы Тәгалә аңа мәрхәмәтле, итагатьле хатыны Фатыймадан дүрт ир бала Ибраһим, Гомәр, Госман, Гали һәм Зөһрә исемле кыз бирде.

Салих бабай Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу өчен җыйган уңышыннан гошерен һәм зәкятен авыл мохтаҗларына бирә, бик еш өстәмә уразалар тота, Коръән Кәримне күп укый иде.

Салих бабайның кешеләргә карата мөгәмәләсе бик яхшы иде.

Үзен башкалардан өстен куймый һәм тәкәбберләнми,

үзен гади тота, башкаларга яхшы киңәшләр бирә иде. Авыл халкы арасында мәшәкатьләр, низаглар килеп чыкса, аның янына киләләр, ә ул алар арасын төзекләндерә иде.

Бер көнне Салих бабай бакчасында эшләде, кайтканда кояш бата иде инде. Ахшам намазын мәчеттә укып, өенә кайтты. Кинәт аның хәле китте һәм ул хәл алыр өчен караватына ятты. Аның янына уллары һәм кызы килде, алар аның өчен бик борчылдылар.

Әтиләре авыр тавыш белән әйтте:

-Әй, улларым, кызым, әгәр әҗәлем җиткән булса, кайгырмагыз. Үлем - хак, ул барыбызга да киләчәк. Аллаһы Тәгалә сезгә биргән нәрсәләрдә тәкъва булуыгызны васыять итәм. Сез мескеннәргә һәм фәкыйрьләргә хакларын вакытында биргәнемне күрдегез. Әгәр аларның үз хакларын алуларыннан тыйсагыз, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булырсыз.

Аннары Салих бабай кинәт тукталды, су сорады, бер йотым эчкәч, “Әлхәмдүлилләһ”, дип әйтте. Соңыннан җан-тәслим кылды (вафат булды).

Салих бабайның вафат булуына бөтен авыл халкы бик кайгырды. Шушы изге кешене соңгы юлга озатырга һәм туганнарының кайгысын уртаклашырга хәтта күрше авыллардан да килделәр. Җеназа намазында кеше бик күп иде.

Салих бабай вафат булганнан соң да балалары аның эшен дәвам иттеләр. Бакчасы һәм җире тагы да зурайды һәм матурланды. Ел саен алар мескен һәм фәкыйрьләргә тиешле зәкятләрен чыгаралар иде, хәтта арттырып сәдакаларын да өләшәләр иде.

**Күнегүләр:**

1. Пәйгамбәребез ﷺ нең берәр хәдисен дәфтәреңә язып куй (исеңдә калдыр).

2. Тырышлык турында берничә мәкаль язып кил. Мәсәлән: "Карама кешенең сүзенә, кара эшенә" һ.б.

## *2. Сабырлык*

Сабырлык – түземле булу, авыр хәлләр килгәндә чыдам булып, үзеңә хуҗа булу, ямьсез сүзләр һәм начар хәрәкәтләрдән үзеңне тыя белү дигәнне аңлата.

Бу дөнья – имтихан дөньясы. Кеше дөньяда төрле хәлләр белән очраша. Кайбер хәлләр кешене шатландыра, кайберләре кайгыга сала. Шатлык вакытында шөкер, кайгы вакытында сабыр булу мөселманнарга фарыз ителгән.

Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын уйлап, Аллаһ кушканга сабыр итүнең зур савабы бар. Аллаһы Тәгалә Корьәндә әйтә:

قُلْ يَاعِبَادِ الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا رَبَّكُمْ لِلَّذِينَ أَحْسَنُوا فِي هَذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةٌ وَأَرْضُ اللَّهِ وَاسِعَةٌ إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُمْ بِغَيْرِ حِسَابٍ

"Ий Мухәммәд ﷺ әйт: «Ий иман китергән Аллаһның бәндәләре, Раббыгызның газабыннан сакланыгыз! Дөньяда вакытта Аллаһка итагать итеп изге гамәлләр кылган хак мөэминнәргә, Ахирәттә Җәннәт нигъмәтләре бардыр. Аллаһы Тәгаләнең җире киндер! Сабыр итүчеләргә хисапсыз әҗерләр бирелер". *(Әз-Зүмәр, 39/10).*

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: “Мөселман шатлыклы хәлендә шөкер итәр. Бу аның өчен бер савaптыр. Кайгылы вакытында сабыр итәр. Бу да үзе өчен бер савaптыр. Мөселманның хәле гаҗәп, һәр эшендә үзенә савап бар. Бу мөселманнарда гына булыр”.

Сабырлык – мөселманның коралы, ләкин шулай да сабырлыкны дөнья тормышыбызда белеп кулланырга кирәк. Хәлебездән килеп тә берәр эш белән мәшгуль булмасак, ялкаулык басар. Ярлылыкка риза булсак, Аллаһы Тәгалә болай язган дип, ярлылыкка баш июнең сабырлыкка катнашы юк.

Сабырлык өч төрле була:

1 – Бәла-каза һәм һәлакәтләргә карата булган сабырлык. Бәла-каза һәм һәлакәтлек кешенең малына, җанына һәм баласына төшсә, кешенең аларны туктатырга көче һәм белеме җитмәсә, ул моңа риза булып сабыр итәр. Җир тетрәүләр, су басулар, сугышлар кебек хәлләрдә авырлыкларга түзеп сабыр итәргә кирәк. Мондый хәлләрдә кешеләр сабыр итмәсәләр, алар шушы бәхетсезлекләр каршысында өметсезлеккә төшеп, дөньядан бизәрләр. Аларга тормышның тәме калмас, сабырсызлык аларның дөнья һәм Ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булыр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ وَالثَّمَرَاتِ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ

“Ий мөэминнәр! Без сезне, әлбәттә, сыныйбыз куркынычлардан бер куркыныч биреп, ачлык биреп, малларыгызны киметеп, сәламәтлекләрегезне киметеп, кетмәгәндә якыннарыгыз

ны үтереп, игеннәрегезне һәм бакча җимешләрегезне киметеп. Аллаһтан сынар өчен бирелгән төрле авырлыкларга риза булып һаман Аллаһ юлыннан баручы сабыр булучы мөэминнәрне Аллаһның рәхмәте вә Җәннәте белән шатландыр!”

*(Әл-Бәкара сүрәсе, 2/155).*

Кодси хәдис: “Аллаһы Тәгалә әйтте: “Мин колларымнан берсенең гәүдәсенә, малына яисә баласына зарар иткәндә, колым ул бәлане сабырлык белән кабул итсә, мин ул колым өчен үлчәү корып, гамәл дәфтәрен ачудан (ягъни Кыямәт көнендә җавап алудан) азат итәрмен”.

2 – Гыйбадәтләрне сабырлык белән кылу: озын һәм эссе көннәрдә ашамый-эчми ураза тоту; кыска төннәрдә, кояш чыкмастан әүвәл торып, иртәнге намазны уку; биш вакыт намазны вакытында һәм калдырмыйча үтәп бару; Мәккәгә барып хаж гамәлләрен башкару; байларга малларыннан зякәт чыгару һ.б. Бу гыйбадәтләрне җиренә җиткереп үтәүнең, әлбәттә, үзенә күрә авырлыклары да бар. Бу авырлыкларга сабырлык итү белән генә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешергә мөмкин.

Ислам динендәге гыйбадәтләр һәрвакыт сабырлык белән башкарылыр. Динебезнең максаты кешене сабырлы итеп тәрбияләү һәм шуның нәтиҗәсендә аны дөньяда да һәм Ахирәттә дә бәхетле итү.

3 – Гөнаһ эшләр кылмауга сабыр итү. Кеше, бер яктан Аллаһы Тәгаләнең әмерләре, икенче яктан эчендәге начар теләкләре, уйлары һәм шайтанның хәйләсе белән каршылыклы хәлдә яши.

Мондый чакларда кеше, шайтанга ияреп, Аллаһ юлыннан тайпылса, зур гөнаһларга дучар була. Кешенең эчендә начар эшләргә өндәгән бер көч, куәт яши. Аңа нәфес дип әйтәләр. Шушы нәфес белән көрәшү, ул өндәгән начар уйларга, ниятләргә каршы тору – динебез әмер иткән нәрсәләр.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: "Көрәштә иптәшләрен җиңгән кеше түгел, ә нык ачуланган хәлдә, сабыр итеп, үз ачуын җиңгән кеше генә көчле кеше дип санала".

📖

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр итми ни хәл итик?
Сабыр төбе диләр алтын,
Сабыр бирсен Үзе Аллам.

Сабырлар Җәннәттә,
Аллаһның рәхмәтендә,
Сабырсызлар Җәһәннәмдә,
Сабыр бирсен Үзе Аллам.

Сабыр иткән бәндәләрне
Сабитлардан санаганнар.
Сабырлыкның савапларын
Китаплардан караганнар.

Түзә алмыйм, йөрәк сызыла,
Күзләремнән яшьләр коела.
Сабырларны Аллаһ сөя,
Сабырлык бир Үзең Аллам.

**Аллаһы Тәгалә сабыр итүчеләр белән булыр.**

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Нәрсә ул сабырлык? соравына җавап яз.
2. Сезнең гаиләдә иң сабыр кеше дип кемне саныйсың? Ни өчен?

## *3. Әманәт*

Әманәт – саклану өчен кемгә булса да тапшырылган нәрсәгә карата әйтәләр.

Әманәт сүзенең төрле мәгънәләре бар. Пәйгамбәребез ﷺ безгә әманәт итеп Коръән Китабын, Ислам динен тапшырган. Без бу әманәтне, ике күзебез кебек саклап, бездән соң киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез. Әгәр динебезне сакламасак, изге Коръәнне өйрәнмәсәк, тора-бара динебез дә онытылырга мөмкин.

Җан да кешегә бер әманәттер. Җанны бирүче Аллаһы Тәгалә. Вакыты җиткәч бу әманәт кире алыныр. Үз-үзен үтергән кешеләр, Аллаһның бу әманәтенә хыянәт иткән өчен зур гөнаһлы булырлар. Тәнебезне авырулардан саклау, аны сәламәт тоту әманәтнең бер төредер.

Безгә тапшырылган вазифалар һәм эшләр дә әманәт булып санала. Аларны хәлебездән килгән кадәр җиренә җиткереп башкарырга тиешбез. Әгәр аларны тиешенчә башкара алмасак, әманәткә хыянәт кылган булабыз.

Балалары һәм гаиләсе дә кеше өчен бер әманәттер. Аларны динле һәм әхлаклы итеп тәрбияләү, гореф-гадәтләребезне өйрәтеп, милли һәм дини тойгылар белән үстерү безнең әманәт бурычларыбыз. Шулай ук безгә сер итеп сөйләнгән сүзләр дә әманәт.

Әманәтнең киресе хыянәт була. Безгә тапшырылган әманәткә зарар китерү яисә аны иясенә бирмәү, эшләребезне җиренә җиткереп үтәмәү хыянәт булып исәпләнә. Мондый эшләр динебездә хәрам санала.

## 🕮 Гомәр әл-Фәрук кыйссасы

Гомәр әл-Фәрук (Аллаһ аннан разый булсын) бер вакытны дәүләт эшләрен башкарганда аның янына Габдрахман ибн Гауф исемле бер сәхабә керә. Сәламләшкәннән соң Гомәр аннан сөйләшүе шәхсиме әллә дәүләткә кагылышлымы дип сорый. Соңыннан Гомәр өстәлендәге шәмне сүндереп тартмага алып куеп, икенче шәмне чыгарып кабыза.

Сәхабә Гомәр ибн Хаттабның шушы эшенә карап торган да сораган: “Я, Гомәр! Шәмнең берсен сүндердең, икенчесен кабыздың. Боларның икесе дә шундый ук шәм. Ник болай эшләдең?”

Гомәр болай дип җавап биргән: “Син килгән вакытта дәүләт эшен эшли идем. Син килеп, синең эшең дәүләткә катнашы булмавы сәбәпле, синең белән сөйләшкәндә дәүләтнең шәмен

яндырырга хакым юк. Шуның өчен, тартмадан алып, үз акчама алынган шәмне кабыздым”.

### Мәкальләр, әйтемнәр:

- «Әманәткә хыянәт итмиләр».
- «Әманәткә хыянәт – ул кешегә кыямәт».

**Әманәтне сакла, аңа бер кайчан да хыянәт итмә!**

### Күнегүләр:

1. Әманәт яисә хыянәт турында үзегез белгән берәр вакыйганы язып килергә яки сөйләргә. Хикәя яисә әкият тә сөйләргә мөмкин.
2. Әманәт яисә хыянәт турында татар мәкальләрен китер.

## *4. Локман Хәкимнең улына әйткән нәсыйхәтләре*

Элек вакытларда бик хикмәтле һәм изгелекле Локман исемле Хәким (Патша) яшәгән. Ул үзенең улын бик каты яраткан һәм аны күркәм әхлаклы тәрбияләргә бик тырышкан. Улы нәсыйхәтләр буенча гамәлләр кылсын өчен, аның белән озак вакытлар шөгыльләнеп, аңа бик хикмәтле нәсыйхәтләр биргән. Хикмәтле һәм игелекле булганы өчен аны Аллаһы Тәгалә һәм кешеләр яратканнар.

Локман Хәким улына әйтә: “Улым, намазларыңны вакытында укы, кайда булсаң да, кешеләрне яхшылыкка өндә һәм гөнаһ-

лы эшләрдән тый, сиңа ирешкән авырлыкларга, бәла-казаларга сабыр ит. Тәхкыйк, бу әйтелгән нәрсәләр, Аллаһы Тәгалә фарыз иткән олуг нәрсәләрдәндер”.

Балалар! Шушы хикмәтле нәсыйхәтләрнең нәтиҗәсен күрәсезме? Локман Хәким улына намаз укырга нәсыйхәт бирә, чөнки намаз Аллаһы Тәгаләгә якынайтучы һәм гөнаһлардан ерагайтучы нәрсә була. Кешеләрне яхшылыкка өндәргә, начарлыктан тыярга чакыра. Улына ирешкән авырлыкларга сабыр итәргә нәсыйхәт итә, чөнки бәла-каза итеп җибәргән нәрсәләргә сабыр итүчеләрне Аллаһы Тәгалә ярата.

Локман Хәким тагын улына нәсыйхәт әйтә: “Кешеләр белән сөйләшкәндә тәкәбберләнеп, яның белән сөйләшмә, җир өстендә, әллә кем булып, мактанып йөрмә. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә үзенә исе китеп мактанып йөрүчеләрне сөйми. Йөрүең уртача булсын, сөйләгәндә тавышыңны да уртача ит. Тәхкыйк, тавышларның иң начары ишәк тавышы”.

Локман кешеләр арасында тәкәбберләнеп йөрүдән улын кисәтә, аны тәкәббер булудан һәм үзенә исе китеп мактанып йөрүдән тыя, чөнки Аллаһы Тәгалә шулай эшләүчеләрне сөйми.

Локман улына уртача йөрүне нәсыйхәт итә: бик тиз дә, бик әкрен дә түгел. Ашыгып бик тиз барса, зарарга юләгергә мөмкин, бик әкрен барса, вакыт бушка үтәргә мөмкин.

Локман Хәким улына сөйләгәндә тавышын уртача итәргә нәсыйхәт итә. Кычкырып сөйләшкән кешенең тавышы ямьсез булып, ул ишәк тавышына охшап кала. Ямьсез тавыш кешеләрне борчуга һәм ярсытуга китергәне өчен.

**“Кешеләр белән сөйләшкәндә тәкәбберләнеп сөйләшмә һәм җир өстендә, әллә кем булып, мактанып йөрмә”.**

**Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Сиңа кем булса да яхшы нәсыйхәтләр биргәне бармы? Син ул нәсыйхәтләрне үтисеңме? Шул хакта фикерләп кара әле.

2. Син үзеңнең энеңә-сеңлеңә нинди нәсыйхәтләр бирер идең? Аларга биргән нәсыйхәтләрне үзең үтисеңме?

## *5. Яхшы һәм начар сүз*

Яхшы сүз ул – яхшылыкка чакыручы һәм начарлыктан ераклаштыручы һәр сүз: Аллаһы Тәгаләне зекер итү, сәлам бирү, аралары бозылган ике кешене дуслаштыру һ.б.

Ислам дине безне яхшы сүзләр сөйләргә чакыра, чөнки ул кешеләр арасында мәхәббәтне арттыра. Яхшы сүз белән җәмгыятебез алга бара һәм эшләре күркәм була. Яхшы сүз ул нык булып үскән агач шикелле, аның тамырлары җирдә нык, ботаклары күккә үрелгән, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән җимешен һәрвакыт биреп тора.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَلَمْ تَرَى كَيْفَ ضَرَبَ اللَّهُ مَثَلًا كَلِمَةً طَيِّبَةً كَشَجَرَةٍ طَيِّبَةٍ أَصْلُهَا ثَابِتٌ وَفَرْعُهَا فِي السَّمَاءِ تُؤْتِي أُكُلَهَا كُلَّ حِينٍ بِإِذْنِ رَبِّهَا وَيَضْرِبُ اللَّهُ الْأَمْثَالَ لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ

“Беләсеңме, яхшы сүзгә (*«Лә Иләһә Илләллаһ»* сүзенә) Аллаһ нинди гаҗәп мисал китерә, ул сүз яхшы үскән агач шикелле,



аның тамырлары җирдә нык тора, ботаклары күккә үрелгән, Раббысының әмере белән җимешен һәрвакыт биреп тора. Аллаһ бәндәләренә шундый мисалларны китерә, гыйбадәтләнеп вәгазьләнсеннәр өчен”.

*(Ибраһим сүрәсе, 14/24-25).*

Ни өчен соң Аллаһы Тәгалә яхшы сүзне яхшы агач белән чагыштыра?

Аллаһы Тәгалә яхшы сүзне яхшы үскән агач белән чагыштыра, чөнки яхшы сүз кешеләргә рәхәтлек китерә, тынычлык бирә, ягъни ул кешеләргә файда бирә. Яхшы агач та үзенең җимешләре, күләгәсе һәм матур күренеше белән кешеләргә файда китерә.

Әгәр мөселман үзенең өстен булуын теләсә, сөйләгәндә һәрвакыт яхшы сүзләрне кулланырга өйрәнергә кирәк.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ янына берәү килеп аннан сорады: “Мөселманнарның иң хәерлесе кем?” Пәйгамбәр Мөхәммәд ﷺ әйтте: “Мөселманнар аның теленнән һәм кулыннан имин булучы кеше”.

Ислам дине һәрвакыт яхшы сүзне таратырга чакыра. Мәсәлән, кешеләр булган җиргә кергәндә сәлам бирү һәм исәнләшү, чыкканда да сәлам әйтү һәм саубуллашу.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең хәдисе: “Берегез кешеләр җыелган җиргә килсә, сәламен бирсен. Әгәр китәргә теләсә, шулай ук сәлам бирсен. Һәм беренчесе, икенчесеннән хаклырак түгел” (ягъни, килгәндә дә, киткәндә дә сәлам бирү икесе дә бер тигез).

Начар сүз исә ул – начарлыкка өндәүче һәм яхшылыктан еракլаштыручы һәр сүз: гөнаһ эшләргә чакыру, начар сүзләр әйтү, кешеләрне мыскыл итү, ялганлау һ.б.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә начар сүзне тамыры белән йолкып җир өстенә ташланган, һичбер нәрсәгә яраксыз начар агач белән чагыштыра:

وَمَثَلُ كَلِمَةٍ خَبِيثَةٍ كَشَجَرَةٍ خَبِيثَةٍ اجْتُثَّتْ مِن فَوْقِ الْأَرْضِ مَا لَهَا مِن قَرَارٍ يُثَبِّتُ اللَّهُ الَّذِينَ
آمَنُوا بِالْقَوْلِ الثَّابِتِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ وَيُضِلُّ اللَّهُ الظَّالِمِينَ وَيَفْعَلُ اللَّهُ مَا يَشَاءُ

“Начар сүзнең мисалы: тамыры белән чыгарып җир өстенә ташланган һичбер нәрсәгә яраксыз начар агач шикелле. Иман китереп хак диндә булган кешеләрне Аллаһ дөньяда вә Ахирәттә дәлил белән сабит булган «Лә Илаһә Илләллаһ» сүзенә беркетер, әмма иман китермәгән залимләрне Аллаһ адаштырыр, Аллаһ теләгән эшне кылыр”. *(Ибраһим сүрәсе, 14/26-27).*

Ни өчен соң Аллаһы Тәгалә начар сүзне начар агач белән чагыштыра икән?

Начар сүз кешеләргә бернинди дә файда китерми, киресенчә, аларга зарар һәм авырлык китерә. Начар агач та шуның шикелле: кешеләргә аннан файда китерүче җимеше дә, күләгәсе дә юк, аның күренеше дә кешеләрне үзенә җәлеп итми.

### 📖 Галимҗан Латыйп. Яхшы сүз, яман сүз

Яхшы сүз яшәртә, көч бирә,
Кулыңа сәләт һәм эш бирә.

Яхшы сүз шифалы, тылсымлы.
Юа ул яраны, борчуны.
Яхшы сүз тауларны күтәрә.
Давыллар аркылы үткәрә.
Яхшы сүз ярдәмгә ашыга.
Әйтерсең эретә ул ташны да.
Яман сүз агудай әшәке.
Хәтта ул корыта чәчәкне.
Ул сине калдыра чырага.
Йөзеңә җыерчык чыгара.
Яман сүз еландай сугыла.
Ул салкын бозны да туңдыра.
Яхшыны күрегез, аңлагыз.
Яманга битараф калмагыз.

**Әй Раббым! Телләрем белән яхшы сүзләр генә әйтсәм иде һәм начар сүзләрдән ерак булсам иде.**

**? Сораулар һәм күнегүләр:**

1. Син тагын нинди яхшы сүзләр беләсең? Шуларны дәфтәреңә язып кил.
2. Рәсемгә берәр матур агач ясап, аның яфракларына яхшы сүзләр генә язып чык.

## *6. Әти-әнигә хөрмәт*

Ихлас мөселманның иң күзгә күренгән сыйфаты – үзенең әти-әнисен хөрмәт итүе һәм аларга карата яхшы мөгамәләдә булуы, чөнки бу якты дөньяга килүебезгә әти-әниләребез сәбәпче булган һәм тормыштагы төрле авырлыкларга карамыйча, безне яхшы кеше итәргә тырышканнар. Шул сәбәпле балаларның әти-әниләренә карата булган хаклары бик зур булып, аны түләп бетерү мөмкин түгел. Моның хакта Коръән Кәримдә бик күп аятьләр һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ нең хәдисләре бар. Түбәндә мөселман кешесе үзенең әти-әнисенә карата нинди мөгамәләдә булырга тиеш икәнлеген китерәбез:

1) Аларга карата яхшы булу, аларны хөрмәт итү: Исламда әти-әнине хөрмәт итүгә һәм аларга яхшы булуга бик зур урын бирелгән һәм ул аларны, башка кешеләргә караганда, күбрәк ихтирам итә. Шул сәбәпле, мөселманның әти-әнисенең берсе яки икесе дә картаеп көчсезләнсәләр аларга карата яхшы булуны Аллаһы Тәгалә әмер итә:

وَقَضَى رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِنْدَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا
أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُلْ لَهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُلْ لَهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا وَاخْفِضْ لَهُمَا
جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُلْ رَبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا

«Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, Аллаһка гына гыйбадәт кыйлырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга

«уф» та димә, һәм кәефләрен җибәрмә, ә аларга һәрвакыт йомшак һәм мөлаем сүзләр сөйлә! Һәм аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй! Һәм әйт: «Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм Ахирәттә шәфкать кыйл!».

*(Әл-Исра сурәсе, 17/23-24).*

Габдуллаһ бин Мәсгудтән риваять ителә. Ул әйтте: «Бер вакытны мин Пәйгамбәр ﷺ нән сорадым: «Аллаһ кайсы гамәлне күбрәк ярата?» Ул әйтте: «Вакытында укылган намазны». Мин сорадым: «Ә аннан соң?» Ул әйтте: «Әти-әнигә хөрмәт күрсәтү». (Бохари һәм Мөслим).

Инде хөрмәт итүдә, мөселман кешесе әти-әнисеннән иң беренче урында әнисен куярга тиеш, соңыннан әтисен. Чөнки әни ул баланы 9 ай буе үзендә йөртә, соңыннан аны ашата һәм тәрбия итә. Һәм шушы гамәлләрендә әни кеше күп авырлыклар күрү сәбәпле Аллаһы Тәгалә аңа карата хөрмәтне күбрәк күрсәтүне өстенрәк куя.

2) Аларга карата йомшак булу, аларны тыңлау, итагать итү. Әти-әнигә хөрмәт күрсәтмәү, аларны түбәнсетү, тыңламау, аларга каты булу, алар белән кычкырып сөйләшү бик зур гөнаһ һәм бик начар эш дип санала. Әлбәттә бу эшләрдән ихласлы мөселман бик курка.

Әбү Бәкер Нуфайг бин Әл-Хәристән риваять ителә: Ул әйтте: «Бер вакытны Пәйгамбәр ﷺ сорады: «Сезгә, кайсы гөнаһ иң олуг икәнен хәбәр итимме?» Без әйттек: «Әлбәттә, Я Рәсүлүллаһ!» Ул әйтте: «Ул – Аллаһка ширек кылу һәм әти-әнине тыңламау».

*(Бохари һәм Мөслим).*

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Аллаһы Тәгалә өч төрле кешегә Җәннәтне хәрам кылды: исерткеч эчемлеккә гадәтләнеп калучыга, әтиәнисен рәнҗетүчегә, гаиләсендә бозыклыкны урнаштыручыга».

3) Әти-әни картайсалар, аларга мал белән ярдәм итү.

Киләчәктә баласының тормышы яхшы булыр, акчасы күп булыр һәм ул үзенең гаиләсе белән мәшгуль булып, үзенең әти-әнисен кайгыртмас. Һәм әти-әнисе аңа күпме акча сарыф иткәнен онытып, аларга карата саранлык күрсәтер, нәтиҗәдә аңа Аллаһның ачуы төшәр.

Риваять ителә: «Бер вакытны Пәйгамбәр ﷺ янына бер кеше килә һәм әйтә: «Я Рәсүлүллаһ, минем акчам һәм балаларым бар, ләкин әтием минем акчаларымны аласы килә!» (ягъни әтисен карау өчен күп акча кирәк булып, ул шул акчаны аңа бирсә, аның үзенә бер нәрсә дә калмаска мөмкин иде). Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Син үзең һәм кулыңда булган нәрсә – әтиеңнеке. Шиксез, балаларыгыз тапкан нәрсәне ашагыз!» (ягъни, әтиләрнең акчага ихтыяҗы булса, алар балаларының акчасыннан үзенә алырга хаклы, үз акчасын алган шикелле. Баласының акчасы юк икән, әмма акча эшли ала икән, ул акча эшләп әтисенә сарыф итәргә тиеш).

4) Аларны дога белән шатландыру, әти-әнисенең дуслары һәм туганнары белән элемтәдә тору: Ислам дине әти-әнине хөрмәт итү белән генә түгел, ә вафат булганнарыннан соң да онытмаска – аларны һәрвакыт хәер-дога белән искә төшерүне әмер

итте; әти-әнисенең дусларына, туганнарына да хөрмәт күрсәтүне – алар белән элемтә өзмәүне кушты.

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Шиксез, олылауның иң югарысы – әтисе вафат булганнан соң, ул яраткан кешеләр белән элемтәне тотып тору». (Мөслим).

Пәйгамбәр ﷺ әйтте: «Әтиең яраткан кешеләр белән элемтәдә тор һәм шул элемтәне өзмә, өзсәң Аллаһ синең нурыңны бетерер!» (Мөслим).

Бер сәхабә Пәйгамбәр ﷺ нән сораган: «Я Рәсүлүллаһ. Мин әтиәнием вафат булганнарыннан соң аларга изгелек кыла аламмы?» Ул әйтте: «Әйе, дүрт нәрсә белән: Аллаһы Тәгаләдән аларны гафу итүен сорап дога кылу, аларга биргән вәгъдәне үтәү, аларның дусларына хөрмәт күрсәтү һәм аларның туганнары белән элемтәне өзмәү белән». (Бохари).

## Мәҗит Гафури. Ата-ана

Сөямен чын күңел берлән үземнең әткә-әнкәмне;
Яраткан барча нәрсәмнән алар матур, алар ямьле.

Сабый чакта күземне ачкач ук күрдем мин аларны,
Сөям мин шул вакыттан бирле бу хөрмәтле җаннарны.

Күтәргәннәр авырлыклар минем өчен җаннары тынмый,
Киендергән, ашатканнар тузан чаклы авырсынмый.

Атам ул – мал табып балам дигән дә тәрбия кыйлган;
Анам ул – ниндәен татлы йокыларын бүләк иткән.

Язу белдем, уку белдем, үзем сигезенче яшемдә;
Бу нигъмәтләр насыйп булды аларның тәрбиясендә.

Минем бар әткәм-әнкәм, мин шуңар чын-чын бәхетлемен;
Аларга мин бурычлымын, ничек үтәргә белмимен.

Сөямен чын күңел берлән үземнең әткәм-әнкәмне, -
Алар олуг, алар матур, алар дөньяда иң ямьле.

**Татар мәкале:**

- «Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган әрәм булган».

**Әй Раббым! Әти-әниемнең гөнаһларын кичер һәм аларны Җәннәткә керт!**

**? Күнегүләр:**

1. Әтиең, әниең, дәү әтиең, дәү әниең турында Пәйгамбәребез ﷺ нең берәр хәдисен кулланып сөйлә.
2. Түбәндәге җөмләне язып бетер (дәфтәреңә күчереп):

“Мөселман кешесе әти-әнисенә карата шундый мөгамәләдә булырга тиеш: хөрмәт итәргә, булышырга.................................................

# 5-НЧЕ БҮЛЕК

## ИСЛАМ ӘДӘПЛӘРЕ ҺӘМ ДОГАЛАРЫ

### *1. Йокы әдәпләре һәм укыла торган догалары*

Мөселман бала Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт истә тотып, әдәпле була һәм йокыга карата түбәндәге әдәпләрне үти.

- Йоклар алдыннан шушы дога укылыр:

اللَّهُمَّ أَسْلَمْتُ نَفْسِي إِلَيْكَ وَفَوَّضْتُ أَمْرِي إِلَيْكَ وَوَجَّهْتُ وَجْهِي إِلَيْكَ وَأَلْجَأْتُ ظَهْرِي إِلَيْكَ رَغْبَةً وَرَهْبَةً إِلَيْكَ لاَ مَلْجَأَ وَلاَ مَنْجَا مِنْكَ إِلاَّ إِلَيْكَ آمَنْتُ بِكِتَابِكَ الَّذِي أَنْزَلْتَ وَبِنَبِيِّكَ الَّذِي أَرْسَلْتَ

*(Әл-Лаһүммә әсләмтү нәфсии иләйкә вә фәввәдтү әмрии иләйкә вә вәжҗәһтү вәжһии иләйкә вә әлжәътү заһрии иләйкә рагбәтән вә раһбәтән иләйкә лә мәлжә-ә вә лә мәнжәә минкә иллә иләйкә. Әмәнтү би-Китәбикә-лләзи әнзәлтә вә би-нәбийикә-лләзи әрсәлтә)*

Мәгънәсе: «Әй Аллаһым! Мин үземне һәм үз эшемне Сиңа тапшырдым, йөземне Сиңа юнәлттем. Сиңа омтылган вә курыккан хәлдә аркамны ышыкладым, качу һәм котылу урыны Синең алда гына. Мин Синең иңдергән Китабыңа һәм җибәргән илчеңә иман китердем».

- Йоклар алдыннан, “Әл-Ихлас”, “Әл-Фәләк” “Ән-Нәс” сүрәләрен укып үч төпләренә өреп, алар белән баштан алып бөтен тәнне сыпырып чыгарга. Шундый рәвештә өч тапкыр эшләргә.

- Йокларга ятканда уң якка карап ятырга. Ир-егетләргә йөзтүбән, ә хатын-кызларга аркасына ятып йоклау һич ярамас.

- Йоклаган вакытта өскә берәр нәрсә ябынып йокларга, җиләс һәм дымлы урыннарга ятмаска.

- Малайлар һәм кызлар бер бүлмәдә түгел, ә аерым бүлмәләрдә йокларлар.

- Бер бүлмәдә йоклаучылар аерым караватта йокларлар. Аерым караватта йоклау мөмкин булмаса, өсләренә ябынган одеяллары аерым булырга тиеш.

- Ашказан тулы килеш йокларга ятмаска.

- Йокыдан уянгач, иң беренче, Аллаһы Тәгаләгә мактау сүзләрен әйтү:

الحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي أَحْيَانَا بَعْدَ مَا أَمَاتَنَا وَإِلَيْهِ النُّشُورُ بِاسْمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلَي اللهِ

*(Әлхәмдү ли-Лләһи-лләзи әхйәәнәә бәгдә мәә әмәәтәнәә вә иләйһин-нүшүүр. Бисмил-Лләһи тәвәккәлтү гәләл-Лааһи)*

Мәгънәсе: “Безне йоклатканнан соң терелткән Аллаһка барча мактаулар булсын һәм Аңа кире кайтачакбыз. Аллаһ исеме белән башлыйм һәм Аллаһка тапшырам”.

**Вил Казыйханов. “Әбием догалар укый”**

Әбием догалар укый,
Еллар имин булсын, дип.
Кешеләр тату яшәсен,
Илем тыныч булсын, дип.

Догалар, догалар,
Алар кешеләргә
Игелекле булырга кушалар.

Әбием догалар укый,
Игеннәр мул уңсын, дип.
Көзен келәтләр, амбарлар
Гел ашлыкка тулсын, дип.

Догалар безне өйрәтә
Аллаһны яратырга.
Яхшылыкка шатланырга,
Сагышны таратырга.

Әбием күп дога белә,
Һәр дога – изге теләк.
Мин дә аларны өйрәнәм
Тырышып һәм бик теләп.

## *2. Юл әдәпләре һәм догалары*

Мөселман бала Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт истә тотып, әдәпле була һәм юлда йөргәндә түбәндәге әдәпләрне үти:

- Өйдән чыкканда түбәндәге доганы укый:

بِسْمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلَى اللهِ وَلاَ حَولَ وَلاَ قُوَّةَ إلاَّ بِاللهِ

*(Бисми-Лләһи, тәвәккәлтү гәлә-Лләһи, вә лә хәүлә вә лә куввәтә иллә би-Лләһи)*

Мәгънәсе: «Аллаһның исеме белән башлыйм. Мин Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылам. Көч һәм куәт Аллаһы Тәгаләгә генә хас».

- Өйгә кергәндә түбәндәге доганы укый:

بِسْمِ اللهِ وَلَجْنَا وَبِسْمِ اللهِ خَرَجْنَا وَعَلَى رَبِّنَا تَوَكَّلْنَا

*(Бисми-Лләһи вәләҗнәә вә бисми-Лләһи хараҗнәә вә гәлә Раббинәә тәвәккәлнәә)*

Мәгънәсе: «Аллаһның исеме белән кердек, Аллаһның исеме белән чыктык һәм Раббыбызга тәвәккәл кылдык».

Бу сүзләрне әйткәннән соң керүче өйдә булучыларга сәлам әйтер.

- Машиналар йөри торган юлда туп белән уйнамый, чөнки бу машиналарның йөрүенә комачаулык китерә һәм кешеләргә авырлык килүгә сәбәпче була.
- Ярдәмгә мохтаҗ булучыларга, мәсәлән, сукырларга, картларга, авыру булганнарга, кечкенә балаларга ярдәм итә.
- Олыларга, бала белән булучыларга юл бирә.
- Сәлам бирүчеләргә сәламне кайтара.
- Конфет кәгазьләрен, көнбагыш кабыкларын, алма кабыкларын һ.б. юлга ташламый, ә урамнарда куелган урналарга сала.
- Юлда кешеләргә комачаулый торган әйберләр булса, мәсәлән, таш, агач ботагы һ.б., аларны юл кырыена алып куя.
- Юлда ипи яки башка ризык ятса, аны юл кырыена алып куя яисә кошларга бирә. Болар барысы да саваплы гамәлләр.

**Татар мәкале**: “Бер савап-рәхмәт мең бәладән коткарыр”.

## *3. Мәчет әдәпләре һәм догалары*



Мәчетләребез – Аллаһы Тәгаләнең йортлары. Мөселманнар мәчетләрдә көненә биш вакыт намазларын, җомга көнендә җомга намазын, гаетләрдә гает намазларын укыйлар. Мәчетләргә карата мөселманнар түбәндәге әдәпләрне саклыйлар:

- Мәчеткә керер алдыннан тәненең һәм киеменең чиста булуына, үзеннән начар ис килмәвенә ышанган булырга тиеш.
- Аяк киемен салып керергә кирәк.
- Мәчеткә кергәндә уң аяк белән атлап керергә кирәк һәм шушы доганы укырга:

اللهُمَّ افْتَحْ لِي أَبْوَابَ رَحْمَتِكَ وَانْشُرْ عَلَيَّ خَزَائِنَ رَحْمَتِكَ

*(Әллаһуммә-фтәх ли әбүәбә рахмәтикә вән-шүр гәләййә хазәәинә рахмәтик)*

Мәгънәсе: “Я Рабби, миңа Рәхмәт ишекләреңне ач һәм Рәхмәт хәзинәләреңне чәч”.

- Мәчеттән чыкканда сул аяк белән атлап чыгарга кирәк һәм шушы доганы укырга:

اللهُمَّ إِنِّي أَسْئَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِيمِ

*(Әллаһүммә инни әс'әлүкә мин фәдликәл-гәзыйм)*

Мәгънәсе: "Я Рабби, тәхкыйк, мин Синнән олугъ фәзыйл (өстенлек) һәм Рәхмәтеңне сорыйм".

- Мәчеткә кергәч тә ике рәкәгать "тәхиятел-мәсҗед" намазы кылыр.
- Мәчет эчендә үзеңне әдәпле тоту тиеш: зикер, тәсбих һәм догада булу, Коръән һәм дини китаплар укып утыру яисә вәгазь тыңлап утыру яки гыйлем өйрәнеп утыру кирәк.
- Мәчеткә суган һәм сарымсак ашаган көенчә керү һәм мәчет эчендә дөнья эшләре эшләп, дөнья сүзләре сөйләп, көлешеп утыру тыелган.

## *Бу бүлектән белгәннәрем һәм өйрәнгәннәрем*

**Бу бүлектән белдем:**

- Юл әдәпләрен.
- Кием әдәпләрен.
- Мәчет әдәпләрен.

**Бу бүлектән өйрәндем:**

- Кием киелгәндә укыла торган доганы.
- Киемне салганда укыла торган доганы.
- Өйдән чыкканда һәм кергәндә укыла торган доганы.
- Мәчеткә кергәндә укыла торган доганы.
- Мәчеттән чыкканда укыла торган доганы.

# 6-НЧЫ БҮЛЕК

## АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ КИТАБЫ – КОРЪӘН КӘРИМ



### *Корьәннең иңдерелүе һәм бер мусхафка тупланууы*

Корьән Кәрим Ләүхел-Мәхфүздә язылган. Мәгълүм булганча Корьән Кәрим дөнья күгендәге "Бәйтүл-Гиззәгә" бөтен килеш Рамазан аеның Кадер кичәсендә иңдерелгән. Соңыннан Аллаһы Тәгалә тарафыннан Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ гә 23 ел дәвамында билгеле бер вакыйгаларга карап бүленеп-бүленеп иңдерелгән.

Пәйгамбәребез ﷺ иңдерелгән аятьләрне һәм сүрәләрне язып алыр өчен сәхабәләрдән Гали бин Әбү Талибны, Мүгәвияне, Үбәйә бин Кәгъбне, Зәйд бин Сәбитне билгеләгән иде. Пәйгамбәребез ﷺ аларга аятьнең Корьәндәге урынын да күрсәтә иде. Башка сәхабәләр дә иңдерелгән аять һәм сүрәләрне язып алалар иде.

Сәхабәләр Корәнне ятлауда бер-берсе белән ярышалар иде, төнге намазларында укыйлар иде. Корьәнне хатыннары

һәм балалары да ятлый иде. Йортларыннан умарта кортлары гөҗләгән шикелле тавыш ишетелә иде.

Коръән Кәрим, Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ исән вакытта ук, тулысынча язып алынган иде, сәхабәләр тарафыннан ятланган иде. Шулай булса да, Коръән бер гомум мусхафка җыелмаган иде. Моңа ихтыяҗ да юк иде, чөнки Коръән әле иңдерелеп бетмәгән иде.

Әбү Бәкер (р.а.г.) хәлифә булган вакытында, Ямамә сугышында бөтен Коръәнне яттан белүче хафизларның шактые һәлак була. Коръәнне яттан белүчеләр сугышларда тагын һәлак булсалар, Коръәннең кайбер өлешләре югалып калуы мөмкин дигән фикер хәзрәти Гомәргә (р.а.г.) тынычлык бирми. Ул Әбү Бәкергә (р.а.г.) Коръәнне бер урынга җыюны тәкъдим итә. Әбү Бәкер (р.а.г.) бу эшне Зәйд бин Сәбиткә (р.а.г.) куша. Җыелган битләр Әбү Бәкердә (р.а.г.) саклана, ул вафат булганнан соң Гомәр (р.а.г.) хәлифәгә күчә, ә аннан соң Пәйгамбәребез ﷺ нең хатыны Хафсага күчә.

Госман (р.а.г.), хәлифә булган вакытында, Хафсада сакланган Коръән язылган битләрне соратып, алардан җиде нөсхә (экземпляр) күчерттереп, кире Хафсага кайтарган. Күчертеп алынган мусхафларны Госман (р.а.г.) хәлифәлекнең (дәүләтнең) төрле тарафларына җибәрә: Мәккәгә, Шамга (Димәшкъка), Куфага, Басрага, Бәһрәйнгә, Йәмәнгә. Берсен Мәдинә шәһәрендә калдыра, ул “имам мусхафы” дип исемләнә. Димәк, Госман (р.а.г.) вакытында Коръән безгә бүген таныш шәкеленә китерелә.

Шул сәбәпле дә, кулыбыздагы Коръән мусхафлары “Госманлы басма”, дип атала.

Пәйгамбәребез ﷺ нең хәдисе: «Аллаһның Китабы – ул сезгә хәтле булганнарның һәм сездән соң булачакларның хәбәре, сезнең һәм үз арагыз өчен канун, ул хак белән ялганны аеручы. Анда юк шаяру. Аның белән кешенең теләкләре адашып китми. Чын галимнәр аны укый-укый туя алмас. Аны күп кабатлап уку белән кеше армый, туймый, аның могҗизалары һич югалмый. Әгәр дә берәү аның белән гамәл кылудан туктаса, Аллаһы Тәгалә аны юк итә. Кем туры юлны Коръәннән башка урында эзләсә, Аллаһы Тәгалә аны адаштыра. Бу – Аллаһы Тәгаләнең нык җебе. Ул хикмәтле зикер, ул хак юл, аның белән гамәл итүче әҗер ала, аның белән хөкем итүче – гадел. Ә кем Коръәнгә чакыра – ул хак, туры юлга чакыра».

📖

Аллаһның әмере белән иңгән Коръән аятьләре.
Ак кәгазьнең өсләрендә язамын бән кәлями:
Лә иләһә илләл-Лаһе - Рәсүлебез сәламе.

Аллаһның әмере белән иңгән Коръән аятьләре,
Өммәтләренә калгандыр Рәсүлебез сөннәтләре.

Аллаһ әмренчә куелган Коръәннең тынышлары,
«Аллаһ» дисәң, күккә аша бәндәнең сулышлары.


Урыннардан кузгалганда «Аллаһ» диеп сулыймын,
И Ходаем, гөнаһымны гафу ит, дип елыймын.

Иртә торып, тәһарәт алып, укыйм «Әлхәм» сүрәсен,
Кыямәт көне булганда фирак (аерылу) уты булмасын.

Иртә торып намаздан соң укыекчы без Коръән,
Җан яраткан Аллаһының юлында булыйк корбан.

Иртә торып намаздан соң укыек без «Тәбәрәк»,
Аллаһыны искә алганда яшьләр төшсен тәгәрәп.

Ходаем, рәхмәтең берлә «Кәлям Шәриф» иңдерден,
Рәсүл сөннәтләре аша туры юлга күндерден.



Камил Вәлиуллин

ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ (ДӘРЕСЛЕК)

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 01.12.2012.

Форматы 84х108 1/16

Яр Чаллы шәһәре

«Ислам нуры» эшмәкәрлек үзәге